2˚2019

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**

ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Миңнуллин К.М., Сәфәров Р.Т.* Татар тел белемендә сүзлекләрнең тоткан урыны һәм тарихи үсеш перспективалары . . . . . . . . . 7
*Сабитова И.И.* Татар телендә тән әгъзалары атамаларының халык авыз иҗатындагы синонимнары *(дастаннар мисалында)* . . 14
*Хисияма Ю.* Татар телендә III зат тартым конструкцияләрен өйрәнүгә карата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Сәйхунов М.Р., Хөсәенова А.М., Хөсәенов Р.Р.* Мәгънәдәш сүзләр табуда нейрон челтәр мөмкинлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . 26

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Хәбетдинова М.М.* Ф. Бәйрәмованың «Һиҗрәт» (2017) романында татар эмиграциясе темасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Миңнуллина Ф.Х.* М. Гыйләҗев иҗатында гомумкешелек кыйммәтләренең чагылышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
*Гайнуллина Г.Р.* Әмирхан Еники публицистикасында иҗат әһелләренә хас сыйфатлар турында . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Әхсәнов К.Г.* Фатих Кәрими, Галиәсгар Камал һәм 1913 елның 23 (10) гыйнварында Истанбулда булган Дәүләт түнтәрелеше . . . 63
*Мифтахетдинова Н.М.* Татарча язу машиналары тарихы . . . . . 72

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Дәүләтшина Л.Х.* Бала туу йоласы: традиция һәм бүгенге халәте *(Норлат һәм Чистай районы татарлары мисалында)* . . . . . . 76

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Харисов Ф.Ф.* Укучыларда компетенцияләр формалаштыру мәсьәләсе: лингвометодик аспект . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
*Абдуллина Ч.З.* Мәгариф системасында татар теле: үткәне һәм хәзергесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88

### СӘНГАТЬ

*Салихова А.Р.* Аяз Гыйләҗевнең Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган әсәрләренә хас сәнгати үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
*Камалова З.А.* Татарстанда яңартыласы паркларда милли мохит тудыру ысуллары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

### ФӘННИ БАГЛАНЫШЛАР

*Рогачев В.И., Баязитова Ф.С, Сәфәров Р.Т.* Идел буендагы мордва-татар тел бәйләнешләре турында . . . . . . . . . . . 115

*Ибраева А.Т., Минһаҗева Л.И.* Казакъ әдәбияты һәм Шәрык әдәби багланышлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Ахунов А.М.* Татар матбагачылык тарихында И.Н. Харитонов *(тууына 160 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

*Г. Газиз*. Милләтне ничек тәгъриф кылырга? . . . . . . . . . . . 140

*Фәтхи А.* Үткән гасырларның шигъри сәхифәләре . . . . . . . . 149

**ЭПИГРАФИКА**

*Гариф Н.Г.* Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик ташларны барлау, исәпкә алу һәм аларга статистик анализ . . . . . . . . . . . 167

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Сибгатуллина Ә.Т.* Исхакыйның иҗтимагый-сәяси фикер дөньясы хакында яңа хезмәт (китап күзәтү: Ahmet Kanlıdere. Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshaki (1878–1954). İstanbul, Ötüken yay., 2019. 318 s.) . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Миннуллин К.М., Сафаров Р.Т.* Основные этапы развития татарской лексикографии . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Сабитова И.И.* Соматические синонимы в фольклорных текстах татарского языка *(на примере дастанов)* . . . . . . . . . 14

*Хисияма Ю.* Исследование конструкций принадлежности татарского языка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19

*Сайхунов М.Р., Хусаинова А.М., Хусаинов Р.Р.* Технологии на основе нейронных сетей для поиска близких по значению слов . 26

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Хабутдинова М.М.* Ф. Тема татарской эмиграции в романе Ф. Байрамовой «Һиҗрәт» («Исход»; 2017) . . . . . . . . . . . . . . 35

*Миннуллина Ф.Х.* Отражение общечеловеческих ценностей в творчестве М. Гилязова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46

*Гайнуллина Г.Р.* Вопросы интеллигентности, народности творца в публицистике Амирхана Еники. . . . . . . . . . . . . . . . 55

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Ахсанов К.Г.* Фатих Карими, Галиаскар Камал и Государственный переворот 23 (10) января 1913 г. в Стамбуле . . . . . . . . . . . 63

*Мифтахетдинова Н.М.* История создания пишущих машин с татарским шрифтом . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Давлетшина Л.Х.* Родильный обряд: традиции и современное состояние *(на примере Нурлатского и Чистопольского районов Республики Татарстан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Харисов Ф.Ф.* Проблемы формирования компетенций в ходе обучения: лингвометодический аспект . . . . . . . . . . . . 81

*Абдуллина Ч.З.* Татарский язык в системе образования: становление и современное состояние . . . . . . . . . . . . . . . 88

## ИСКУССТВО

*Салихова А.Р.* Художественные особенности сценического воплощения произведений Аяза Гилязова на сцене Татарского государственного академического театра им. Г. Камала . . . . . . 96

*Камалова З.А.* Способы сохранения и восстановления татарского национального стиля при оформлении парков в Республике Татарстан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .102

## НАУЧНЫЕ СВЯЗИ

*Рогачев В.И., Баязитова Ф.С, Сафаров Р.Т.* О мордовско-татарских языковых контактах в Поволжье . . . . . . . . . . . .115

*Ибраева А.Т., Мингазова Л.И.* Казахская литература и восточные литературные взаимосвязи . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Ахунов А.М.* И.Н. Харитонов в истории становления татарской печати *(к 160-летию со дня рождения)* . . . . . . . . 134

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

*Г. Газиз*. Как определить понятие «милләт» . . . . . . . . . . . 140

*Фатхи А.* Поэтические страницы прошлых веков . . . . . . . . 149

**ЭПИГРАФИКА**

*Гариф Н.Г.* Эпиграфические (надгробные) памятники Казанского ханства . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Сибгатуллина А.Т.* Новое произведение о мировоззрении Г. Исхаки (обзор книги: Ahmet Kanlıdere. Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshaki (1878–1954). İstanbul, Ötüken yay., 2019. 318 s.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 811.512.145

***К.М. Миңнуллин,***
***Р.Т. Сәфәров***

# ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ СҮЗЛЕКЛӘРНЕҢ ТОТКАН УРЫНЫ ҺӘМ ТАРИХИ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

Статья посвящена основным этапам развития татарской лексикографии. В хронологическом порядке рассмотрены и описаны рукописные и печатные словари татарского языка, определены предпосылки их составления. Отдельно рассмотрена типология наиболее значимых словарей татарского языка, проведена их классификация и описание.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикография, типология словарей, история татарской лексикографии.

The article is devoted to the main stages of the development of Tatar lexicography. The handwritten and printed dictionaries of the Tatar language are reviewed and described in chronological order, the prerequisites for their compilation are determined. The typology of the most significant dictionaries of the Tatar language is considered separately, their classification and description are carried out.

**Keywords:** Tatar language, lexicography, typology of dictionaries, history of Tatar lexicography.

Сүзлекләр – телнең билгеле бер чордагы хәлен, сүз байлыгын теге яки бу күләмдә чагылдыра торган лексикографик чыганаклар. Аларда телнең үсеш тарихы һәм аерым чорга хас сүзләр мирасы теркәлеп кала. Сүзлекләр, бер яктан, телнең сүзлек фондын тәкъдим итсә, икенче яктан, аларда җәмгыятьтә мәйданга килгән күренешләрне, чит халыклардан кергән яңа реалияләрне телнең үз чараларыннан файдаланып атаган яңа сүзләр яисә алынмалар да теркәлә. Вакыт сынавы үткәннән соң, ул сүзләр кулланылышка кереп китәргә мөмкин. Шуңа күрә сүзлекнең телне үстерүдә, баетуда уйнаган роле, тоткан урыны гаять зур.

Телдәге барлык сүзләрне яисә билгеле бер күрсәткечкә нигезләнеп сайланган сүзләр төркемен аерып барлау, аерым бер тәртиптә тезү ихтыяҗы борынгы заманнарда ук туган. Галимнәр фаразлавынча, сүзлекләр төзү аларның гамәли заруриятенә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Халыкларның үзара аралашуы, тормыш-көнкүреш казанышларын уртаклашуы, башка халыкларның мәдәниятен белергә омтылуы алар телендәге аерымлыкларны, җитештерелгән һәм базарга чыга торган төрле әйберләрнең, эшләнмәләрнең исем-атамаларын да белү зарурлыгын тудырган. Бу бигрәк тә чит, әлегә таныш булмаган халыклар белән очрашканда, алар белән аралашуны җайга салу өчен кирәк булган. Сүзлекләрнең гамәли максатларны күздә тотуы бәхәссез. Иң борынгы сүзлекләр, аеруча тәрҗемәле сүзлекләрнең беренче үрнәкләре сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр тарафыннан башкарылган булуы

шул турыда сөйли. Халыклар арасында дин тарату, миссионерлык итүчеләр дә бу эшкә өлешләрен керткәннәр. Мәсәлән, фәндә Codex Cumanicus дип йөртелә торган Коман мәҗмугасы Кара диңгез буендагы кыпчаклар (европалылар телендә команнар) белән актив сәүдә мөнәсәбәтләре алып барган Европа, төгәлрәге Италия сәүдәгәрләре тарафыннан 1303 елда төзелгән була. Алтын Урдага йөреп сәүдә иткән руслар өчен язылган «Се татарскыи язык» лексиконын да мисалга китерә алабыз.

Сүзлекләрнең тарихы, аларның кайсы төре аеруча актуаль булуы турында фикер йөрткәндә, бигрәк тә тәрҗемәле сүзлекләрнең алгырак планда торуы күзгә ташлана. Халыкларның үзара аралашуында чит телләрне өйрәнү, алардан кергән сүзләрне аңлату, бер телдәге сүзнең мәгънәсен икенче телгә мөмкин кадәр тулы һәм төгәл итеп күчерү кирәк булган. Шул сәбәпле булса кирәк, күпчелек телләрдә сүзлекләрнең барлыкка килүе, тарихы турында сөйләгәндә, сүзне иң элек тәрҗемәле сүзлекләрдән башлыйлар. Татар лексикографиясе тарихында да зур урынны XI гасырда М. Кашгари тарафыннан төзелгән төркичә-гарәпчә «Диване лөгатет-төрк» сүзлеге алып тора. Анда күпсанлы төрки кабиләләрнең бай фольклор әсәрләре (табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, җырлар), төрле сөйләү үрнәкләре, бай сүзлек материалы тупланган. Аларның шактый өлеше хәзерге татар телендә дә яшәп килә.

Сүзлекләр төзелә башлау һәм аларның үсеш-үзгәреше халыкларның тарихы, аларның иҗтимагый үсеш-үзгәреше һәм төрле мәдәни-икътисади вакыйгалар белән бәйле, бу процесста күптөрле факторларның теге яки бу дәрәҗәдәге йогынтысы хакында әйтергә кирәк.

Борынгы чордан ук сүзлекләр төрле характерда төзелгәннәр. Башлыча, тәрҗемәле сүзлекләр күбрәк булса да, алар үз эчләрендә дә төрлелек күрсәтәләр. Мәсәлән, XIII гасыр азагында – XIV гасыр башында «Китабе тәрҗемане фарси вә төрки вә магули» дигән сүзлек төзелүе мәгълүм. Ул гарәп галиме Ибне Мүһанна тарафыннан гарәп телендә язылган һәм, исеменнән күренгәнчә, фарсы, төрек, монгол телләренең грамматикасын һәм сүзлеген эченә ала. Галимнәр (В.Р. Розен, П.М. Мелиоранский, С.Е. Малов, М. Ногман) бу сүзлектә дә татар теле белән уртак материалның шактый булуына игътибар итәләр. Мәсәлән, М. Ногман әлеге хезмәттә чагылган 900ләп фигыльнең күпчелек өлеше хәзерге татар телендә дә актив кулланылышта йөри, дип ассызыклап күрсәтә [Ногман, б. 9].

Югарыда атап үтелгән Коман мәҗмугасы да татар теленә бәйләнешле сүзлекләр рәтендә карала ала. Анда европалы миссионерлар тарафыннан тәрҗемә ителгән «Инҗил»нең кайбер өлешләре һәм кыпчак сүзләренең тәрҗемәсен тәшкил иткән сүзлек бирелгән. В.В. Радлов әлеге хезмәттәге коман (кыпчак) теленең Идел буе татарлары теленә, бигрәк тә мишәр диалектына якын икәнлеген кат-кат ассызыклап күрсәтә [Радлов, 1884]. Татар тел белгечләреннән Л.Т. Мәхмүтова Коман мәҗмугасын махсус тикшерә. Ул да мәҗмуга лексикасының

татар теленең көнбатыш диалектына якынлыгын раслый [Махмутова, 1982; Махмутова, 1985].

Урта гасырларда төзелгән һәм татар теленә кагылышы булган сүзлекләрдән Хаҗи Бәйрәм Хаҗи Булат углы сүзлеген дә күрсәтергә мөмкин (1581). И.Ш. Әүхәдиев шактый яхшы сакланган 296 битлек бу кулъязма сүзлекнең госманлы төрек теленә нисбәтле булуын ассызыклый [Авхадиев, с. 343–357].

Татар телендә сүзлекләр тарихы турында сүз йөрткәндә, татар-рус бәйләнешләрен исәпкә алырга туры килә, чөнки татар халкы төрки дөньяның бер читендәрәк формалашкан. Аның рус халкы белән турыдан-туры бәйләнеш тарихы мең елдан артып китә. Шушы дәвердә татар һәм рус халыклары арасында иҗтимагый-сәяси, мәдәни-икътисади, сәүдә, гади көнкүреш һ. б. юнәлешләрдә тыгыз бәйләнешләр яшәп килгән. Әлбәттә, бу бәйләнешләр барышында үзара аралашу бик мөһим. Тагын бер бик әһәмиятле факторны истә тотарга кирәк: татар халкы Европа белән Көнчыгышны, Төньяк белән Көньякны үзара тоташтыручы-бәйләүче, арадашчы ролен үтәгән, татар теле исә аралашу теле булып хезмәт иткән. Менә мондый хәл русча-татарча тәрҗемәле сүзлекләрнең барлыкка килүенә, аларның сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан да үсешенә китергән.

Аеруча Казан ханлыгы Рус дәүләте составына кертелгәч, татар-рус мөнәсәбәтләре тагын да тирәнәя. Нәтиҗәдә аралашу максатына яраклы рәвештә практик кулланма буларак төрле сүзлекләр төзелә башлый. Шундыйлардан XVII йөз ахырында рус сәүдәгәрләре төзегән кулъязма сүзлек (Сборник рукописей конца XVII и начала XVIII веков) билгеле. Табигый, алар әле кулъязма хәлендә булганнар һәм аерым бер даирәдәге кешеләрне канәгатьләндергәннәр. Мәсәлән, Н.К. Симонинның «Памятники старинной русской лексикографии по рукописям XV–XVII веков» (1908) исемле хезмәтенә кергән сүзлекчәдә 40 ка якын татар сүзләре һәм тәгъбирләре теркәлгән [Ногман, б. 26].

Тарих барышында ижитимагый үсеш-үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, сүзлекләр төзүнең максаты һәм юнәлеше дә үзгәрә, төрләнә килә. Рус дәүләтенең яңадан-яңа төбәкләрне үзенә куша баруы нәтиҗәсендә, әлеге территорияләрдә татарлар белән идарә итү һәм шулай ук көньякта, көчыгышта биләмәләрен үстерү өчен, татар телен белү ихтыяҗы арта. Россиянең идарә органнарына татар телен белүче кешеләр хезмәт күрсәткән. Чит илләр, аеруча Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр татар телендә алып барылган. Татар теле Идел-Урал регионында яшәүче халыклар өчен XVIII гасыр азакларына, XIX гасыр башларына кадәр аралашу теле хезмәтен үтәгән. XVII йөз башында ук дәүләткүләм әһәмияткә ия рус грамоталары даими рәвештә татар теленә тәрҗемә ителгән.

Көннән-көн үсә, зурая барган рус дәүләтенең мәнфәгатьләрен ныгыту максатыннан, татарлар арасында эшләр өчен, аларның телләрен белә торган рус чиновниклары әзерләү мәсьәләсе көн тәртибенә баса.

Моның өчен күп кенә шәһәр мәктәпләрендә һәм гимназияләрендә татар телен фән буларак укыту кертелә, аларга кирәкле кулланмалар, аеруча икетелле сүзлекләр төзү мөһим бурычка әверелә. Шуның нәтиҗәсендә Самарада (1730), Казанда (1769), Тубылда, Омскида, Оренбургта һәм башка кайбер шәһәрләрдә татар теле укытыла, дәреслекләр, үзлектән телне өйрәнү кулланмалары языла башлый, күпсанлы тәрҗемәле сүзлекләр төзелә. Ул сүзлекләрнең кайберләре кульязма хәлендә хәзергә кадәр сакланып калган.

Заманында күренекле дәүләт эшлеклесе булган тарихчы В.Н. Татищев әмере белән, русларга татар һәм калмык телләрен укыту өчен, мәктәп ачыла, «Русча-татарча-калмыкча сүзлек» (1740) (Рычков сүзлеге) төзү оештырыла. Тик ул төзелеп бетмәгән, «В» хәрефендә тукталып калган. Самарадагы татар-калмык мәктәбе укучылары өчен кульязма хезмәт тә языла (төзүчесе М. Котельников), Казан гимназиясе укытучысы Сәгыйть Хәлфин 1785 елда ике томлы (I – 653 б., II – 874 б.) татарча-русча сүзлек төзи. Бу кульязма сүзлеккә 22 мең сүз кергән. Галимнәр күрсәтүенчә, ул башка сүзлекләрдән үзенең системалылыгы, рус сүзләренең мәгънәләрен тулырак, төгәлрәк күрсәтүе белән аерылып тора. Галимнәр сүзлекне татар лексикографиясенең иң югары казанышларыннан беренчесе дип саныйлар, авторның бу эшкә иҗади якын килүен, сүзләрне тәрҗемә итүдә төрле ысуллар белән эш итүен ассызыклап күрсәтәләр.

Кульязма сүзлекләрдән тагын бер сүзлеккә тукталып үтәргә кирәк. XVIII гасырның икенче яртысында Екатерина II җитәкчелегендә күптелле чагыштырма сүзлек төзүгә омтылыш ясала. Төрле өлкәләрдән килгән материаллар нигезендә «Сравнительные словари всех языков и наречий, собранные десницею всевысочайшей особы. Отделение первое. Содержащее в себе европейские и азиатские языки» (СПб., ч. I. – 1787; ч. II. – 1789) дигән сүзлек (Паллас сүзлеге) басылып чыга, анда татар сүзләренең адреслары казан татарлары, мишәрләр, себер татарлары дип аерып күрсәтелә.

Шулай итеп, сүзлекләр төрле тарихи шартларда, мәдәни-икътисади һәм иҗтимагый сәбәпләр белән бәйле рәвештә төзелә башлаганнар. Тарихи үсеш-үзгәреш барышында аларның төрләре арта, күләмнәре зурая, эчтәлекләре киңәя, төзү принциплары да камилләшә бара.

Басма сүзлекләр төзелә башлауны теге яки бу тел фәненең үсешендә әһәмиятле баскыч дип бәяләргә кирәк. Бу фәнни кыйммәткә ия булган сикереш кульязма сүзлекләр формалашкан чорның бөтен казанышларын эченә ала, әкренләп тупланып килгән тәҗрибәгә нигезләнә.

Татар лексикографиясендә беренче басма сүзлекләрне Тубыл мәктәбендә татар теле укытучысы булып эшләгән И. Гиганов төзегән. Ул 1801 елда «Слова коренные и нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку» дигән 75 битлек сүзлек чыгара, ә 1804 елда, Тубыл төбәгендәге муллалар ярдәме белән, «Словарь российско-

татарский» дигән 684 битлек сүзлек әзерләп бастыра. Бу сүзлекләр татар теленең көнчыгыш диалектларына хас үзенчәлекләрне һәм сүзләрне чагылдыралар.

XIX гасыр татар лексикографиясе үсеш-үзгәрешенең төп этаплары бер төркем сүзлекләр белән дәлилләнә. Шуларның берсе – А. Троянскийның 1833–1835 елларда басылып чыккан «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских» дигән татарча-русча ике томлы сүзлеге. Ул күләмле (1000 биткә якын) бай материалны эченә алган һәм җентекләп эшләнгән булуы белән аерылып тора.

1869–1871 елларда Петербургта Л.З. Будагов тарафыннан төзелгән «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий» исемле сүзлек дөнья күрә. Ул ике томнан тора һәм татар теле генә түгел, башка төрки телләр буенча да бай материалны колачлый, сүзлектә сүзләрнең оялап бирелүе дә үзенчәлекле, анда борынгы төрки һ. б. язма истәлекләрдән дә сүзләр китерелгән. Тел белеме өчен зур әһәмияте булган бу сүзлек соңгы елларда кабат басылды.

XIX гасыр азагы татар лексикографиясендә К. Насыйри эшчәнлеге зур игътибарга лаек. Галимнең киң мәгълүматлы, гаять күпкырлы фәнни иҗатында сүзлекләр төзү аерым урын алып тора. Аның тәрҗемәле сүзлекләре ике яклы булуын ассызыклап үтәргә кирәк. Ул 1878 елда «Татарско-русский словарь» исемле 120 битлек китап бастыра. 1892 елда исә аның «Полный русско-татарский словарь с дополнениями из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» дигән сүзлеге дөнья күрә. 263 битлек бу сүзлек 1911 елда яңадан басыла.

К. Насыйри – төрле дәреслекләр авторы. Ул үзенең хезмәтләрендә, татар тел белемендә беренчеләрдән булып, төрле тармакларга (тел белеме, химия, математика, педагогика, медицина, үсемлекләр дөньясы һ. б.) караган терминнар системасының башлангыч нигезләрен төзегән, бу өлкәләргә хас кайбер гарәп-фарсы алынмаларын, русча булган терминнарны татар теленең үз сүзләре белән ясарга яисә инде көндәлек аралашу теленә кергән һәм мәгънәләре ачык аңлаешлы булган алынмалар белән алыштырырга тәкъдим иткән, хезмәтләрендә үзе язган һәр юнәлеш буенча кечкенә сүзлекчәләр төзеп бастыра килгән. Шулай итеп, XIX гасыр азагында татар теленең терминнар системасына да нигез салына, һәм алар киләсе этапларда төрле тармак терминологиясе сүзлекләренең уңышлы башлангычын билгелиләр.

XIX гасыр азагында да татарларның аерым төркемнәре белән бәйле тәрҗемә сүзлекләр бастыру дәвам итә. Шундыйлардан Н.П. Остроумовның керәшен сөйләшләре буенча төзелгән татарча-русча сүзлеген күрсәтергә мөмкин.

Шушы ук чорларда А. Воскресенскийның «Русско-татарский словарь с предисловием о произношении и этимологических изменениях татарских слов» (Казань, 1894) дигән сүзлеге чыга.

XIX гасыр басма сүзлекләренә күзәтү ясаганда, бер төркем кыскача русча-татарча яисә татарча-русча сүзлекләргә аерым тукталып үтәргә кирәк. Алар татар телен укыту барышында ярдәмлек яки төрле кулланмаларга кертелгән өлеш буларак дөнья күргәннәр. Аларның күбесе XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында төзелгән төрле телләрне өйрәтү кулланмаларында, сөйләүлекләрдә тәрҗемә материал буларак та чагылыш тапкан. Татар теленең сүзлек фондыннан кызыклы, бай материал тупланган һәм зур фәнни әһәмияткә ия булган сөйләүлекләргә түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

1) Букварь татарского и арабского письма с приложением слов со знаками, показывающими их выводы, сочиненный в Тобольском главном народном училище Бухарцем Ният-Бакою Атнометовым под руководством татарского языка учителя, соборного священника Иосифа Гиганова (СПб., 1802; Ә.Ш. Юсупова бу хезмәтне XIX гасырда һәм аннан соң төзелгән үзөйрәткеч һәм башка кулланмаларның беренче башлап җибәрүчесе дип саный);

2) М.Ш. Салихов – Новый самоучитель татарского языка или руководство выучиться говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски, без посторонней помощи (Казань, 1885. Бу хезмәт, нигездә, русча-татарча сүзлек рәвешендә төзелгән);

3) Новый и полный самоучитель татарского или руководство выучиться говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски (Казань, 1887. Хезмәт русча-татарча сүзлек рәвешендә төзелгән. А. Фәтхи аны Г. Вәһаповныкы булуы мөмкин дип санаган. Берничә тапкыр басылып чыккан);

4) Русско-татарская азбука, составленная Вагаповымъ, в коей помещены употребительнейшие слова, разговоры, краткія повести и песни северных татар (Казань, 1852. Бу үзөйрәткеч 1916 елга хәтле 20 тапкыр нәшер ителгән);

5) Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков с кратким объяснением существующих в Оренбургском крае наречий башкир и киргизов и с приложением к нему русско-персидско-татарских слов и прописей составил старший учитель арабского и персидского языков в Оренбургском Неплюевском кадетском корпусе и преподаватель татарского языка в школе киргизских детей, учрежденной при Оренбургской пограничной комиссии, коллежский ассессор Мир-Салихъ Бекчурин (Казань, 1859. Биредә сүзләр русча-татарча тематик сүзлек рәвешендә урнаштырылган);

6) Новый практический самоучитель татарского языка. Полное руководство, как без посторонней помощи, выучиться по-татарски, а татарам по-русски. С приложением татарско-русского словаря, фраз и разговоров. Составил по Троянскому, Махмудову и Салихову. И. Кондратов (Казань, 1893. – 5 тапкыр басылган);

7) Ш. Саинов. Яңа тулы үз-үзеңнән үгрәнгеч (Казан, 1880; Хезмәт татарча-русча тематик сүзлек рәвешендә төзелгән);

8) Ш.Ә. Рәхмәтуллин. Үзлегеннән өйрәтүче татар телине урысларга һәм урыс телине татарларга (1894–1915 елларда 7 басмасы дөнья күрә).

Үзлектән телне өйрәнү кулланмалары Ә.Ш. Юсупованың «Самоучители татарского языка XIX века: лексика» хезмәтендә шактый тулы һәм җентекле итеп анализланган. [Юсупова, 2002].

*Дәвамы бар.*

**Әдәбият**

*Авхадиев И.Ш.* Арабско-тюркский словарь XVI века // Вопросы татарского языкознания. Кн. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1965. С. 456.

*Махмутова Л.Т.* О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 3. Казань, 1985. Б. 117–142.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики (краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 2. Казань, 1982. Б. 68–153.

*Ногман М.* XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кулъязма сүзлекләр. Казан: КДУ нәшр., 1969. 112 б.

*Радлов В.В.* О языке куманов: По поводу издания куманского словаря. СПб.: тип. Имп. АН, 1884. С. 53.

*Юсупова А.Ш.* Самоучители татарского языка XIX века: лексика. Казань: Школа, 2002. 140 с.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145’373

***И.И. Сабитова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТӘН ӘГЪЗАЛАРЫ АТАМАЛАРЫНЫҢ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДАГЫ СИНОНИМНАРЫ
**(дастаннар мисалында)**

В статье рассматриваются названия частей тела, которые встречаются в народных дастанах и имеют синонимы в современном татарском литературном языке. Большинство этих соматизмов не употребляются в современном языке, лишь некоторые из них имеют место в отдельных диалектах.

**Ключевые слова***:* дастан, соматизм, синоним, диалект, синонимия.

The article deals with the names of body parts that are found in folk dastans and have synonyms in the modern Tatar literary language. Most of these somatisms are not used in the modern language, only some of them occur in separate dialects.

**Key words:** dastan, somatism, synonym, dialect, synonymy.

Халык иҗаты – гаҗәеп мәгънәле, бай, борынгы өлкә. Фольклор әсәрләренең һәркайсы игътибарга лаек, чөнки аларда халкыбызның үткәне, чал тарихы чагыла. Фольклорның бер жанры булган дастаннар да халык иҗатында күренекле урын алып торалар. Дастан – борынгы фарсы сүзе, хәзер дә киң кулланышта булган бу атама поэма, эпос төшенчәләренә якын тора. Дастан сүзенең төрки телләрдәге «тарих, хикәя», «үткән эшләр хикәясе» дигән мәгънәләре дә һәрберебезгә мәгълүм.

Борынгыдан килгән лексика дастаннарда катып калган хәлдә дә сакланган. Хәзерге тел дәрәҗәсендә бу берәмлекләрнең мәгънәләре инде югалган диярлек. Алар күбесенчә искергән, борынгы тарихи сүзләргә карый. Дастаннарда, хәзерге татар телендәге тән әгъзалары атамалары белән беррәттән, борынгы соматизмнар да киң кулланыла.

Дастаннарның килеп чыгышы, халыкта таралышы, сакланыш дәрәҗәсе, формасы һәм стиле фольклорчыларның тикшерү объекты булса да, бу мәкаләдә без татар халык дастаннарында очраган һәм хәзерге телебездә кулланыла торган соматизмнарга мәгънәдәш, тән әгъзаларын атаган сүзләрнең кайберләренә тукталып үтәргә булдык.

Борынгыдан ук килгән кеше әгъзалары атамалары арасында халык сөйләм телендә генә йөри торганнары, кулланылыштан төшеп калып, бөтенләй эзсез югалып барганнары бар. Алар 1969 елда дөнья күргән «Борынгы төрки сүзлек»тә урын алсалар да, хәзерге татар телендә очрамыйлар. Ул сүзлектә дә борынгы тән әгъзалары атамаларының барысы да теркәлмәгән [Древнетюркский словарь, 1969]. Шуңа күрә онытылып барган борынгы соматизмнарның дастаннарда гына очравы һәм сакланып калуы гаҗәп түгел.

«Идегәй» дастанында **арка**, **арка турысы**, **калак сөякләре** соматизмнарының бик кызыклы синонимнары очрый:

*__Яурыны__ яссы, муйны озын,*
*Җәй тартмага кулы озын*
[Идегәй. Татар халык дастаны, 1988, б. 33].

2015 елда дөнья күргән, Р. Әхмәтьянов тарафыннан төзелгән «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә ***яурын*** сүзе һәм аның варианты – ***явыр*** сүзләре дә теркәлгән [Әхмәтьянов, 2015, II, б. 564]. Бу сүз күпчелек төрки телләрдә һәм татар сөйләшләрендә дә калак сөяген, җилкә сөяген һәм умыртка башын белдерә диелә [Әхмәтьянов, 2015, II, б. 530].

Икенче бер дастанда **умыртка баганасын** *арка баганасы* дип атаган урын бар: *Арысланның **арка баганасын** сындырган көчле абыең да, ... ат өстендә оста йөрүче абыең да, үзләре кай яклары беләндер синнән өстен булсалар да, көнләшерләр синнән* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 164].

«Түләк» дастанында **умыртканың** *уңгуртка* варианты очрый:

*Ун ай төгәл күтәргән,*
*__Уңгурткадин__ бөгелгән*
[Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 126].

Шул ук «Идегәй» дастанында **аңкау** атамасының мәгънәдәше *таңлай* атамасы китерелә:

*Каршыннан килеп акырып,*
*Маңлаена бер сукты,*
*__Таңлаеннан__ ут чыкты*
[Идегәй. Татар халык дастаны, 1988, б. 152].

Кайбер төрки телләрдә (нугай, каракалпак, үзбәк, төрекмән) *таңлай* атамасының **аңкау** мәгънәсендә кулланылганын күрергә мөмкин [Әхмәтьянов, 2015, I, б. 212].

«Таһир белән Зөһрә» дастанында **бит**, **йөз, чырай** атамаларының мәгънәдәше буларак *җәмал* сүзе китерелгән очрак бар: *Әмма Зөһрә бу сүзләрне колагына алмады, оят, намусны куеп, Таһиргә **җәмал** күрсәтеп, бер шигырь әйтте* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 227].

Икенче бер дастанда әлеге атамаларның синонимы булган *дидар* сүзе кулланылган:

*Кашымда сөеп утырган,*
*__Дидарыма__ туймаган,*
*Ялгызым, дип уйлаган*
[Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 221].

«Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә **бит**, **йөз чырай** атамаларының мәгънәдәше булган *рөх* сүзе очрый: *Көннәрдән бер көнне Кайс Ләйләгә ала күз илә бактыкта күрде кем, **рөхләре** гөл, саче сөмбел, бәге гамбәр, кашы камәр, гамзәсе хәнҗәр, күзләре мәхмүр, сим тәне кафур, бәдәне бер маһитаптыр ки, көннән-көн чибәрлеге артмакта* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 175].

Шул ук дастанда *әл* сүзе **кул** атамасының синонимы булып килә: *Соңра һушына килеп, Ләйлә Мәҗнүннең **әленә** ябышып, икесе бер йиргә килеп, Зәет дәхи араларында хезмәт итә иде* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 204].

Д. Рамазанова үзенең «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» исемле хезмәтендә *«кул»* сүзенә дә җентекле анализ ясый. Ул «борынгы татар язма әдәбияты әсәрләрендә *кул* мәгънәсендә, нигездә, *әл/әлег* сүзе кулланыла һәм бу әсәрләрне җентекләп өйрәнү әлеге ядкярләрдә Көнчыгыш әдәбиятына хас традицион *әл* сүзенең кулланыштан төшә баруын, *кул* сүзенең активлашуын күрсәтә», – дип билгеләп үтә [Рамазанова, 2015, б. 107]. «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә *«әл»* вокабуласы искергән сүз тамгасы белән теркәлгән һәм аның борынгы төрки сүз икәне күрсәтелгән [Әхмәтьянов, 2015, I, б. 130].

**Кулбаш** соматизмының *чөгер* сүзе аша бирелгән очрагына мисал: ... *ике **чөгере** йөдәп, чыкылдап торды* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 29].

Халык дастаннарында **ирен** сүзенең дә матур яңгырашлы мәгънәдәше очрый: *Гыйшк ара **ләб** ташнәмән су бирәрем юк мәнем* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 261].

*Морт* сүзенең **мыек** атамасы синонимы икәнлеге түбәндәге мисалдан ачык күренә: *Өй эчендә яшь егет алып ятыр, ... кулы белән **мортын** сыйпап көлеп ятыр* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 48].

**Яңак** сөягенең дә мәгънәдәш сүзе бар. Ул «Идегәй» дастанында очрый:

*Алты суның буенда*
*Йөз туксан биш яшәгән,*
*Азаулары какшаган,*
***Мөчәләре** йомшаган,*
***Чокчытлары** бушаган*

[Идегәй. Татар халык дастаны, 1988, б. 51].

Алда китерелгән өзектә *мөчә* сүзенең **әгъза** мәгънәсендә кулланылуы да күренә.

Ә менә борынгы бабаларыбыз балыкның яңагын, ягъни саңагын *шыгай*, *аткак* сүзләре белән атаганнар. Бу сүзләр кеше әгъзаларын белдермәсәләр дә, аларны бу мәкаләдә күрсәтеп үтү урынлы булыр: *Ак Күбәк камчы сабы белән балыкны **шыгайдан** элеп күтәреп алып чыгып китте* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 81]*; Балык ... ике алтын **аткак** сөяген алып килде Мешәк алыпка* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 30].

«Йиртөшлек» дастанында безне кызыксындырган кеше тәне әгъзалары атамаларыннан *соганак бармак* һәм *симә кабырга* сүзләре бар. Алар хәзерге әдәби телдә **чәнчә бармак** һәм **соңгы кечкенә кабырга** атамаларына туры килә:

*Киек әйтте:*

*– Үлемем синнән булыр дип тойган идем. Син туганда бик авырлык килгән иде,* ***соганак бармагым*** *мырт иткән,* ***симә кабыргам*** *шырт иткән* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 70].

Хәзерге вакытта кайбер сөйләшләрдә **чәнчә бармакның** *чыганак бармак* формасы кулланыла, шулай ук *чыганак* сүзе **терсәкне** дә белдерә, ә *сонагак* сүзе **терсәк, терсәктән кул чугына кадәр өлешне** белдергән сүз буларак сакланып калган [Рамазанова, 2015, б. 118].

Дастаннарда **маңгай чәче** атамасының борынгы мәгънәдәше булган *какыль* сүзе дә очрый:

*Бәет Шаһсәнәм бу торыр:*
*Бу сүзләрең куйды мәне үлемгә,*
*Былбыл китеб, заглар кунды гөлемгә,*
***Какыльләрем*** *чормашыбдыр билемгә,*
*Адәм чакар мар икәнең белмәдем*
[Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 262].

«Идегәй» дастанында *кәгел* сүзе **атның маңгай ялы** мәгънәсендә бирелгән:

*Иярenең кашы алтын,*
*Йөгәненең башы алтын,*
*Колагын бездәй кадаган,*
*Кәгелен кыздай тараган*
[Идегәй. Татар халык дастаны, 1988, б. 79].

Д. Рамазанованың алда күрсәтеп үтелгән хезмәтендә әлеге сүз «кикел» дип бирелә. Ул аны «берәр якка төшебрәк торган маңгай чәче» ди. Бу сүз борынгы чорда кулланышта йөргән булырга тиеш һәм бүгенге көндә дә нугай, казакъ, кыргыз, каракалпак, үзбәк телләрендә сакланып калган [Рамазанова, 2015, б. 26]. Р. Әхмәтьянов үзенең сүзлегендә әлеге сүзнең «какул» вариантын китерә. Аның төп мәгънәсе – «ир кешенең яшьтән үк баш түбәсендә киселмичә-кырылмыйча калдырыла торган толымчык». Бу сүз «кәкәл, кәкел» вариантларында татар диалектларында, шулай ук казакъ, каракалпак, нугай, кыргыз, комык, карачай-балкар, үзбәк, монгол, эвенк, якут телләрендә сакланганын күрсәтә [Әхмәтьянов, 2015, I, б. 338]. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең 2017 елда басылып чыккан III томында да бу сүз «какул» формасында теркәлгән [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2017, III, б. 65].

Халык дастаннарында бик кызыклы тагын бер борынгы соматизм очрый. Ул да булса *ау* сүзе. Борынгылар кешенең утыра торган әгъзасын, ягъни артын, шул сүз белән атаганнар:

*Ат бирсә дә менә алмам*
***Аувым*** *котсыз булганда!*
[Идегәй. Татар халык дастаны, 1988, б. 82].

Тагын бер кызыклы атама – *куксү*. Ул – хәзерге әдәби телдәге **күкрәк, түш, гәүдә** кебек атамаларның мәгънәдәше: *Аждаһаның башы җирдә калды,* ***куксүе*** *каерылып барып, дәрьяның эченә егылды*

[Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 31]; *Шул заман Шаһсәнәм урныдин торыб, күксегә кулыны куеп, бөкелеб тәгъзим кыйлды* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 265].

**Тән** сүзенең синонимы булган *ит* сүзе «Кузы Көрпәч белән Баян Сылу» дастанында урын алган: *Кузы Көрпәч әйтте: – Анамнан туган **итемдә** һич нәрсә авыртканы юк, син авырттырдың* [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 143].

Татар теленең этимологик сүзлегендә *ит* сүзенең, гомумтөрки сүз буларак, **тән** мәгънәсен дә белдерүе күрсәтелгән [Әхмәтьянов, 2015, I, б. 315].

Алда карап үтелгән борынгы соматизмнар хәзерге татар әдәби телендә сакланмаган. Кайберләре генә диалектларда очрый. Хәзерге көндә *әл* сүзе **кул** мәгънәсендә – татар теленең бары пермь сөйләшендә, *күксә* сүзе **күкрәк читлеге** мәгънәсендә – тубыл сөйләшендә, *таңлай* сүзе **аңкау** мәгънәсендә – әстерхан сөйләшендә, *таңнай* варианты шул ук мәгънәдә – тара сөйләшендә, *морт* сүзе **мыек** мәгънәсендә – тубыл һәм тара сөйләшләрендә, *шыгай* сүзе **балык яңагы**, **саңагы** мәгънәсендә – себер диалектларында, шул ук мәгънәдә *аткак* сүзе яүштәчат сөйләшендә генә сакланып калган. **Чәнчә бармак** чыганак бармак мәгънәсендә – пермь, түбән, тубыл, **терсәк** мәгънәсендә – нугай, каракалпак, казакъ телләре сөйләшләрендә, *соганак* сүзе терсәк, терсәктән кул чугына кадәр өлешне белдергән мәгънәдә – алтай, чыгтай телләрендә, башкорт телендә **терсәкне** белдергән *сыганак* сүзендә очрый.

Шулай итеп, хәзерге татар телендә кулланыла торган соматизмнарның синонимнары булган борынгы тән әгъзалары атамаларының күбесе халык авыз иҗатында гына сакланып калган. Кайберләре диалектларда очрый, әмма әдәби телдә гомумән кулланылмый.

### Әдәбият

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 677 с.

Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 254 б.

*Рамазанова Д. Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан, 2013. 364 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. III т. Казан: ТӘҺСИ, 2017. 744 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 460 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 383 б.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Ю. Хисияма***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ III ЗАТ ТАРТЫМ КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН ӨЙРӘНҮГӘ КАРАТА

В данной статье рассматриваются конструкции принадлежности татарского языка, в которых отсутствует суффикс принадлежности третьего лица. Предыдущие исследования утверждают, что суффикс принадлежности третьего лица является обязательным в конструкциях принадлежности татарского языка. Согласно предыдущим исследованиям по турецкому языку, конструкции принадлежности, в которых отсутствует суффикс принадлежности третьего лица, приемлемы, когда существует определенная семантическая связь между существительным родительного падежа и главным существительным. В этой статье я утверждаю, что в татарском языке, в отличие от турецкого, конструкции принадлежности, в которых отсутствует суффикс принадлежности третьего лица, обычно неприемлемы, независимо от семантической связи между существительным в родительном падеже и главным существительным. Анализ нескольких примеров, извлеченных из веб-корпуса, показывает, что такие конструкции в основном встречаются в устной речи и они могут не выражать смысла владения. Наши данные с чувашского языка позволяют предположить, что возможность использования таких конструкций варьируется среди тюркских языков.

**Ключевые слова**: татарский язык, турецкий язык, чувашский язык, категория принадлежности, аффикс принадлежности третьего лица.

This article deals with Tatar genitive possessive constructions which lack the 3rd person possessive suffix. Previous research argue that the 3rd person possessive suffix is obligatory in Tatar possessive constructions. According to previous research on Turkish, genitive possessive constructions which lack the 3rd person possessive suffix are acceptable when there is a certain semantic relationship between a genitive noun and a head noun. In this article, I argue that in Tatar, unlike Turkish, genitive possessive constructions which lack the 3rd person possessive suffix are generally inacceptable, regardless of a semantic relationship between a genitive noun and a head noun. The analyses of the few examples extracted from the web-corpus show that such constructions are mainly found in spoken language and they may not express the meaning of possession. Our data from Chuvash language suggest that the possibility of the use of such constructions is varied among Turkic languages.

**Keywords:** Tatar language, Turkish language, Chuvash language, genitive possessive construction, 3rd person possessive suffix.

Татар теленең тартым конструкцияләрендәге III зат тартым кушымчасын галимнәр, I яки II затныкыннан аермалы буларак, төшеп калмый дип аңлата. Ләкин, без тикшергәнчә, татар телендә дә андый конструкция сирәк булса да күзәтелә. Татар теле кебек үк төрки телләргә кергән һәм татар теленә караганда күбрәк тикшерелгән төрек теле турындагы фәнни мәкаләләрдә, III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкциясе, аның нинди очракларда барлыкка

килүе һәм нинди мәгънәләр белдерүе турында җентекләп язылган. Бу мәкаләдә без, татар теленең III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкциясенең үзенчәлекләре төрек теленекенә туры киләмеюкмы икәнен, аеруча иялек килешендәге исем белән тартымсыз исем арасындагы семантик бәйләнешкә игътибар итеп анализлауны максат итеп куябыз. Башта без татар һәм төрек телләренең III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкциясе турындагы тасвирларны барлыйбыз. Аннары тикшерү ысулларына һәм нәтиҗәләренә күзәтү ясыйбыз һәм иң азакта йомгак ясыйбыз.

Татар теленең III зат тартым конструкцияләре турында В.Н. Хангилдин (1959): «III зат тартымы формасының төшенчәсе гаять киң һәм билгесез. Шунлыктан ул һәрвакыт билгеләнүгә мохтаҗ. Шуңа күрә III зат тартымы формасындагы сүз, гадәттә, үзенең аергычы һәм кушымчасы белән сөйләнелә. Аның кушымчасын кыскартып яки аергычын төшереп куллану бары ул формадагы сүзләр сөйләмдә тиңдәш кисәк булып яки тезмә кушма җөмлә кисәге булып килү шартларында гына очрый», – дип язып, үрнәк бирә: ***Безнең республикабызның барлык колхоз һәм совхозлары*** *язгы чәчү эшенә зур хәзерлек алып баралар* [Хангилдин, 1959, б. 80–81].

Ф.М. Хисамова (2006), «I, II затта, берлектә һәм күплектә кушымчалар төшеп калып, тартым мәгънәсен иялек килешендәге алмашлыклар белән дә белдереп була (аналитик ысул)» дип язып, *минем китап*, *синең китап* кебек үрнәкләрне бирә. Әмма бу ысулның III затта мөмкин түгеллеген искәртеп куя [Хисамова, 2006, б. 102].

B. Öztürk һәм E.E. Taylan (2016) төрек теленең тартымлы конструкциясен «genitive possessive constructions (GP)» – «иялек тартым конструкциясе», тартымсыз конструкциясен «possessive free genitives (PFG)» – «тартымсыз иялекләр» дип атый. Авторлар, C. Vikner һәм P.A. Jensen (2002) хезмәтендә тасвирланган, инглиз теленең тартым конструкциясендәге дүрт лексик мөнәсәбәткә, ягъни «inherent» («хас» дип тәрҗемә ителә: кемгә, нәрсәгә караганлыгы үзенә хас булган исемнәр, мәсәлән, «апа» кебек туганлык атамалары, «исем» кебек мөнәсәбәтле исемнәр һәм фигыльдән ясалган исемнәр бу мөнәсәбәткә ия), «part-whole» («өлеш-бөтен» дип тәрҗемә ителә: тән әгъзалары, «тәгәрмәч» кебек берәр әйбергә буйсынмаган состав өлешләр, һәм «кырый» кебек берәр әйбергә буйсынган состав өлешләр бу мөнәсәбәткә ия), «agentive» («агентивлык» дип тәрҗемә ителә: «рәсем» кебек, аны ясаган кеше, ягъни эшнең башкаручысы булган исемнәр бу мөнәсәбәткә ия), «control» («контроль» дип тәрҗемә ителә: «машина» кебек, кемнеңдер әйбере булып, аның иясе аны теләсә ничек кулланырга мөмкин булган исемнәр бу мөнәсәбәткә ия) мөнәсәбәтләренә нигезләнеп аңлата. Авторлар карашынча, төрек телендә, тартым конструкциясендәге ике исем арасындагы мөнәсәбәт «хас» яки «(буйсынган) өлеш-бөтен» булса, ягъни икенче исем лексик яктан «күчемле (транзитив)» булган (ягъни, иялек килешендәге исемгә мөхтаҗ булган) очракта

тартымсыз конструкция мөмкин түгел [Öztürk һәм Taylan, 2016, б. 90–92].

(1) a. **Öğretmen-in* *hala* хас: туганлык
укытучы-ның апа
«Укытучының апасы»
b. **makale-nin* *başlık* хас: мөнәсәбәтле
мәкалә-нең исем
«мәкаләнең исеме»
c. **Bina-nın* *yıkım* хас: фигыльгә бәйле
бина-ның сүтелү
«Бинаның сүтелүе»
(2) a. *Çocuğ-un* *burun* өлеш-бөтен: тән әгъзалары
бала-ның борын
«Баланың борыны»
b. *Araba-nın* *lastik* өлеш-бөтен: буйсынмаган состав өлеш
машина-ның тәгәрмәч
«Машинаның тәгәрмәче»
c. **Masa-nın* *kenar* өлеш-бөтен: буйсынган состав өлеш
өстәл-нең кырый
«Өстәлнең кырые»
(3) *Çocuğ-un* *şiir* агентивлык
бала-ның шигырь
«Баланың шигыре»
(4) *Kadın-ın* *araba* контроль
хатын-ның машина
«Хатынның машинасы»

B. Öztürk һәм E.E. Taylan (2016: 92) тартымсыз конструкциядә дә күчемле исем очравын, шул очракта икенче исемнең «күчемле» мәгънәсе мөмкин түгеллеген искәртеп, түбәндәге үрнәкләрне бирә [Öztürk and Taylan, 2016, б. 92].

(5) a. *Kadın-ın* *katil-i* тартымлы
хатын-ның катыйль-е
«Хатынны үтергән катыйль»
b. *Kadın-ın* *katil* тартымсыз
хатын-ның катыйль
«Хатын эшкә алган катыйль»

E.A. Csató (2019) төрек теленең тартымсыз конструкциясен «non-canonical possessives», ягъни «каноник булмаган тартымнар» дип атый һәм III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкциясенең үрнәген бирә:

(6) *Mehmet'-in* *karı*
Мәхмәт-нең хатын
«Мәхмәтнең хатыны»

E.A. Csató (2019) аңлатуынча, тартымлы конструкция белдергән семантик мөнәсәбәтләр: «body-part/whole-part» (тән әгъзалары/бөтен-өлеш), «kinship» (туганлык), «ownership» (ия булу), «part-of relation» (өлеш мөнәсәбәте), «location» (урын) мөнәсәбәтләре арасында, тартымсыз конструкция «өлеш мөнәсәбәтен» белдерә алмый, «тән әгъзалары/бөтен-өлеш» мөнәсәбәтен сирәк кенә белдерә, «ия булу» һәм «туганлык» мөнәсәбәтләрен, мәгънә ягыннан чикләнгән булса да, «урын» мөнәсәбәтен дә, белдерә ала дип тасвирлый [Csató, 2019, б. 91–92].

Туганлык
(7) *Hasan'-ın* *Ali*
Хәсән-нең Гали
«Хәсәннең улы Гали»

Ия булу
(8) *Ali'-nin* *araba*
Гали-нең машина
«Галинең машинасы»

Өлеш мөнәсәбәте
(9) **çocuk-lar-ın* *üç*
бала-лар-ның өч
«балаларның өчесе»

Урын
(10) *park-ın* *ora-da*
парк-ның анда
«паркның тирәсендә»

Күренгәнчә, татар теленең тартым конструкцияләрендәге III зат тартым кушымчасы төшеп калмый дип аңлатылса, төрек теле турындагы фәнни мәкаләләрдә III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкциясе, аның нинди очракларда барлыкка килүе һәм нинди мәгънәләр белдерүе турында җентекләп язылган. Ләкин, без тикшергәнчә, татар телендә дә андый конструкция сирәк булса да күзәтелә. Без татар теленең III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкциясенең үзенчәлекләре төрек теленекенә туры киләме-юкмы икәнен, аеруча иялек килешендәге исем белән тартымсыз исем арасындагы семантик бәйләнешне игътибар итеп анализладык. Тикшеренүләребезне без информант (1973 елда Казанда туган ир кеше) һәм «Татар теленең язма корпусы» ярдәмендә башкардык.

Безнең информант (1–4) һәм (7–10) үрнәкләренең татарчасы тартымсыз булса, барысы да «хата» була дип белдерде, дөрес булсын өчен, тартым кушымчасы булырга тиеш. Йолдыз билгесе (*) булган җөмләләр «хата» дип бәяләнде.

(11) a. **укытучының апа* хас: туганлык
*укытучының апасы*
b. **мәкаләнең исем* хас: мөнәсәбәтле
*мәкаләнең исеме*
c. **бинаның сүтелү* хас: фигыльгә бәйле
*бинаның сүтелүе*
(12) a. **баланың борын* өлеш-бөтен: тән әгъзалары
*баланың борыны*
b. **машинаның тәгәрмәч* өлеш-бөтен: буйсынмаган состав өлеш
*машинаның тәгәрмәче*
c. **өстәлнең кырый* өлеш-бөтен: буйсынган состав өлеш
*өстәлнең кырые*

| | | |
|---|---|---|
| (13) | **баланың шигырь*<br>*баланың шигыре* | агентивлык |
| (14) | **хатынның машина*<br>*хатынның машинасы* | контроль |

Туганлык
(15) **Айгөлнең Марат*
*Айгөлнең Мараты*

Ия булу
(16) **Айгөлнең машина*
*Айгөлнең машинасы*

Өлеш мөнәсәбәте
(17) **балаларның өч*
*балаларның өчесе*

Урын
(18) **паркның алда*
*паркның алдында*

Шулай да, «Татар теленең язма корпусы» сайтыннан тартымсыз үрнәкләр табылды. Корпустан җыелган җөмләләрнең бер өлешен иялек килешендәге исем белән тартымсыз исем арасындагы семантик бәйләнешләр белән бергә күрсәтәбез. Кыек сызык билгесенең сулдагысы – B. Öztürk and E.E. Taylan (2016), уңдагысы E.A. Csató (2019) кулланган мөнәсәбәт исеме. Әлеге хезмәтләрдә кулланылмаган мөнәсәбәтне исә, «-» билгесе белән билгеләдек.

Контроль / Ия булу
(19) ***Аның кием** шәп.*

Хас: туганлык / Туганлык
(20) *Полицейскийлар **аның** **хатын**ның фотосурәтен социаль челтәрләрдән алган.*

Өлеш-бөтен / Тән әгъзалары
(21) ***Аның кул**да киләчәк!*
(22) ***Гөлсараның күзләр** уйнады.*

- / Урын
(23) *Кайсы ир-ат башын имәс **аның ал**да.*
Хас: фигыльгә бәйле / -
(24) ***Дусларның караш** үткәр, адым озын, зиһен шәп!*

Күренгәнчә, төрле мөнәсәбәтләрне белдергән тартымсыз конструкцияләр табылды. Ләкин аларның I яки II затныкына караганда бик сирәк очравын искәртеп куярга кирәк. Информантыбыз әйтүенчә, алар – гадәттә сөйләмә телдә очраган, әдәби нормаларга туры килмәгән формалар. Аның фикеренчә, мәсәлән, (19) җөмләсенең мәгънәсе «Аның хәле шундый: кием шәп! (аның киеме түгел, ул кигән кием шәп)» була. Шулай ук, (22) җөмләсенең мәгънәсе дә «Гөлсараның хәле шундый: күзләр уйнады» була. Димәк, тартымсыз конструкциядә тартым мәгънәсе юк дәрәҗәсендә: алар иялек килешендәге исемнең әйбере турында түгел, иялек килешендәге исемнең хәле турында аңлатканда кулланыла дип әйтергә мөмкин.

Башка төрки телләргә күз салсак, III зат тартымсыз конструкцияләрнең кулланылу мөмкинлеге аерылып тора. Мәсәлән, чуваш теле

буенча түбәндәге нәтиҗәләр алынды. Информантыбыз – 1999 елда Чуваш Республикасында туган ир кеше. Йолдыз билгесе (*) булган җөмләләр «хата», сорау билгесе (?) булган җөмләләр «сәер» дип бәяләнде.

| | | | |
|---|---|---|---|
| (25) a. | ?*вĕрентекен-ĕн* | *анне* | хас: туганлык |
| | укытучы-ның | әни | |
| | *вĕрентекен-ĕн* | *амăшĕ* | |
| | укытучы-ның | әнисе | |
| b. | **статья-н* | *ят* | хас: мөнәсәбәтле |
| | мәкалә-нең | исем | |
| | *статья-н* | *яч-ĕ* | |
| | мәкалә-нең | исем-е | |
| (26) a. | **ача-н* | *сăмса* | өлеш-бөтен: тән әгъзалары |
| | бала-ның | борын | |
| | *ача-н* | *сăмс-и* | |
| | бала-ның | борын-ы | |
| b. | **машинă-н* | *шина* | өлеш-бөтен: буйсынмаган состав өлеш |
| | машина-ның | тәгәрмәч | |
| | *машинă-н* | *шин-и* | |
| | машина-ның | тәгәрмәч-е | |
| c. | **сĕтел-ĕн* | *хĕрĕ* | өлеш-бөтен: буйсынган состав өлеш |
| | өстәл-нең | кырый | |
| | *сĕтел* | *хĕрр-и* | |
| | өстәл-нең | кырые | |
| (27) | ?*ача-н* | *сăвă* | агентивлык |
| | бала-ның | шигырь | |
| | *ача-н* | *сăвв-и* | |
| | бала-ның | шигыр-е | |
| (28) | ?*хĕрарăм-ăн* | *машина* | контроль |
| | хатын-ның | машина | |
| | *хĕрарăм-ăн* | *машинн-и* | |
| | хатын-ның | машина-сы | |

Туганлык

| | | |
|---|---|---|
| (29) | **Сашă-н* | *Иван* |
| | Саша-ның | Иван |
| | *Сашă-н* | *Иван-ĕ* |
| | Саша-ның | Иван-ы |

Ия булу

| | | |
|---|---|---|
| (30) | ?*Сашă-н* | *машина* |
| | Саша-ның | машина |
| | *Сашă-н* | *машинн-и* |
| | Сашаның | машина-сы |

Өлеш мөнәсәбәте

| | | |
|---|---|---|
| (31) | **ача-сен* | *виççĕ* |
| | бала-ларның | өч |
| | *(нумай) ача-ран* | *виçç-ĕшĕ* |
| | (күп) бала-дан | өч-есе |

Урын

| | | |
|---|---|---|
| (32) | ?*шкул-ăн* | *ум-ра* |
| | мәктәп-нең | ал-да |
| | *шкул* | *ум-ĕн-че* |
| | мәктәп | алд-ын-да |

Күренгәнчә, чуваш телендә дә III зат тартымсыз конструкцияләрнең грамматик хата яки сәер дип кабул ителүе, тартымлы фор-

малар дөресрәк булуы ачыкланды. Берсе дә дөрес дип табылмавы белән – төрек теленнән, кайберәүләре хата түгел, ә сәер дип бәяләнүе белән татар теленнән аерылып тора. Чуваш теленең онлайн-корпусы «Чӑваш чӗлхин икчӗлхеллӗ ҫӳпҫи» сайтыннан тартымсыз үрнәкләр табылды. Корпустан җыелган җөмләләрнең бер өлешен иялек килешендәге исем белән тартымсыз исем арасындагы семантик бәйләнешләр белән бергә күрсәтәбез.

Хас: туганлык / Туганлык

(33) *Унӑн ывӑл-сем-пе хӗр-сем ҫурал-нӑ.*
анын ул-лар-белән кыз-лар ту-ган.
«Аның уллары белән кызлары туган».

Хас: фигыльгә бәйле / -

(34) *Ҫав предмет-па унӑн ҫитӗнӳ-сем чылай.*
шул предмет-белән аның казаныш-лар шактый
«Шул предмет буенча аның казанышлары шактый».

Шунысы игътибарга лаек: икесе дә төрек телендә тартымсыз конструкция белән мөмкин булмаган мөнәсәбәтләрне белдерә. Моннан чыгып, III зат тартымсыз конструкциянең кулланылу мөмкинлеге,телгә карап аерылып тора, дип әйтә алабыз.

Тикшерү нәтиҗәләреннән чыгып, түбәндәгечә йомгак ясый алабыз: төрек теленнән аермалы буларак, татар телендә, иялек килешендәге исем белән тартымсыз исем арасындагы семантик бәйләнеш нинди булуга карамастан, III зат тартым кушымчасы булмаган тартым конструкцияләре гомумән грамматик хата дип кабул ителә. Алар күбрәк сөйләм телгә хас һәм тартым мәгънәсен белдермәскә мөмкин. Төрек, татар һәм чуваш телләрен чагыштыргач, телгә карап, III зат тартымсыз конструкцияләрнең кулланылу мөмкинлегенең аерылып торуы ачыкланды.

**Әдәбият**

*Csató E.A.* On Turkish non-canonical possessives. L. Johanson et al. (eds.) *Possession of languages in Europe and North and Central Asia*, 2019. 85–102. Amsterdam: John Benjamins.

*Öztürk B., E.E. Taylan.* Possessive constructions in Turkish. *Lingua* 182. 2016. 88–108.

*Vikner C.* and *P.A. Jensen.*A Semantic Analysis of the English Genitive. Interaction of Lexical and Formal Semantics. *Studia Linguistica* 56. 2002. 191–226.

Татар теленең язма корпусы (http://corpus.tatfolk.ru/index_tt.php)

*Хангилдин В.Н.* (1959) Татар теле грамматикасы. Казан. Татар. кит. нәшр.

*Хисамова Ф.М.* (2006) Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф.

Чӑваш чӗлхин икчӗлхеллӗ ҫӳпҫи (http://corpus.chv.su/)

***Хисияма Юто,***
*Токио чит телләр университеты аспиранты*

УДК 811.512.145

***М.Р. Сәйхунов,***
***А.М. Хөсәенова,***
***Р.Р. Хөсәенов***

# МӘГЪНӘДӘШ СҮЗЛӘР ТАБУДА НЕЙРОН ЧЕЛТӘР МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

В работе рассматривается применение векторов слов, обученных на текстовом корпусе с помощью технологии на основе нейронных сетей word2vec, для поиска близких по значению слов, а также для решения аналогий вида «X – Y, Z – ?».

**Ключевые слова:** татарский язык, корпус, нейронные сети, word2vec, векторы слов.

The work discusses the use of word vectors trained on the text corpus using the word2vec technology based on neural networks to search for words that are close in meaning, as well as to solve analogies of the form «X – Y, Z – ?».

**Keywords:** Tatar language, corpus, neural networks, word2vec, word vectors.

**Тел гыйлеме кысаларында нейрон челтәрләр.** Соңгы елларда компьютер лингвистикасы өлкәсендә күпсанлы яңа технологияләр кулланыла башлады. Шуларның иң киң таралганнарыннан нейрон челтәрләрне атарга мөмкин. Аларның башка технологияләрдән төп аермасы, кагыйдәләр белән баетылуда, программалаштырылуда түгел, ә «өйрәтелү» принцибына корылуларында чагылыш таба. Шуңа күрә нейрон челтәрләр башта зур мәгълүмат базасында «өйрәтелә» һәм бу халәттә яңа мәгълүматны эшкәртә, аңа карата «фараз кыла» ала.

Әлеге эшкә нейрон челтәрләр ярдәмендә өйрәтелгән сүз векторлары җәлеп ителә, ягъни текстлардагы һәр сүзгә чын саннардан торган n-үлчәмле вектор (n-dimensional vector of real numbers) билгеләнә. Мәсәлән, әгәр n=3 булса, *«йорт»* сүзенә [0.5, 2.6, 1.5] кыяфәтендәге вектор туры килергә мөмкин. Сүзләрнең болай бирелеше лингвистиканың «Дистрибутив семантика» [Дистрибутивная семантика] өлкәсендә кулланыла. Моннан тыш сүз векторлары үзләрен телне табигый рәвештә эшкәртү [Natural language processing] өлкәсенә караган күпсанлы проблемаларны хәл итүдә дә нәтиҗәле күрсәтеләр (мәсәлән, машина тәрҗемәсе, текстның тематикасын яки тональлеген [Анализ тональности текста] билгеләү һ. б.).

**Сүз векторларының үзенчәлеге һәм файдасы.** Сүз векторлары идеясенең асылы *«охшаш тирәлектә очраган сүзләр якын мәгънәгә ия»* дигән гипотезага нигезләнә. Димәк текстларның зур күләмле тупланмасы булса, һәр сүзгә аерым вектор туры китерергә мөмкин. Якын мәгънәле сүзләргә туры килә торган әлеге векторлар n-үлчәмле пространствода бер-берсенә якын торырга тиеш булалар.

Алда әйтеп киткәнчә, соңгы вакытта бу мәсьәләне чишүдә нейрон челтәрләр кулланыла. Шуларның берсе, әлеге эштә карала торган word2vec моделе, сүзләрнең ихтималлы контекстын фаразларга өйрәтелгән гади нейрон челтәр аша сүз векторларын булдыра ала.

Шушы юл белән тупланган векторлар кайбер кызыклы һәм файдалы үзенчәлекләргә ия. Алар сүзләр арасындагы семантик һәм синтаксик мөнәсәбәтләрне таба һәм әлеге мөнәсәбәтләрнең ныклыгын билгели. Мондый мөмкинлекләрнең кайберләре алга таба 4 бүлектә карала.

**Косинус охшашлыгы төшенчәсе.** Оригиналь мәкаләдә word2vec моделендә ике төрле архитектура тәкъдим ителә [Tomas Mikolov]. Аларның берсендә (Skip-Gram) нейрон челтәр сүзнең ихтималлы контекстын фаразларга, икенчесендә (CBOW) контекст буенча ихтималлы сүзне ачыкларга өйрәтелә. Контекст бу очракта әлеге сүзнең уң һәм сул ягында килә торган һәм гадәттә уннан артмаган берничә күрше сүзне белдерә. Әлеге эштә без CBOW архитектурасын кулланабыз.

Word2vec векторлары рәвешендә бирелгән сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне анализлау өчен, *косинус охшашлыгы* [Cosine similarity] төшенчәсенә мөрәҗәгать итәләр. Ул – векторлар арасындагы почмакның косинусын үлчәү аша ике векторның якынлыгын билгели торган күрсәткеч. Почмак кечерәк булган саен, векторлар бер-берсенә якынрак. Шулай итеп, әлеге почмакның косинусы 1 гә якынрак булып чыга.

Әгәр векторлар бер-берсенә каршы юнәлгән булса, косинус охшашлыгы -1 гә тигез булачак. Әгәр векторлар ортогональ булса, ягъни алар арасындагы почмак 90° тәшкил итсә, косинус охшашлыгы 0 гә тигез булачак. Әгәр векторлар бер тарафка юнәлгән булса, косинус охшашлыгы 1 гә тигез булачак. Шулай итеп, саннар арасындагы күрсәткечләр сүзләрнең төрле дәрәҗәдәге якынлыгы турында сөйли.

Әлеге күрсәткечне кулланып, аерым бер сүз векторына иң якын векторларны, ягъни күрше сүзләрне табарга (4.1 пункты), ике сүзнең охшашлык дәрәҗәсен бәяләргә (4.3 пункты) мөмкин. Бу күрсәткеч шулай ук 4.2 пунктындагы аналогияләрне төзүдә дә кулланыла, ләкин монда исәпләүләр бераз катлаулырак. Алар векторлар өстендәге арифметик гамәлләргә нигезләнә. Мәсәлән, *«җәй – эссе, ә кыш – ?»* аналогиясен алсак, *«?»* урынында без «*суык*» яки «*салкын*» кебек сүз булырга тиешлеген аңлыйбыз. Бу типтагы мәсьәләләрне автоматик рәвештә сүз векторлары аша чишеп була. Моның өчен без түбәндәге векторны исәпләп чыгара алабыз:

X = вектор(«*эссе*») – вектор(«*җәй*») + вектор(«*кыш*»).

Шуннан соң сүз векторлары пространствосында без X векторына иң якынын эзлибез дә, шуны җавап («*?*») буларак кайтарабыз. Әгәр сүз векторлары җитәрлек дәрәҗәдә яхшы өйрәтелгән булса, без дөрес җавапка ирешәчәкбез (бу очракта «*суык*» сүзе).

**Word2vec моделен корпус нигезендә куллану.** Word2vec моделе нигезендә сүз векторларын өйрәтү өчен аерым ике корпус алынды:

– күләме 15 миллион сүз тәшкил иткән һәм тулысынча матур әдәбият әсәрләренә корылган «Татар матур әдәбияты корпусы» [Татар матур әдәбияты корпусы];

– 356 миллион сүздән торган һәм үз эченә төрле жанрлардагы, төрле стильләрдәге текстларны алган «Татар теленең язма корпусы» [Татар теленең язма корпусы].

Корпуслардагы мәгълүмат ике формада әзерләнде: оригиналь (ягъни сүзформалар буларак) һәм леммалар рәвешендә. Башта автоматик рәвештә тотрыклы тезмәләр табылды. Шуннан соң әлеге сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләр билгеләнде.

Исәпләүләрне башкару өчен, Google компаниясе тарафыннан эшләнгән word2vec программасы кулланылды [Word2vec].

Төзелгән система әлеге ике корпус сайтында да «Тезаурус» исеме белән урнаштырылды. Ул түбәндәге өч гамәлне башкарырга мөмкинлек бирә:

**1. Мәгънәдәш сүзләр.** Әлеге функция мәгънәдәш сүзләрне эзләргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, «*китап*» сүзенең косинус охшашлыгы буенча иң якын очраклары буларак түбәндәгеләр табыла. Мисаллардагы саннар һәр сүзнең «*китап*» сүзенә карата исәпләнгән косинус охшашлыгын күрсәтә:

***китап** – 0.752229 китаб, 0.682486 мең_данә_тираж, 0.672231 китапчык, 0.671023 том_том, 0.667688 фәнни_популяр_китап, 0.65399 китап_брошюра, 0.645721 иман_нәшрият, 0.643474 фәнни_популяр, 0.64313 җыентык, 0.634892 данә_тираж, 0.634619 энциклопедик, 0.634452 гарәп_шрифтында, 0.6336 әлифба_китаб, 0.6328 калын_калын_китап, 0.63182 библиографик_күрсәткеч, 0.631582 күптомлы, 0.63082 томлы, 0.628358 библиографик, 0.625116 календарьларны, 0.625025 томлы_китап, 0.624684 китап_киштә, 0.622028 борынгы_кульязма, 0.620939 мәгариф_нәшрият, 0.620155 фәнни_монография, 0.619905 биш_томлык, 0.616826 кульязма, 0.616399 аудиокитаплар, 0.616167 күптомлык, 0.613371 мең_тираж, 0.612622 фәнни_фәнни_популяр.*

Алдагы графикта табылган сүзләрнең «*китап*» сүзенә карата гына түгел, ә сыеграк төс белән бирелгән сызыклар аша үзара мөнәсәбәтләре дә чагылыш таба (1 нче график).

Икенче мисал буларак «кыр» сүзен карап үтик (2 нче график):

***кыр** – 0.937906 көтүлек, 0.926447 чулман, 0.915009 көтү_көтү, 0.902445 итил, 0.901285 җәйләү, 0.901143 ерганак, 0.901018 җәйлә, 0.899437 буа, 0.899136 кышлау, 0.897992 аръягында, 0.895145 кырында, 0.894153 ялан, 0.893301 сөр, 0.887688 елга, 0.886665 үзән, 0.88585 чулман_буй, 0.883478 елга_буй, 0.88304 иген_кыр, 0.88128 киң_дала, 0.879818 алан, 0.879712 үзәнлек, 0.87778 каберлек, 0.877585 баткак, 0.876186 тикле, 0.875428 ташу, 0.875172 туздырып, 0.873972 җире, 0.873611 казы, 0.872944 нократ, 0.871216 тау_итәк.*

Түбәндәге мисалда бирелгән ике сүзгә карата уртак мәгънәдәш сүзләр табыла. Аның өчен ике сүзнең векторлары кушыла, һәм бу куш-




1 нче график

ма векторга иң якын сүз векторлары туплана (3 нче график). Шунысы кызык, табылган нәтиҗәләр исемлегенең башында әлеге ике сүз өчен дә уртак булган сыйфатларны (*«тимер»нең каты, ә «кәгазь»нең юка булуы*) чагылдырган сүзләр урнаша: *катыргы, картон, калай*:

***тимер, кәгазь*** *– 0.611537 металл, 0.610027 катыргы, 0.609618 кәгазь_кисәк, 0.593739 картон, 0.590721 калай, 0.568972 тимер_кисәк, 0.567635 кәгазъ, 0.560675 арткы_яг, 0.560555 пластмасса, 0.557492 пластмасс, 0.556839 авторучка, 0.554691 тартмачык, 0.553912 ватман, 0.552176 карандаш, 0.551499 дүрт_бөкләә, 0.550077 күкрәк_кесә, 0.546048 өстәл_тартма, 0.545314 сырлап, 0.54462 пыяла, 0.543587 акбур, 0.54297 тимерчыбык, 0.541497 мөһерлә, 0.540843 төргәклә, 0.537996 тартма, 0.536848 тоткыч, 0.535645 арматура, 0.534824 лупа, 0.534338 тәрәзә_рам, 0.533764 сырлы, 0.53317 конвертлар.*




2 нче график

Ә «юрган, караватъ» пары өчен иң якын сүзләр буларак түбәндәгеләр табыла (4 нче график):

***юрган, караватъ*** *– 0.731421 сәке, 0.729877 йомшак_мендәр, 0.7238 одеял, 0.715946 кушетка, 0.715095 ятак, 0.711984 тимер_караватъ, 0.710837 ак_җәймә, 0.702655 ястык, 0.699629 яткырды, 0.698992 җәймә, 0.692825 мендәр, 0.688617 чыбылдык, 0.688601 раскладушка, 0.683847 караватъ_кырый, 0.682108 диван_караватъ, 0.680681 матрас, 0.673922 чишенде, 0.67388 түшәк, 0.672862 матрац, 0.667898 йомшак_түшәк, 0.666311 тәрәзә_пәрдә, 0.665535 түр_сәке, 0.665025 идән_келәм, 0.663881 тумбочка, 0.663878 шифоньер, 0.663257 кроватька, 0.660866 юрган_ябын, 0.660195 мамык_мендәр, 0.659965 тапчан, 0.659901 идән_палас.*

**2. Төшенчәләр аналогиясе.** Әлеге функция «*X – Y, Z – ?*» арифметик аналогиясе нигезендә нәтиҗәне табарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, «*эт – ул хайван, ә алма – ул нәрсә?*» һ. б. очракларны карап үтик:

***эт – хайван, алма*** *– 0.873757 җимеш, 0.862394 гөл, 0.851239 үсемлек, 0.848565 шифалы, 0.847187 искитмәле, 0.834528 бәрәкәт-*




3 нче график

*ле, 0.833419 күрке, 0.827192 чәчәк, 0.815759 татып_кара, 0.815128 пакь, 0.810416 чәчкә, 0.808018 гөлбакча, 0.80672 мул, 0.806341 тансык, 0.800148 йок, 0.798206 шытып_чык, 0.795633 орлык, 0.793072 сабак, 0.786472 хозурлык, 0.779775 тиңлә, 0.779583 гөл_чәчәк, 0.778158 яралган, 0.775153 татлы, 0.772041 бөре, 0.770986 матурлык, 0.757603 кызыктыр, 0.754347 сугар, 0.754283 аклык, 0.748151 туклыклы, 0.747967 ямьле;*

***эт – хайван, алмагач** – 0.555482 үсемлек, 0.532633 агач_куак, 0.522246 чыршы_нарат, 0.520003 җиләк_җимеш_куак, 0.513412 декоратив_үсемлек, 0.504221 җимеш, 0.501679 имән_юкә, 0.492185 яфраклы_агач, 0.491171 чия_слива, 0.490028 җиләк_җимеш, 0.489917 үсенте, 0.48975 алмагач_чия, 0.489199 дару_үлән, 0.48613 агач_куаклык, 0.484642 агач_үсенте, 0.479097 нарат_чыршы, 0.478646 ылыслы, 0.478233 ылыслы_агач, 0.477539 куак_үсенте, 0.474722 үсенте_утырт, 0.474009 слива, 0.470146 тәҗрибәле_бакчачы, 0.46699 чәчәк_бөрелән, 0.466524 алмагач_груша, 0.462612 җимеш_агач_куак, 0.462331 каен, 0.460904 бакча_җиләк, 0.458814 каен_нарат, 0.458287 кәлшә, 0.457976 агач;*




4 нче график

***эт – хайван, карга*** *– 0.529546 кош, 0.452673 җәнлек_кош_корт, 0.45135 хайван_кош_корт, 0.424303 кош_оя, 0.417403 күз_кар_чукы, 0.417002 киек_кош, 0.415236 кош_корт_хайван, 0.413669 җәнлек_җанвар, 0.408859 бөҗәк, 0.407776 тереклек_ия, 0.403236 җәнлек_кош, 0.40039 ерткыч_кош, 0.394989 дуңгыз_асрау, 0.394723 бүдәнә, 0.388843 кыргый_хайван, 0.387124 кош_җәнлек, 0.384505 чыпчык, 0.384216 җәнлек, 0.382977 бытбылдык, 0.380001 күчмә_кош, 0.379483 карр_карр, 0.379233 зарарлы_бөҗәк, 0.379104 ерткыч_хайван, 0.376883 кыргый_җәнлек, 0.376299 мәхлукат, 0.374626 каргыш, 0.371003 җәнлек_хайван, 0.368932 хайван_үсемлек, 0.368489 кош_корт, 0.366938 үрдәк_каз;*

***җир_шар – планета, кояш*** *– 0.925748 йолдыз, 0.911985 якты, 0.909303 балкы, 0.897471 яктылык, 0.879299 болыт_капла, 0.878039 томанлы, 0.872683 болыт, 0.868168 нур_сип, 0.863357 балкыш, 0.862675 нур, 0.858728 яктыр, 0.857401 томан, 0.855835 сүн, 0.852218 ап_ачык, 0.850376 офык, 0.848987 кояш_нур, 0.848596 аяз, 0.844198 зәңгәр_күк, 0.843785 күк, 0.842158 сүрән, 0.838735 сихри, 0.83776 кояш_балкы, 0.83621 нурлан, 0.826901 болытлы, 0.826159 яшәр, 0.825893 күзлә, 0.820815 балкытып, 0.818787 нурлы, 0.818328 алланып, 0.818247 җансыз;*

***умарта_корт – бал, сыер*** *– 0.560947 литр_сөт, 0.52204 сөт_сау, 0.512419 килограмм_сөт, 0.508482 кг_сөт_сау, 0.508447 майлылык, 0.503198 мең_килограмм_сөт, 0.49752 литр_сөт_сау, 0.496192 сөт, 0.482043 тонна_сөт, 0.479899 сау_сыер, 0.477969 сыер_сөт_сау, 0.474186 сыер_тәүлек, 0.474164 сөт_литр, 0.470264 көнлек_савым, 0.469839 тәүлеклек_савым, 0.468629 тана, 0.467971 килограмм_тәшкил, 0.466081 савым, 0.463965 артык_сөт_сау, 0.463271 сөт_майлылык, 0.460077 урта_килограмм_сөт, 0.45934 шикәр_ком, 0.459334 эремчек, 0.458588 сыер_сау, 0.458409 бозаула_тана, 0.457793 сыер_савым, 0.457119 майлылык_процент, 0.45479 сыер_көнлек_савым, 0.453182 сыер_сөт, 0.452489 тонна_сөт_сау.*

**3. Ике сүз арасындагы мәгънәви якынлык күрсәткече.** Әлеге функция югарыда каралган гамәлләрнең нигезендә ята. Ул ике сүзнең мәгънә ягыннан якынлыгын косинус охшашлыгы формуласы нигезендә исәпләп чыгара:

$$\text{similarity} = \cos(\theta) = \frac{\mathbf{A} \cdot \mathbf{B}}{\|\mathbf{A}\|\|\mathbf{B}\|} = \frac{\sum_{i=1}^{n} A_i B_i}{\sqrt{\sum_{i=1}^{n} A_i^2}\sqrt{\sum_{i=1}^{n} B_i^2}},$$

Биредә **A** белән **B** – сүзләрне ачыклый торган векторлар, ә $\boldsymbol{A_i}$ белән $\boldsymbol{B_i}$ – әлеге векторларның компонентлары [Cosine similarity]. Мәсәлән, «*эт*» белән «*бүре*» сүзләре «*урындык*» белән «*сыер*» сүзләренә караганда бер-берсенә якынрак торалар: *0.543926 эт бүре 0.111563 урындык сыер.*

Ә «*тычкан*» сүзенең «*китап*», «*компьютер*» һәм «*күсе*» сүзләре белән мөнәсәбәтендә «*компьютер – тычкан*» пары «*китап – тычкан*» парына караганда якынрак, чөнки бу очракта «*тычкан*» сүзенең компьютер җиһазын белдерә торган мәгънәсе дә чагыла: *0.661968 күсе тычкан, 0.178382 компьютер тычкан, 0.079947 китап тычкан.*

**Нәтиҗә.** Word2vec моделе нигезендә әлеге эш кысаларында ясалган «Тезаурус» системасы, беренче чиратта, семантика һәм лексикография өлкәсендәге эзләнүләрдә файдалы булырга тиеш. Нейрон челтәрләр технологиясе кайбер очракларда шактый кечкенә күләмле корпус кысаларында да бай мәгълүмат бирә ала. Ләкин моның өчен күпсанлы көйләү параметрларын истә тотарга кирәк: тәрәзәнең киңлеге, итерацияләр саны, сүз векторларының зурлыгы h. б. Гомумән алганда исә, барлык сүзләргә карата да яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен, берничә миллиард сүзне үз эченә алган югары сыйфатлы корпусның булуы зарур.

## Әдәбият

Анализ тональности текста // Википедия. URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/Анализ_тональности_текста (дата обращения: 05.03.2019).

Дистрибутивная семантика // Википедия. URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/Дистрибутивная_семантика (дата обращения: 05.03.2019).

Татар матур әдәбияты корпусы. URL: http://litcorpus.antat.ru (дата обращения: 05.03.2019).

Татар теленең язма корпусы. URL: http://www.corpus.tatar/tt (дата обращения: 05.03.2019).

Cosine similarity // Wikipedia. URL: https://en.wikipedia.org/wiki/Cosine_similarity (дата обращения: 05.03.2019).

Natural language processing // Wikipedia. URL: https://en.wikipedia.org/wiki/Natural_language_processing (дата обращения: 05.03.2019).

*Tomas Mikolov, Kai Chen, Greg Corrado, and Jeffrey Dean.* Distributed Representations of Words and Phrases and their Compositionality. NIPS'13 Proceedings of the 26th International Conference on Neural Information Processing Systems. Volume 2. Pages 3111–3119. https://arxiv.org/abs/1301.3781

*Tomas Mikolov, Kai Chen, Greg Corrado, and Jeffrey Dean.* Efficient estimation of word representations in vector space. ICLR Workshop, 2013. https://arxiv.org/abs/1310.4546

Word2vec. Google Code. URL: https://code.google.com/archive/p/word2vec/ (дата обращения: 05.03.2019).

***Сәйхунов Мансур Рифкать улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Хөсәенова Альбина Марат кызы,***
*Иннополис университетының Машиналы өйрәнү һәм белем тасвирлау лабораториясе ассистенты*

***Хөсәенов Рөстәм Рафаэль улы,***
*GDC компаниясе инженеры*

УДК 821.512.145

*М.М. Хәбетдинова*

# Ф. БӘЙРӘМОВАНЫҢ «ҺИҖРӘТ» (2017) РОМАНЫНДА ТАТАР ЭМИГРАЦИЯСЕ ТЕМАСЫ

В статье систематизирована научная литература, посвященная проблеме татарской эмиграции. В ходе обзора произведений татарской литературы определены ключевые тенденции в разработке указанной темы. В работе выявлена специфика разработки темы эмиграции в романе Ф. Байрамовой «Һиҗрәт» («Исход») (2017). В статье обобщен материал по исторической основе произведения. В работе проанализированы ключевые сюжетные линии, система образов и композиция произведения Ф. Байрамовой, доказана многозначность понятия «Һиҗрәт» («Исход») в романе.

**Ключевые слова:** татарская литература, татарская эмиграция, Ф. Байрамова, роман «Һиҗрәт» («Исход»), сибирские татары.

The article systematizes the scientific literature devoted to the problem of Tatar emigration. The key trends in the development of this topic in the course of the Tatar literature works review are identified. In this paper we outlined the specificity of the exile theme development in the novel «The hijrat» («The exodus») (2017) by F. Bayramova. The article summarizes the material on the historical basis of the work. This paper analyzes the key story line, a system of images and the composition of the works by F. Bayramova, proves the ambiguity of the concept of «The hijrat» («The exodus») in the novel.

**Keywords**: Tatar literature, Tatar emigration, F. Bayramova, «The hijrat» («The exodus») novel, Siberian Tatars.

Татар совет әдәбиятында татар мөһаҗирлеге темасы популярлык казанмый. Әлеге темага милли әдәбиятыбызда М. Галәүнең «Болганчык еллар» (1931) һәм «Мөһаҗирләр» (1933) романнарында [Галәү] нигез салына [Safin, Khabutdinova, Khabutdinov]. М. Булгаковның «Зойкина квартира» (1925) һәм «Бег» (1926–1928)) әсәрләрендәгечә [Булгаков], татар әдибе эмиграция темасына фаҗига яссылыгында туктала, образларны психологик яктан бай итә. 1960 елларда татар язучылары әлеге темага янәдән әйләнеп кайта. «Качак» (1959) [Гыйләҗев, 1994, 1 т., б. 72–124], «Өч аршын җир» (1962) [Гыйләҗев, 1994, 1 т., б. 382–451], «Берәү» (1958–1965) [Гыйләҗев, 1994, 2 т., б. 5–154] повестьлары дөнья күргәннән соң, әдәби тәнкыйть А. Гыйләҗевны туган җирләрен ташлап, чит җиргә – СССР территориясендәге башка төбәкләргә мал артыннан куып күченеп киткән татар «качакларына» нахак сүз әйтүдә гаепли [Гыйләҗев, б. 314]. «Безнең өй өянкеләр астында иде...» (1964) новелласында [Юныс, б. 18–26] М. Юныс тумышы белән Самара губернасының Карамалы авылыннан булган татар карчыгының чит җиргә китеп гомер сөрергә мәҗбүр булуы, мөһаҗирлек фаҗигасенең сәбәпләре хакында уйлана: «Без дә

бит таралып беттек. Кайсыбыз кайда. Нигә туган җирдә генә яшәп булмый икән? Нинди көч гаиләләрне туздырып, туганнарны әллә кайларга таратып ташлый икән? Татар кешесе үз иркеннән китми бит туган җиреннән. Татарлар туган туфракларыннан бәхет эзләргә китәләр. Туган нигезендә бәхеткә ирешеп булмый микәнни? Кая киткән татар яши торган җирдәге бәхет? Кем куган аны? Нигә?» [Юныс, б. 26].

Татар әдәбиятында эмиграция темасы 1980–1990 елларда яңа күтәрелеш чоры кичерә. А. Гыйләҗев «Яра» повестенда (1981, 1984) [Гыйләҗев, 1991, б. 3–102], «Йәгез, бер дога!» (1991–1993) романында [Гыйләҗев, 1997] татар легионерлары мәсьәләсен күтәрә. Әйтергә кирәк, татар язучылары мөһаҗирләр язмышын эчке бер сызлану белән яктырталар (И. Юзеев [Юзеев, 372–413], З. Хәким [Хәким, 2007, б. 172–276], [Хәким, 2009], Т. Әйди [Айди, с. 5–16], В. Имамов [Имамов], С. Гафарова [Гафарова]). Әлеге теманы яктыртуга әдәбият белгечләре алына (Р. Мостафин [Мостафин, 1971], [Мостафин, 1974], Г. Гайнуллина [Гайнуллина, б. 231–239], М. Хәбетдинова [Хәбетдинова, б. 59–63], [Хабутдинова, с. 3], Л.Р. Фәизова [Faezova, Khabutdinova, Gaynyllina] һ. б.).

Татар-мөселман эмиграциясе темасы бүгенге көндә фәндә шактый тирән өйрәнелгән [Giljazov, 1996], [Giljazov, 1998], [Giljazov, 2000], [Гилязов, 1998], [Гилязов, 2005], Р.М. Адутов [Адутов], Гайнетдинов [Гайнетдинов], Л. Усманова [Usmanova] һ. б.

«Тимер пәрдә» алып ташланганнан соң, эмиграциядәге татарларның әдәби мирасы туган илгә кайтарыла башлый һәм әдипләр иҗатына игътибар бермә-бер көчәя (И. Мансуров [Мансуров], Х. Миңнегулов [Миңнегулов, 1994], [Чит илләрдә] һ. б.).

Татар әдәбиятында мөһаҗирлек темасын үстерүгә Ф. Бәйрәмова үзеннән зур өлеш кертә. «Һиҗрәт» дип исемләнгән тарихи романының (2017) исемендә үк төп тема чагылыш таба [Бәйрәмова, 2017]. Әсәр 1907 елда Госманлы империясенә (бүгенге көндә Төркия җиренә) күченеп киткән мөһаҗир себер татарлары язмышы хакында. И.Б. Кукулин карашынча, әлеге роман – «халыкны колонияләштерүгә бәйле фаҗигагә әрнү нәтиҗәсе» [Там, внутри…, с. 150]. Әдибәнең «Кырык сырт» романы да шул яссылыкта икәнен искәртик [Загидуллина, с. 32–34].

«Һиҗрәт» романының үзәгенә җәмәгать эшлеклесе, дин белгече Габдеррәшид Ибраһим (1857–1944) инициативасы белән себер татарларының Төркиягә күченеп китү вакыйгасы салына [Ибраһим]. Архив документларында 1907 елның ноябрь ахырларында Себердән чыгып киткән татар мөһаҗирләренең Төркиягә 1908 елның 1 гыйнварында гына килеп урнашуы турындагы мәгълүмат теркәлгән. Массакүләм матбугат чараларындагы хәбәрләргә караганда, бүгенге көндә Төркиядә чыгышлары белән Россиядән булган ун мең кеше яши. Алар Бөгередәлек, Әфәнде Күпере, Гексу, Искешәһәрдә тупланып гомер сөрә. Ике ел үтүгә татарлар Анатолиянең үзәгендә яңа оешкан, кеше саны азрак булган Рәшадия исемле авылга күчеп урнашалар.

Бу авыл солтан Мәхмүд V Рәшад (1908–1918) хөрмәтенә шулай атала. Төркия Республикасы оешканнан соң, бу исем беркадәр каршылыклы яңгырый. 1930 елларда авылны Бөгередәлек дип исемлиләр [Гаделшина].

Ф. Бәйрәмова үз әсәрләрендә һәрвакыт тарихи хәтерне тергезергә, татар тарихының тулы манзарасын күз алдыннан үткәрергә омтыла. «Һиҗрәт» романында язучы фәнни, тарихи материалны әдәби әйләнешкә кертү омтылышы ясый, әдәби хикәяләү белән авторның публицистик фикерләре үрелеп бара, шул рәвешле автор сурәтләнгән вакыйгаларга үз карашларын ачык белдерә. Ф. Бәйрәмова *кеше һәм тарих*, *халык һәм тарих* мәсьәләләрен әдәби материалга урнаштыруга ирешә.

Роман «Һиҗрәт кәрваны», «Һиҗрәт авылы», «Татарның мәңгелек һиҗрәте» дип исемләнгән өч кисәктән гыйбарәт. Әсәрдә бер-берсе белән тыгыз үрелгән сюжет сызыклары үзара керешә. Архив материалларын өйрәнү өчен, автор Себергә, Төркиягә, себер татарлары тупланып яшәгән авыл-шәһәрләргә күп тапкырлар юл тота.

Ф. Бәйрәмова Шиховлар нәселе тарихын бәян итә, өч буын себер мөселман зыялылары тормышын тасвирлый. Нәсел шәҗәрәсе Мөхәммәд пәйгамбәргә тоташкан Мөхәммәтҗан кавеме кайчандыр Бохарадан Себергә исламны тарату максаты белән күчеп утырган була. Әлеге әсәр дини лидерларның рухи шәҗәрәсе булган «алтын дәвамлылык» – силсилә үрнәге[1]. Аны без суфичылык әдәбиятында очратабыз. Археологик-этнографик эзләнүләрдәге фактларга караганда, бу нәсел XVI гасырда Себердә барлыкка килә. Шиховлар нәселенең зур бер өлеше совет властенең беренче унъеллыгында ук юк ителә, аерым бер өлеше XX йөз башында Төркиягә күчеп утыра, яңа оешкан җирлектә шәҗәрәнең бер язма нөсхәсе исән кала [Корусенко, с. 111–115]. Шул рәвешле, әсәрдәге сюжет нигезенә салынган вакыйгалар тарихи фактларга таянып барлыкка китерелгән. Ф. Бәйрәмова карашынча, «бохаралылар» гаҗәеп акыллы, күп илләр белән хезмәттәшлек итүче җитди сәүдәгәрләр була. Күчем хан чакырып китереп, Тара шәһәре тирәсенә күчеп утырган татарлар шушы катламга карый. Ф. Бәйрәмова тарихи чынбарлыкны әдәби күзлектән яңача һәм киңкырлы анализлый. Әдибә тарихи персонажларның, вакыйгаларның яшерен иҗтимагый һәм психологик нигезләрен ачып бирә.

Икенче сюжет сызыгы – мәгълүм дин һәм җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, публицист, сәяхәтче, тумышы белән Себердән булган Рәшид казый дип танылган Габдеррәшид Ибраһим (1857–1944) тормыш юлының әдәби укылышы. Бу өлештә Ф. Бәйрәмова *тарихта шәхеснең роле проблемасын* яктыртуга ирешә.

[1] Силсилә («буын», «рәт»). «Суфиларның мистик иснады, алдарак идарә иткән шәехләр шәҗәрәдә буыннарны тоташтырып торучы араны – «ахл-ас-силсилә» хасил итәләр. Алар тамырлары белән Мөхәммәд пәйгамбәргә тоташа торган шәҗәрәнең рухи дәвамчылары булып торалар» [Ислам, с. 208–209].

Романдагы вакыйгалар XX йөз башында Европаны, Госманлы империясен, Японияне таң калдырган тарихи катаклизмнар белән бәйле үстерелә. Ф. Бәйрәмова Рус дәүләтенең мөселманнарга карата колониаль сәясәтенә аерым игътибар бирә. Романда Идел буе, Себер, Кырым татарлары, нугайлар һ. б. хакында төгәл тарихи фактлар китерелә, Казан ханлыгы җимерелү, Ермакның Себерне алуы, рус булмаган халыкларны көчләп чукындыру кебек тарихи вакыйгаларга тәфсилле анализ ясала.

Автор позициясе вакыйгаларны сайлауда, характер һәм сюжет үстерелешендә, роман композициясендә, әсәр поэтикасында чагылыш таба. Романның исеме Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең Мәккә һәм Мәдинәгә күчеп утыру вакыйгасына бәйле. Ислам тарату, динне дәгъвәт итүдә бу вакыйга хәлиткеч роль уйный. «Ислам» энциклопедик сүзлегендә әл-һиҗрә – «күченеп китү, «эмиграция» [Ислам, б. 278] дип тәрҗемә кылына.

Себер татарларын туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр иткән сәбәп романда ачыктан-ачык әйтелә, ул – көчләп чукындыру куркынычы янау: «Халыкның ашыга-ашыга туган җирләрен ташлап китәргә җыенуының төп сәбәбе булып чукындыру куркынычы тора иде» [Бәйрәмова, б. 7], татарның милләт буларак юкка чыгуын алдан кисәтү: «алда безне милләт буларак бетү, юкка чыгу көтә» [Бәйрәмова, б. 13]. Чынбарлыкта, 1750 елларның урталарыннан патша хакимияте мөселманнарны көчләп чукындыру сәясәтеннән баш тарта. XIX йөзнең икенче яртысыннан Госманлы империясе сәясәтчеләре Россиядән күчеп килгән мөһаҗирләргә теләктәшлек, яклау күрсәтә, шул рәвешле алар үз җирлегендә мөселманнарның саны артуга ирешә. Мөһаҗирләр Балкандагы славян һәм Якын Көнчыгыштагы гарәп сепаратистларына каршылык күрсәтергә тиеш була. Рус администраторлары да, аеруча 1853–1856 елгы Кырым, 1865 елгы Кавказ сугышлары тәмамланганнан соң, мөселманнарның, бигрәк тә Кара диңгез бассейнына мөнәсәбәтле мөһаҗирләрнең күченеп китүләрен яклап чыга [Северный Кавказ..., с. 155–183].

Әдибә романда антитеза алымын яратып куллана. Романдагы *кеше һәм тарих, халык һәм тарих* проблемалары антитеза ярдәмендә тәкъдим ителә. Каршы кую персонажлар системасында (*калганнар – киткәннәр),* хронотопта (*Себер – госманлы иле (туган җир – чит җир))* чагылыш таба. Антитеза ярдәмендә әдәби образлар барлыкка китерелә, персонажларның эчке дөньясы ачыла.

Шиховлар нәселенең өлкән вәкиле Мөхәммәд – туган җирен өзелеп яратучы *ил карты* Себер татарларының борынгы бабаларыбыз яшәгән, Себер ханлыгы гөрләгән, ислам чәчәк аткан газиз җирдән күпләп күченеп китүләренә каршылык күрсәтеп карый. Романның башлам өлешендә бирелгән Рәшид казый белән бәхәс ислам динендәге һиҗрә хакында сөйләшүне хәтерләтә. Рәшид казый фикеренчә, иман хакына туган җирдән китү фарыз: «монда калып кяфер булганчы, ислам илендә фәкыйрь булуың мең артык!» [Бәйрәмова, б. 16].

«Без үз илебездә качак хәлендә, теләсә кайчан тотып, зинданга ябарга мөмкиннәр...», – дип ул XX йөз башында патша Россиясендәге татарларның хәленә бәя бирә. [Бәйрәмова, б. 28]. Мөхәммәд белән Рәшид казый арасындагы бәхәс соңрак көзгеле композициядә Г. Тукайның «Китмибез!» дип исемләнгән мәгълүм шигырендәге эпизодта яңгыратыла [Тукай, б. 186].

Романда һиҗрәт юл хронотобы белән янәшә бирелә. Бер яктан, юл – Себер татарларының Төркиягә юнәлүе. Ф. Бәйрәмова мөһаҗирләрнең маршруты белән тәфсилләп таныштыра: Омск – Курган – Чиләбе – Өфе – Рязань – Мәскәү – Одесса – Истанбул – Рәшадия (Бөгередәлек). Мөһаҗирләр юлның бер өлешен атта үтәләр, Омск каласында поездга күчеп утырып, Петропавловск (Кызылъяр), Курган, Чиләбе, Өфе аша Одессага җитәләр, юлның соңын Кара диңгез аша пароходта кичәләр. Романда юл газаплары – кардәшләрнең авырып китүе, җан әрнетеп, үлеп китүләре бик җентекле, тетрәндергеч итеп тасвир ителә.

Юлдагы төп вакыйгалар – Мәрфуга карчыкның һәм Абдулланың үлеме. *Шәһит булу* – иман өчен баш салу концепциясе романда әнә шулай чагылыш таба. Шул рәвешле, һиҗрәт Аллаһка якынаю мәгънәсен ала. Бөгередәлек авылында бүген дә Истанбулга юл тоткан күп балалы аналарның Кара диңгез кичүен үткән вакыттагы күз яшьләрен хәтерлиләр. Пароходка ияреп йөзгән Абдулла мәете төргәге иман хакына корбан китерү сызыгында кульминацион эпизод: «кара дәрья илсез-җирсез бер татар баласын үз кочагына алды...» [Бәйрәмова, б. 108]. Балаларның газапка дучар ителүе – дөньяның дөрес кануннарга корылмаганлыгын белдерүче төп күрсәткеч, дип белдерә Ф. Бәйрәмова. Татар язучысы, Абдулланың үлеме сурәте аша, дәүләтчелекне югалтканнан соң, иманнарын саклап калу хакына, чит җирләргә китәргә мәҗбүр ителгән мөһаҗирләр мәсьәләсен гәүдәләндерүгә ирешә. Дәрдемәнднең «Кораб» шигыре ярдәмендә автор проблеманы көчәйтеп куя.

Китапның икенче кисәгендә Төркиядәге вакыйгалар бәян ителә. Романда Төркия мөселманнарны яклаучы, саклаучы ил буларак данлана. Себер татарлары кайчандыр бирегә килеп урнашып, икенче ватаннарын тапкан нугайлар, кырым татарлары белән аралаша. Госманлы империясе хакимияте белән арадашчы ролен Рәшид казый үти. Аның карашларын белдерү аша мөһаҗирлек Якын Көнчыгышта рус-төрек каршылыгының бер ягы дип тамгалана. Мөселманнарның Госманлы империясенә күченеп китүен Ф. Бәйрәмова Россиянең мөселман халыкларына карата сәясәте нәтиҗәсе дип бәяли. Себер татарларының төрекләр һәм башка милләт мөһаҗирләре белән очрашу эпизодларында төркиләрнең кардәшлеге турындагы фикер алга чыгарыла: «Борынгы бабаларыбыз дус булса, уртак дошманга каршы бергәләп сугышкан булсалар, Алтын Урда да таралмас иде, Казан, Себер, Әстерхан ханлыклары, Нугай Урдасы да урыска калмас иде. Без дә монда илдән качкан мөһаҗир булып кеше кулына карап яшәмәс

идек» [Бәйрәмова, б. 150]. Әгәр себер мөһаҗирләре башлыгына, күченеп китәр алдыннан, җирле байлар, сәүдәгәрләр ярдәм кулы сузса, Төркиядә исә төрекләр һәм башка милләт мөһаҗирләре булыша. Шул рәвешле, мөселман дине төрле халыкларны берләштергән, укмаштырган көч буларак бәяләнә.

Ф. Бәйрәмова Төркияне идеаллаштырмый, халыкның яшәеш тәртибен тәфсилләп тасвирлаганда, аның кайтыш якларын да читләтеп үтми. Язучы күченеп китүчеләр тормышына бәйле берничә фактка игътибар итә. Алардан күренгәнчә, Госманлы империясе, нинди генә икътисади кыенлыклар кичерсә дә, мөһаҗирләр алдында үз бурычларын үти: аларны солтан үзе яклый, яшәр өчен җир бүлеп бирә, хәрби хезмәттән азат итә.

«Һиҗрәт» романының өченче кисәгендә һиҗрәт сүзенә өченче төрле – ислам сугышчысының хәрби хәрәкәтләр урынына күченүе мәгънәсе салына. Бөгередәлекнең хәрби хезмәттән азат ителгән егерме мөһаҗире 1912–1913 елгы I һәм II Балкан сугышларында төрекләр ягында катнашырга теләк белдерә. Ф. Бәйрәмова Себер татарларының батырлыгын ассызыклап сурәтли. Әнвәр паша сугыш кырында арысландай көрәшкән татар мөһаҗирләренә сокланып туя алмый [Бәйрәмова, б. 245]. Татарлар 1914–1915 елгы Сарыкамыш һөҗүмнәрендә катнаша, анда төрекләр җиңелә. Ф. Бәйрәмова Беренче бөтендөнья сугышындагы иң хәлиткеч көрәшләрнең берсе – Чанаккаладагы сугышта татарларның батырларча көрәшен тасвирлый: «Татар мөһаҗирләре дә бу көрәшнең иң алгы сафларында булалар, бу илнең исән-сау калуы өчен каннарын түгәләр, гомерләрен бирәләр...» [Бәйрәмова, б. 270]. Төрекләрнең бу бәрелештә өстен чыгуы Истанбулны яулап алырга теләгән Британия империясе һәм аның доминионнары гаскәрләренең җиңелүенә китерә һәм 1918 елның ноябренә кадәр сугышны дәвам иттерергә мөмкинлек бирә. Вакытны оту Анатолиядә каршылык күрсәтүче база оештыру һәм Төркия республикасының бәйсезлеге өчен көрәш башлауга файдалы була. Төрек хакимияте татарларның сугышларда күрсәткән батырлыкларын югары бәяли, акчалата бүләк бирә. Татарлар бүләктән баш тарталар: «Без шәһитләребез каны өчен акча алмыйбыз, алар Аллаһ ризалыгы өчен, Ватан хакына башларын салдылар. Ватан сау булсын! – ди татар мөһаҗирләре. Һәм балаларына, нәселләренә дә шушы изге әманәтне васыять итеп әйтеп калдыралар» [Бәйрәмова, б. 270].

Ф. Бәйрәмова үзенең романына Рәшид казый катнашында немец дипломаты Оппенгейм белән Госманлы империясенең хәрби министры, Генч (яшь) төрекләр триумвираты лидеры Әнвәр пашаның сөйләшүен кертә. Макс фон Оппенгейм (Оппенхайм) – барон, немец дипломаты, шәрыкшенас галим, Беренче бөтендөнья сугышы вакытында җиһад дип Һиндстан һәм Мисырдагы көнчыгыш мөселманнарын Британия хакимиятенә каршы көрәшкә өндәү идеясе белән яна. Ул Берлинда тышкы эшләр министрлыгында хезмәт куя. Ул Көнчыгыш яңалыклар агентлыгына (Nachrichtenstelle fur den Orient) нигез

сала, һәм гарәп илләрендә тарату өчен, «Җиһад» дип исемләнгән журнал нәшер итә [Северный Кавказ..., с. 155–184; Роган, с. 80].

Романда Рәшид казыйның мөһаҗирләр өчен казакъ, татар, гарәп телләрендә мәгълүмат чаралары булдыруга бәйле эшчәнлеге, Алманиядә хәрби әсирләр өчен мәчет төзетү буенча йөрүе, Австрия-Венгрия һәм Алмания төзегән төрмәләрдә әсирләр белән аралашуы җентекле тасвирлана. Шул рәвешле, Рәшид казыйның Беренче бөтендөнья сугышы вакытында татар хәрби әсирләре арасында пропаганда эше алып баруы турындагы эпизодлар аша ике сюжет сызыгы – татар мөһаҗирләре һәм татар хәрби әсирләре сызыгы үзара тоташа.

Өченче кисәктә колонияләр темасы Оренбург татары Рәхмәтуллага әнисе язган хат аша үстерелә. Ана улына әсирлектән инкыйлаблар чолгап алган туган иленә кайтмавын сорап ялына. Рәшид казый һәм Мөхәммәтҗан карт сюжет сызыклары биредә янәдән үрелә. Алар төрмәдә очраша. Шул рәвешле, автор укучыны янәдән мөһаҗирләрнең ватанына – гражданнар сугышы утында, ак һәм кызыл террор кулында, ачлык-ялангачлык көненә калган Себер җиренә кайтара.

Төркиягә күченеп киткән мөһаҗирләрнең язмышын тасвирлау барышында Ф. Бәйрәмова Мөхәммәтҗан карт кызы Хөснибикәнең һәм Зөлбануның гаилә тарихын җентекләп сурәтләп бирә. Иҗтимагыйтарихи вакыйгалар белән шәхси сызыкны янәшә үреп бару исәбенә әдибә татар милли характеры турында фикер үткәрүгә ирешә. Әдибә татар хатын-кызларындагы сабырлык, тугрылык, пөхтәлек, ачыклык, хуҗалыкчыл булу сыйфатларын аерып куя, Зөлбану тарихы аша гаиләдәге хәл-әхвәлләрне эчтән кичерә белү сыйфатына басым ясый. Хөснибикә һәм Зөлбану тол калгач, тормыш авырлыгын Аллаһка таянып һәм үз көчләренә ышанып күтәрәләр. Аларга ярдәмгә туганнары, кардәш тиешле татарлар килә. Шул рәвешле, әдибә татар мөһаҗирләренең чит җирдә дә милли яшәеш нигезләрен саклап кала алуларын бәян итә.

Төркиядә үзләре оештырган татар авылы урамнарын мөһаҗирләр туган авылдагыча исемлиләр, милли йола-гадәтләрне күз карасыдай саклыйлар, татар ризыклары пешерәләр.

Ф. Бәйрәмова – психологизм остасы. Геройларның тышкы рәвешләрен тасвирлаган вакытта милли сызыкларга аерып туктала. Себер татарларының портретларын биргәндә, идеаллаштыруга омтылыш та үзен сиздерә (мисалга, Мөхәммәтҗан, Хөснебикә портретлары). Портретлар автордан түгел, башка геройлар күзлегеннән тәкъдим ителә. Еш кына портрет бирелешендә мифопоэтик традициягә мөрәҗәгать итү дә күзәтелә. Әйтик, Рәшид казый Хозыр-Ильяс портретына якын китерелгән. Шәхси портретлар белән янәшә аерым халыкларның – татар, нугай, төрекләрнең милли портретлары да бирелә. Автор, геройларның кичерешләрен тирәнрәк ачу максатында, эчке монолог алымына, халык җырларына, бәетләргә мөрәҗәгать итә.

Мөһаҗир образларын тулырак ачу өчен, төш образы да кулланыла. Төшләргә кереп йөдәткән туган ил, җир хезмәте мөһаҗирләрнең

әрнү-сызлануларын тирәнрәк тоярга мөмкилек бирә: «Алар төшләрендә Себернең ап-ак карларын, шул карларда уелып калган җәнлек эзләрен, артларыннан томырылып чабып килгән тугры атларын, авыл өстеннән туп-туры күтәрелгән морҗа төтеннәрен, шул төтен белән бергә бар дөньяга таралган ризык исләрен, себеркеле мунча парларын, боз каплаган күлләрне, ак сакаллы картларын күрделәр...» [Бәйрәмова, б. 106]. Мөхәммәтҗан карт сызлануы хәсрәт сызыгын тагын да тирәнәйтә: «ничек инде ирекле баштан шушы җәннәттәй җирләрне ташлап китәргә мөмкин?!» [Бәйрәмова, б. 18]

Телсез-чукрак Хөснебикә төшләре язмышны юрау эчтәлегенә ия: Ырыслы күленә аккошлар түгел, билгесез-ят акчарлаклар кайткан икән, шуларның берсе күл өстенә төшеп, бала мәетенә әверелгән икән» [Бәйрәмова, б. 106].

Романда аккош образы – себер татарларында тотем кош мифопоэтик традицияләрдә ачыла. Себер татарларында аккошка ату тыела. Аккош – туган илнең идиллик табигате сурәте, мәхәббәт һәм тугрылык символы. Аккошны үтерү вакыйгасы Шиховлар нәселенә төшкән каргышны искәртә. Аккош образын мифопоэтик традицияләргә тугры калып сурәтләү себер татарларына караган кисәктә генә түгел, романның төрекләргә кагылышлы бүлекләрендә дә чагылыш таба. Өченче кисәктә аккош образы Киек каз юлы турындагы мифка тоташа, куылганнарның җаннары, мөһаҗирләрнең туган җирләргә кайтуын искәртә. Автор моны махсус рәвештә прозага мөрәҗәгать итеп ассызыклый. Үләр алдыннан алар телендә бер сүз: «Кайда минем өем... Кайда... минем... илем...». Романда бу сүзләр рефрен хасил итә [Бәйрәмова, б. 243]. «Окоп көе» («Көзге ачы җилләрдә») җыры чит җирләргә китәргә мәҗбүр ителгән татарларның гимны булып яңгырый. Галимнәр бу җырның туу датасына бәйле төрле караштa тора. А. Ключарев фикеренчә, бу җыр 1904–1905 елларда – Рус-япон сугышы вакытында туа, М. Мозаффаров, Ю. Виноградов, А. Абдуллин, Җ. Фәйзи карашынча, 1914–1918 елларда Берече бөтендөнья сугышы барганда языла. Шул рәвешле, әлеге җыр әсәрнең пафосын булдыруда гына түгел, хронотопта да катнаша.

Мөһаҗирләр язган бәетләр – иман, ирек хакына туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр ителгәннәрнең эчке сызлануы, гомерлек хәсрәте чагылышы, автор карашы белдерелеше дә. Себер татарларында киң таралган бәетләр, дастаннар ватанны идеаллаштырып сурәтләүдә әһәмиятле роль уйный. Сәяхәтчеләр юлда Күчем хан турындагы дастанны тыңлый. Рус һәм совет чыганакларыннан аермалы буларак, Ф. Бәйрәмованың Күчем ханы явыз да, мәкерле дә, канечкеч тә түгел, Зәйнәб абыстай көйләгән бәет һәм дастандагыча, ул – акыллы идарәче. Бу – әсәрнең хронотобын киңәйтү чарасы.

Себер татарлары өчен Күчем хан – төньякта Обь ярларыннан алып көнбатышта Уралгача, көнчыгышта Бараба чүленәчә җәелгән күпсанлы, төрле халкы булган мәгърур ханлык оештырган бөек зат. Ул – ирек сөюче гадел идарәче, ханлыкта ислам динен таратуга

үзеннән зур өлеш кертә. Халык хәтеренә ханның туган җир хакына көрәшүе, фаҗигале төстә һәлак булуы сеңеп кала. Себер ханлыгы яулап алыну татарның милли фаҗигасе дип кабул ителә.

Зөлбану башкарган «Сак-Сок» бәете укучы хәтерендә татарның борынгы тарихын тергезә. Татар галимнәре карашынча, әсәрнең нигезенә салынган легенда болгар нигезле (А.Х. Халиков). Легенданың нигезенә салынган миф тагын да иртәрәк барлыкка килгән (Г.М. Дәүләтшин). Бәеттә төрки генеологиянең тармаклары таркалу мотивы гәүдәләнеш таба. «Сак-Сок» бәете, бер яктан, милли һәм дини кыйммәтләрне саклап калу хакына ватанын ташлап киткәннәрнең хәсрәтен чагылдырса, икенче яктан, фаҗиганең тирәнлеген ассызыкларга ярдәм итә [Сагитова, Хабутдинова].

Роман структурасында бәетләр бик күп. Мөһаҗирләрнең туганнары әйтүләренә караганда, аларның бабалары бәет жанрын аеруча яратып куллана, XX йөз башында язылган бәетләр халык хәтерендә бүгенгәчә саклана.

Романда дини дискурс исемгә үк чыгарыла, Коръән сүрәләре, хәдисләр, гарәп телендәге дога текстларыннан оеша. Корбан бәйрәме, бала туу, исем кушу, мәет күмү һ. б. йолалар да дини дискурсны хасил итә. Дөньяга карашлары буенча мөселман булган геройлар теле белән дәгъвәт кылына, үгет-нәсыйхәт җиткерелә. Дин эшлеклеләре, мөдәррис образларының күп булуы, дин турындагы сөйләшүләр, бәхәсләр дә дини дискурсны баета төшә. Мөхәммәд картның русларны яклап чыгу вакыйгасы татар кешесенең киң күңелле булуы, башка диндәгеләрне ихтирам итүе хакында бәян итә. Шул рәвешле, һиҗрәтнең дүртенче мәгънәсе – дин тоту аша Аллаһка, пәйгамбәргә якынаю омтылышы.

Себер татарлары мөһаҗирләре язмышы буыннар өчен үгет-нәсыйхәт булып тора. Исламга тугры диниятле кеше өчен әлеге тарихи вакыйга гыйбрәт ролен үти. Күчеп китү – һиҗрәтнең матди ягы ул, рухи ягы – имансызлыкны, гөнаһны артта калдыру, Аллаһка һәм аның пәйгамбәренә якынаю. Һиҗрәтнең максаты – исламны тарату. Һиҗрәтнең рухи ягы, автор карашынча, иманлы кешедә булырга, аны камилеккә өндәп, рухи үсешкә омтылдырып торырга тиеш, чөнки хакыйкать җиңәргә тиеш.

Ф. Бәйрәмованың яңа романында дини һәм публицистик дискурс әдәби катламнан киңәебрәк киткән урыннар да бар. Сюжет сызыклары ачык бирелмәгән урыннар да юк түгел. Хронотопны, эчке бәйләнешләрне тотып алу кыенлык тудырган очраклар да күзәтелә. Себер татарларының җырларын биргән өлешләр дә әдәби яктан эшләнеп бетмәгән, дигән тәэсир кала.

Ф. Бәйрәмованың «Һиҗрәт» тарихи романы милләт тарихындагы ак тапларны киметә. Китапның композициясе авторның тарихи барышны күзаллавы, аңлавы белән бәйле. Ф. Бәйрәмова дөньякүләм әһәмияткә ия вакыйгаларны, сугышларны, инкыйлабларны кеше яшәешенең мәгънәсе, милли идея яссылыгында гаҗәеп төгәл

һәм ачык тасвирлауга ирешә. Романда үзәк урынны геройларның язмышларын тарихи вакыйгаларга бәйләп тасвирлау алып тора. Әдәби уйдырма документаль, тарихи нигезгә утыртыла. Романдагы персонажлар чор сурәтен тудыруда катнашалар.

**Әдәбият**

*Faezova L.R., Khabutdinova M. M., Gaynyllina G.R.* The Emigration Theme In Tatar Literature // MODERN JOURNAL OF LANGUAGE TEACHING METHODS. 2018. Vol. 8, Is. 9. P. 66–71.

*Giljazov I. A.* Die Islampolitik von Staat und Kirche im Wolga-Ural-Gebiet und der Batirsah-Aufstand von 1775, in: Muslim Culture in Russia and Central Asia from the 18th to the 20th Century / Hrsg. Michael Kemper, Anke von Kügelgen, Dmitry Yermakov (=Islamkundliche Untersuchungen, Bd. 200). Berlin: Schwarz Verlag 1996, S. 69–89.

*Giljazov I. A.* Die Muslime Ruslands in Deutschland wahrend der Weltkriege als Subjekte und Objekte der Grosmachtpolitik // Fremdeinsätze: Afrikaner und Asiaten in euroaischen Kriegen; 1914–1945 / Zentrum Moderner Orient, Geistwissenschaftliche Zentren Berlin e. V. Hrsg. Gerhard Hupp und Brigitte Reinwald. Berlin: Das Arabische Buch, 2000. S. 143–148.

*Giljazov I.A.* Die Wolga-Tataren und Deutschland im ersten Drittel des 20. Jahrhunderts // Muslim Culture in Russia and Central Asia from the 18th to the Early 20th Centuries, vol. 2: Inter-Regional and Inter-Ethnic Relations / Hrsg. Anke von Kugelgen, Michael Kemper, Allen J. Frank (=Islamkundliche Untersuchungen, Bd. 216). Berlin: Schwarz Verlag, 1998. S. 335–353.

*Safin M.F, Khabutdinova M.M, Khabutdinov A.J.* The theme of muhajirlik in tatar prose [El tema del muhajirlik en la prosa tartara] // Opcion. 2018. Vol. 34, Is. 86. P. 119–126.

Usmanova L. The Turk-Tatar Diaspora in Northeast Asia : Transformation of Consciosness; A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950s. Tokyo: Rakudasha, 2007. 367 p.

Адутов Р.М. Татарская и башкирская эмиграция в Японии. Япониядәге кардәшләребез. Наб. Челны: НГПИ, 2008. 196 с.

*Айди Т.* Без родины // Современная татарская проза. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. С. 5–16.

*Бәйрәмова Ф.* Һиҗрәт. Казан: «Аяз» нәшр., 2017. 480 б.

*Булгаков М.* Пьесы 1920-х гг. Л.: Искусство, 1989. 591 с.

*Гаделшина Г.* Бөгередәлекнең төрек маршы // Ватаным Татарстан. 2007. № 168–169 (26024). 23 август.

Гайнетдинов Р.Б. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начала XX века – 30-е годы: исторический очерк (1997). Камский изд. дом, 1997. 159 с.

*Гайнуллина Г.Р.* З.Хәкимнең «Легионер» «романында коллаборационизм темасы // Материалы Международной научной конференции «Джалиловские чтения»: Казань: Фолиант, 2017. Б. 231–239.

*Галяу М.* Муть. Мухаджиры. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 460 с.

*Гафарова С.* Килмешәк / Рк. Зәйдулла тәрҗ. // М.М. Хабутдинова архивы: кульязма. 2017. 40 б.

*Гилязов И.А.* Легион «Идель-Урал». Представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами «третьего рейха». Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 383 с.

*Гилязов И.А.* На другой стороне. Коллаборационисты из поволжско-приуральских татар в годы Второй мировой войны. Казань: Мастер-Лайн, 1998. 252 с.

*Гыйләҗев А.М.* Әсәрләр: 4 т. т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 334 б.

*Гыйләҗев А.М.* Әсәрләр: 4 т. т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 574 б.

*Гыйләҗев А.М.* Йәгез, бер дога! Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 448 б.

*Гыйләҗев А.М.* Татарстан могҗизасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 504 б.

*Гыйләҗев А.М.* Яра. Казан: Татар. кит.нәшр., 1991. 415 б.

*Загидуллина Д.Ф.* Постколониальные мотивы в татарской прозе XXI веке (на материале романа Ф. Байрамовой «Сорок вершин» // Тамбов: Грамота, 2017. № 4(70): в 2-х ч. Ч. 1. С. 32-34

*Ибраһим Г.* Бөгрәдәлек көндәлеге. Казан, РИУ нәшр, 2013. 194 б.

*Имамов В.* Япун татары: роман. Чаллы: Газета-китап нәшр., 2004. 152 б.

Ислам. Энциклопедический словарь. М.: Наука, Гл. ред. вост. лит-ры, 1991. 315 с.

*Корусенко С.Н.* Из истории рода Шиховых: генеалогический метод в этноисторических исследованиях // Интеграция археологических и этнографических исследований: сб. науч. Тр.: в 2 т. Иркутск: Изд-во ИрГТУ, 2013. Т. 1. С. 111–115.

*Мансуров И.С.* Милли юлда: Мөһаҗирлектә татар әдәби хәрәкәте 1917–1954 еллар. Стәрлетамак: БДУның Стәрлетамак фил., 2013. 221 с

*Миннегулов Х.Ю.* Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 384 с.

*Мустафин Р. А.* По следам поэта-героя М.: Дет. лит., 1971. 271 с.

*Мустафин Р.А.* По следам оборванной песни. М.: Известия, 1974. 510 с.

*Роган Ю.* Падение Османской империи. М.: Альпина Нон-фикшн, 2017. 560 с.

*Сагитова Г.Р., Хабутдинова М.М.* Татарский баит «Сак-Сок» сквозь призму искусства XXI века // Tatarica. 2016. № 2. С. 177–201.

Северный Кавказ в Российской империи. М.: НЛО, 2007. 460 с.

Там, внутри: практики внутренней колонизации в культурной истории России: сб. статей / под ред. А. Эткинда, Д. Уффельманна, И. Кукулина. М.: Новое литературное обозрение, 2012. 960 с.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 5 т. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 406 с.

*Хабутдинова М.М* В поисках ак калфак... // Звезда Поволжья. 2017. № 14 (837). 13–19 апреля. С. 3.

*Хәбетдинова М.М.* Пародиядән татар милли трагедиясен аңлауга... // Идел. 2017. № 11. Б. 59–63.

*Хәким З.* Легионер // Казан утлары. 2009. № 9. Б. 5–50; № 10. Б. 60–88; № 11. Б. 43–78.

*Хәким З.* Легионер // Яңа татар пьесасы. Альманах. Бишенче кисәк. Казан: Идел-пресс, 2007. Б. 175–276.

Чит илләрдә татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2007. 399 б.

*Юзеев И.* Сайланма әсәрләр: 5 т. Т. 5. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 414 с.

*Юныс М.* Безнең өй өянкеләр астында иде... // Юныс М. Әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2005. Б. 18–26.

***Хәбетдинова Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 821.512.145

***Ф.Х. Миңнуллина***

# М. ГЫЙЛӘҖЕВ ИҖАТЫНДА ГОМУМКЕШЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

В статье исследуются пьесы М. Гилязова, в которых отражается проблема духовных ценностей в современном обществе. Акценты делаются на тенденциях ценностных трансформаций в характере героев. Современный социально-политический контекст проблемы рассматривается сквозь призму общечеловеческих ценностей. На основе анализа раскрываются характерные черты героев современной татарской драматургии.

**Ключевые слова:** драма, герой, пьеса, конфликт, жанр.

The article explores M. Gilyazov's plays, which reflect the problem of moral values in modern society. Accents are made on the trends of value transformations in the character of the heroes. The contemporary socio-political context of the problem is viewed through the lens of universal human values. Based on the analysis, the characteristic features of the heroes of modern Tatar dramaturgy are revealed.

**Keywords:** drama, hero, play, conflict, genre.

Хәзерге татар әдәбиятында идея-эстетик кыйммәте, замандашлары дөньясына ясаган йогынтысы, чорның дөньяви-иҗтимагый, рухи-әхлакый әһәмиятле мәсьәләләрен укучы игътибарына җиткерүдә М. Гыйләҗев иҗаты аеруча игътибарга лаек. Ул язган пьесалар буенча Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Бичура», «Казан егетләре», «Баскетболист», «Яра», К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә «Баланың баласы балдан татлы» һ. б. спектакльләр куелды. «Күктау» фильмының сценарий авторы да – М. Гыйләҗев. Әдипнең әлеге иҗат җимешләре рәтенә «Бөркетләр», «Бибинур» фильмнары һәм «Курчак туе», «Исәнмесез» спектакльләре өстәлде. XX йөз ахырында башланып киткән иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр әдәбиятка яңадан-яңа тема һәм проблемалар алып килде, милләт буларак сакланып калу турында уйланырга мөмкинлек тудырды [Миңнуллина, 2016, б. 131]. Драматургның пьесаларына хас төп үзенчәлекләренең берсе – аларның фәлсәфилеккә нигезләнүендә. М. Гыйләҗев драмаларында фикер кискенлеге, татар гадәтләренең, милли йолаларының бозылуы, татар гаиләсендә мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгы, яшьләр арасында азгынлык күренешләренең артуы мөһим урын алып тора. Катлаулы чынбарлыкта әхлакый кыйммәтләр, кеше язмышы өчен борчылу язучы иҗатының рухи-әхлакый доминантасы булып тора. М. Гыйләҗев драматургиясе новаторлык элементларын куллануы белән татар драматургиясе үсешенә зур өлеш кертте. Пьесаларында сурәтләнгән чынбарлыкның реаль картиналары һәм актуаль темаларның, мәсьәләләрнең

яктыртылышы белән автор шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрендә драматургиядә моңа кадәр кагылмаган якларга игътибарын юнәлтте. Драматург иҗатында милләт язмышы, татар халкының милләт буларак сакланып калуы темасы даими рәвештә яктыртылып килә. Бу уңайдан авторның «Бичура», «Баскетболист», «Төзүче, тимерче һәм бакчачы», «Бушап калган өйнең төшләре», «Мәхәббәт сүзлеге», «Курчак туе», «Исәнмесез?!» пьесалары игътибарга лаек.

Соңгы елларда иҗат ителгән драма әсәрләре образлар системасы, идея-эстетик үзенчәлекләре ягыннан берникадәр үзгәреш кичерә. Мәсәлән, татар әдәбиятында бичуралар, албастылар, шайтаннар кебек мифологик затларга мөрәҗәгать итү активлаша. Бичура образы – шуларның берсе. Татар ышануларында бичура һәм өй иясе ике рух дип карала. «Өй иясе – татар мифологиясенең нигезен тәшкил иткән ияләр дөньясында үзәк урын тотучы рух. Чөнки ул башка ияләргә караганда кешеләргә якынрак тора… Кешеләргә күп файда китерә. Иң мөһиме, ул өйне саклый. Аны куркытырга, куарга тырышмагыз, ахыры начар бетәчәк... Йорт иясе йортны явыз рухлардан, хәтәр авырулардан саклый...» [Татар мифлары, 1996, б. 203]. Өй ияләре арасында усаллары, шат күңеллеләре, холыксызлары, тынгысызлары булу хакында да ышанулар яши. «М. Гыйләҗевның «Бичура» (1989) драмасында Бичура – йорт хуҗасы, кешеләргә файда китерүче буларак сурәтләнә. Әлеге образга бәйле рәвештә, автор милләт язмышы мәсьәләсен күтәрә. Драмада ике катлам – чынбарлык һәм шартлы-мифологик дөнья янәшә куела. Шартлы-метафорик эчтәлек Бичура һәм Кара җаннар образларына бәйле рәвештә ачыла [XX гасыр татар әдәбияты тарихы, 2011, б. 32]. Әсәрдә Аксак белән Хатынның ике генә гаилә калган авылда яшәүләре, Аксакның Кара җаннар, Бичура белән очрашуы, киленнәрнең авылга кайтып төшүе кебек вакыйгалар тасвирлана. Вакыйгалар үстерелешендә Кара җаннар – кешенең караңгы башлангычы, ә Бичураның кешедә якты як булып торуы ачыклана. Ә. Закирҗанов язганча: «Кеше күңеленең ике ягын – өмет һәм өметсезлек, яктылык һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык, тугрылык һәм мәкер чагылышын тикшерү максат итеп куела. Кеше күңелендә мәңгелек көрәш бара. Үзара каршылыкта булган көчләрнең Якты ягы (Яхшылык) өстенлек алса, кешедә киләчәккә ышану, бәхеткә омтылыш баш калкыта, Караңгы ягы (Явызлык) җиңүе исә өметсезлек, ялгызлык, яшәешнең мәгънәсезлеге булып чагыла» [Закирҗанов, 2005, б.]. Шартлы-метафорик эчтәлек тә шул образларга бәйле рәвештә ачыла. Драманың сюжеты иҗтимагый проблемалар – шәхес фаҗигасе алга куелу белән үзенчәлекле. «Бичура»да система корбаннары, сәясәт һәм гаилә каршылыгы, сәяси вакыйгаларның кеше язмышын җимерүе кебек мәсьәләләр күтәрелә. Аксак сүзләрендә, мәсәлән, совет системасына карата булган тәнкыйди фикер чагылыш таба: *«Аксак. ... Юкка яшәгәнбез, күрше, гомерне бушка сарыф иткәнбез. Кеше күңелләрендә калырлык изгелек кылмадык, тормышны чәнти бармак кадәр дә алга җибәрмәдек. Киресенчә, ул*

*гел артка тәгәрәде, аска, адәм башы чыгалмаслык упкынга, өметсезлеккә…»* [Гыйләҗев, 2004, б. 61]. Бичура белән күптәннән таныш булган Хатын образы аша да җәмгыятькә бәя бирелә. «*Иске тормышны җимердек. Яңасына юл таба алмадык, җимерекләр арасында гомер үтте. Бичураның китәсен белеп, сизеп яшәдем. Хәрабәләр, җимерекләр арасында ни мәгънә табып калсын ул?*» [Гыйләҗев, 2004, б. 88]. Әлеге сүзләрдә аерым бер кеше фаҗигасе генә түгел, ә ил, халык фаҗигасе ачыла. Утыз ел буена югалган бәбкәләрен эзләп йөрүче Күрше образында да сугыш алып килгән фаҗига, авылның хәерчелеккә төшүе, кешеләрнең саташу халәтендә гомер итүләре билгеләнә. Геройларының психологик халәтләре ярдәмендә драматург җәмгыятьтә хөкем сөргән әхлаксызлык, битарафлык кебек мәсьәләләргә тукталa. Мәсәлән, Бичураның мосафир кыяфәтендә килеп, картның киленнәре белән ата-бабадан калган нигез хакында сүз алып баруы, Руфия белән Гөлнараның сәер кунакны аңларга теләмәүләре, Гөлнараның «картларны» җүләрләр йортына илтергә кирәк дигән фикергә килүе – шуның ачык мисалы. Кимсетелгән Бичура шушы вакыйгадан соң бик озак вакытка югалып тора. Кара шәүләләрнең киленнәр юган керләрне пычратып китүләре – бүгенге кешеләрнең миһербансызлыкларына, җан пычраклыгына ишарә итә. Әсәрдә Бичура урынына чормага менеп утырган Аксакның җимерелеп төшүе, түбәсез калган йорт шулай ук игътибарга лаек. А. Батталова язганча, М. Гыйләҗевнең «Бичура»сында ак һәм кара башлангыч көрәше йорт образына нисбәтле ачык күренә [Батталова, 2009, б. 81].

Әсәрдә туган йорт – нәсел – ил чылбыры үзәктә тора. Өлкән буынның яшьләргә тапшырыр васыяте – шуларны саклау хакында. М. Гыйләҗевтагы җимерек өй дөньяның җимерелүен, милләтнең юкка чыга баруын символлаштыра. Ул бушлык, ялгызлык, җимерелгән хыяллар билгесе генә түгел, ә йорт-нигез яссылыгында бүгенге яшәешкә, җәмгыятькә, совет идеологиясенә тәнкыйди караш та. Шулай итеп: «Бичура шартлы-символик образы укучы алдына матурлыкка омтылыш, җан сакчысы, рухи яшәеш, иман билгесе, авырлыкны җиңәргә ярдәм итүче кебек архетипик сыйфатларга ия булып гәүдәләнә. Кара җаннар исә, аерым кеше тормышыннан башлап, милләт яшәешендәге ямьсезлек булып күзаллана [XX гасыр татар әдәбияты тарихы, 2011, б. 32]. Бичура образы рухи яшәеш билгесе, авырлыкларны җиңәргә ярдәм итүче архетип буларак күзаллана. Драматург татар авылларының бетүе, юкка чыга баруына борчыла. Аларны милләтнең җан сакчысы, яшәеш чыганагы дәрәҗәсенә күтәреп, татарның киләчәге нинди булыр дип чаң суга [XX гасыр татар әдәбияты тарихы, 2011, б. 32].

Драма, нигездә, психологик характердагы конфликтка корылган, персонажларның күңел дөньясы ачыла барган саен, ул конфликтның система тарафыннан рәхимсез имгәтелгән шәхесләр фаҗигасе нәтиҗәсе икәнлеге күренә. Драматик конфликт милли һәм әхлакый кыйммәтләр белән тыгыз үрелеп бара. Мифологик образлар ярдә-

мендә гомумкешелек кыйммәтләре, яшәеш кануннарына бәйле мәсьәләләр күтәрелә.

Җәмгыять кешене ялгызлыкка китерә дигән фикер авторның 2002 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелгән, татар театры тарихына Марсель Сәлимҗанов куйган соңгы спектакль буларак кереп калган «Баскетболист» комедиясендә дә урын ала. Биредә дә тормышның шартлы-метофорик моделе бирелә. Вакыйгалар яңгырдан соң утрау хәлендә калган Баткаклы авылында бара. Монда хәтта техника белән дә кереп булмый. Әсәрдә авыру, инвалид, Африкадан килгән кеше, эчкечелектән интегүче халыкның фаҗигасе тасвирлана. Пьеса геройлары ил күләмендә башланып киткән яңа иҗтимагый-социаль шартларга яраклаша алмыйлар. Биредә шартлылык авыл атамасының бирелеше, геройларның исеме, образларның сурәтләнешендә ачыла. Сократ, Диоген, Платон, Венера кебек образлар аша драматург кешеләрнең тормыш баткагында югалып калуларын, җәмгыять тарафыннан читкә кагылуларын бирә. Ә. Закирҗанов сүзләре белән әйткәндә, алар – бер яктан, мәгънәсез, хәтта көлке генә уята торган комиклар, икенче яктан, яңа социаль шартларга җайлаша алмыйча аптыраган, кыйблаларын югалткан фаҗигале шәхесләр» [Закирҗанов, 2004, б. 100–101]. Мәсәлән, төп геройларның берсе – кайчандыр укытучы булып эшләгән Сократ, мәктәп ябылганнан соң, эшсез калуын кабул итә алмый. Баскетболист булып, дөнья күләмендә беренчелекне алам дип йөри. Чарасызлык Сократның күршесе Диогенны да эчкечелеккә этәрә. Шунысы игътибарга лаек, Сократның хыялы артында кешенең бәхеткә, матур яшәешкә омтылышы ята. Платон да вакыйгалар барышында күршеләрен иген игәргә, бәрәңге, суган үстерергә өнди. Сократ хыял белән яши. Нәкъ менә ул башкаларга да битарафлык сазлыгыннан чыгарга, үз көчләренә ышанырга ярдәм итә. А. Әхмәдуллин Баткаклы авылын – татар яшәешенең моделе, ә баскетболчыларны, бүгенге хәл белән килешмичә, яңарышка омтылучылар дип бәяли. Авылның Баткаклы дип аталуы да символик төсмер ала, ул шартлы рәвештә милләт тормышын ачарга ярдәм итә. Шулай итеп, М. Гыйләҗевның «Баскетболист» комедиясендә үзгәрешләр чорындагы ил тормышына, үзгәртеп кору тәртипләренә, илдәге һәм хакимияттәге абсурд уеннарга, халыкның чарасызлык чигенә җиткән караңгы, «баткак» тормышына пародия биреп, драматург йорт-авылны төп сурәтләү объекты ясый. Татар авылының юкка чыга баруы, мәктәпләрнең ябылуы кебек милли проблемаларны күтәрә.

А. Гыйләҗевның «Яра» әсәренә нигезләнеп иҗат иткән «Яра» драмасында М. Гыйләҗев үткән чорның социаль күренешләрен, тоталитар режим шартларында халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормыш сурәтли. Тоталитар режимның кешене шәхес буларак юкка чыгара баруын, герой фаҗигасенең күңел халәтендә ачылуын, шул дәвер сәяси кануннарының дөрес булмавын күрсәтә. Драмада, повестьтагы кебек үк, Бөек Ватан сугышыннан

соңгы авыл тормышы тергезелә. Шуларга бәйле рәвештә өлкән буын вәкилләре Сөләйман, Шәкүр, Зөләйха, яшьләрдән Габдулла, Зәйтүнә, Хәлил тормышы мисалында тоталитар системаның, совет идеологиясенең асылы ачыла. Сөләйман белән Зөләйханың сугышка киткән уллары Габдулладан өч елдан артык хәбәр юк. Шуңа күрә дә әлеге билгесезлек алар йөрәгендә яра – җан сызлавы буларак бирелә. Габдулланың сөйгәне Зәйтүнәнең яңарак сугыштан кайткан Кәримҗанга кияүгә чыгуы, хәер-фатиха алырга килүе шулай ук аларда төзәлмәслек җан ярасы тудыра. Әсәрдә даими рәвештә кабатланган авып баручы капка баганалары да шуны күрсәтүче символ буларак кабул ителә. Күңелендә тормышка яраксызлыгын аңлаган, яралардан танымаслык дәрәҗәгә килгән Габдулла әти-әнисен, сөйгәнен сагынып туган нигезенә әйләнеп кайта. Якыннарына тиешле дәрәҗәдә ярдәм итә алмаслыгын аңлаган егет кире китәргә карар кыла. Әмма аны бу адымнан Зәйтүнә туктата: баласын алып, Сөләйман карт йортына күчә. Биредә татар хатын-кызларына хас булган кыюлык, олы җанлылык чагылыш таба. Ә. Закирҗанов язганча: «...өмет һәм өметсезлек каршылыгы барлык вакыйга-күренешләрне иңләп үтә. Вакыты белән чарасызлык, көчсезлек, яшәүнең мәгънәсезлеге кебек мотивлар да яңгырап китә» [Закирҗанов, 2005, б. 43].

Драмада тоталитар режим шартлары халык өчен дәһшәтле, фаҗигале чор буларак билгеләнә: кешеләрнең, халык дошманы дип, бер гаепсезгә кулга алынуы, ата-ананың сугыш кырында балаларын югалтуы һ. б. Пьесада улларының сугыштан кайтуын көтеп яшәүчеләр арасында Шәкүр карт та бар. Аның улы Хәлилне чит ил шпионы булуда гаеплиләр. Булмаган хәлләрне ачу өчен, төрле җәзалауларга тарталар. Геройны хаксызга рәнҗетелү ярасы күбрәк газаплый, әрнетә. М. Гыйләҗев геройлары фаҗигале ситуацияләргә үз гамәлләре белән түгел, ә җәмгыятьтә туган, урнаштырылган тәртипләргә бәйле рәвештә килеп керәләр. Халык фаҗигасе аерым шәхесләрнең психологик халәтләрендә ачыла. Шулай итеп, пьесада Шәкүр карт язмышы аша ил, халык язмышындагы тагын бер фаҗигале яра ачыла. Әсәрдә Сөләйман карт йорты да символик мәгънәгә ия. Язучы төп игътибарын йортны әйләндереп алган ишегалдына юнәлтә, башка объектлар ярдәмендә аның чиген билгели. Ул бушлык, ялгызлык, җимерелгән хыяллар билгесе генә түгел, ә киләчәккә ышаныч буларак та төсмерләнә. Шул рәвешле йорт-нигез яссылыгында җәмгыятькә, совет идеологиясенә тәнкыйди караш ташлана. «Яра» психологик характердагы конфликтка корылган; персонажларның күңел дөньясы ачыла барган саен, ул конфликтның система тарафыннан рәхимсез имгәтелгән шәхесләр фаҗигасе нәтиҗәсе икәнлеге күренә. Әсәрләрдә моңа кадәр күпертелеп, идеаллаштырып сурәтләнгән социалистик җәмгыятьнең чын асылы ачыла. Яшәешнең озак еллар күләгәдә калып килгән ямьсез якларына игътибар арта, кеше һәм система каршылыгы әдәби чаралар ярдәмендә тасвирлана. Әйтергә кирәк, драмада, повестьтагы кебек, Язмыш төшенчәсен Киләчәк, Тарих белән янәшә карарга мөмкин.

М. Гыйләҗевнең милләт язмышы мәсьәләсе «Словарь любви» җыентыгында урын алган «Төзүче, тимерче һәм бакчачы» («Строитель, кузнец и садовник»), «Бушап калган өйнең төшләре» («Сны опустевшего дома») пьесаларында да күтәрелә. Автор рухи мирасның кадерен белмәүне генә түгел, белергә теләмәүне дә гаепли, аны әхлаксыз күренешләрнең берсе дип бәяли. Әдипне яшь буынның дөньяга карашлары, яшәү принциплары, уй-хыяллары, мәхәббәт-дуслык хисләре кызыксындыра. «Төзүче, тимерче һәм бакчачы» драмасында сурәтләнгән Рәшид, Айдар, Җәмилә, Гөлнара образлары аша драматург яшьләр арасында әхлаксыз күренешләрнең артуын, хатын-кызларга хас гүзәл сыйфатларның югалуын, «саф» мәхәббәтнең «ирекле» мәхәббәткә алмашынуын тасвирлый. Абыйлы-энеле Айдар белән Рәшид, Гөлнара һәм Җәмилә исемле кызлар белән очраклы гына танышып, төн куналар. Вакыт узу белән, Гөлнараның рак авыруыннан үлүен, Җәмиләнең балага узып, аборт ясатуын беләләр. Төзүче, тимерче, бакчачы булырга хыялланган Айдарның фикер йөртүе аша аның ваемсыз, салкын күңелле кеше булуы ачыклана. *«Айдар. Ну так веди сюда свою подругу!...А потом она здесь останется! Будет спать с тобой! Угостишь меня своей невестой!»* [Гилязов, с. 165].

Рухи яктан кыерсытылган кызларның берсе нерв системасы какшау сәбәпле (Җәмилә), җүләрләр йортына дәвалануга җибәрелә.

*«Роза. Нет она жива... Джамиля, бедная наша Джамиля... Ее обманул какой-то подлец. Какой-то донжуан!.. Вскружил ей голову, она ведь была совсем ребенком, доверчивым ребенком... Еще ничего не знала о жизни.*

*Айдар. Да, я слышал об этом...*

*Роза. У нее должен быть ребенок... Ее родители не стали рисковать... В эти дни Гулечка уже болела... Как-то все сразу... Джамиля сильно переживала все это ... Она же всю жизнь с родителями, даже не ездила одна никуда. И вдруг такое!..*

*Айдар. Что-же с ней?*

*Роза. Джамиля не выдержала всего этого... Ее отвезли в психиатрическую лечебницу ... С ней творилось что-то ужасное...»* [Гилязов, с. 167]

Әмма автор киләчәккә өметен өзми. Рәшитнең үз хатасын аңлап туры юлга басуы, гаилә кору теләге, Җәмиләнең акрынлап терелүе – шуның ачык мисалы. Шулай итеп, драматург җәмгыятьнең рухи яктан зәгыйфьләнә баруы, шуның нәтиҗәсендә гаепсез язмышларның һәлакәткә килүе проблемасын күтәрә.

М. Гыйләҗевның «Ялгыз йортның төшләре» пьесасында кайчандыр көчле янгыннан соң авылның күп кенә кешеләрен үзендә сыендырган җылы, якты йортның вакытлар узу белән караңгы, салкын бинага әйләнүе, төгәлрәк әйткәндә, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, иң куркынычы – аталар һәм балалар арасында тирән упкын, аңлашылмаучанлык, мәрхәмәтсезлек сурәтләнә. Әйтергә

кирәк, йорт образы татар әдәбиятында һәрчак үзәктә тора [Батталова, б. 60]. Йортка уңай мөнәсәбәт авыл прозасы белән килеп керә. М. Гыйләҗевта йорт – нигез, йорт – нәсел, йорт – милләт чылбыры кебек мәгънәви төсмерләр ала. «Ялгыз йортның төшләре»ндә ул – гаилә тормышы, хуҗа, аның матди хәле, җәмгыятьтәге урыны, шәхси сыйфатлары, холык-фигыле хакында мәгълүмат та бирүче. Йортның салкынаюы күнегелгән тәртипләрнең җимерелү мотивы булып тора. Йорт хуҗалары бары тик үз мәшәкатьләре белән генә яшиләр. Шуларга бәйле рәвештә, җинаятьчелек, эчүчелек, тормышта үз урыныңны таба алмау мәсьәләләре күтәрелә.

Драматургның «Мәхәббәт сүзлеге» драмасында патриотик хиснең югалуы, чит җирдәге бай тормышка кызыгып яшәү кебек вакыйгалар тасвирлана. Биредә белемле, тәрбияле (Тәлгать), тормышка җиңел карашлы (Фердинанд), төскә-биткә чибәр, акыллы (Зөбәрҗәт) студентларны, «яңа байлар» социаль катламы вәкилләрен – Зөбәрҗәтнең әти-әнисен, төрмәдә утыручы бандитларны да очратырга була. Драманың төп геройлары – ярлы, биткә ямьсез, әмма киң күңелле, фән өлкәсендә сәләтле Тәлгать исемле студент егет белән бай кыз Зөбәрҗәт бер-берсенә гашыйк булалар. Ләкин кызның әти-әнисе Зөбәрҗәтне егерме яшькә олырак америкалы байга кияүгә бирмәкче була. Драматург чынбарлыкның вәхшилеген, үз милләтеңнән, телеңнән баш тарту кебек тискәре күренешләрне тетрәндергеч ситуацияләрдә таба. Ниятләренә ирешү өчен, кызның әти-әнисе Тәлгатьне төрмәгә яптыра. Мәхәббәтеннән көчләп аерылырга мәҗбүр булган Зөбәрҗәт, чит төбәктә озак яши алмый, тәрәзәдән сикерә. Биредә автор заман үзгәрешен байлыкка табынучы, максатларын тормышка ашырырга теләп, фаҗига китереп чыгарган бер гаилә мисалында ача. Шуның нигезендә драматург укучының игътибарын җәмгыятьне борчыган мәсьәләләргә юнәлтә.

Яшәешебездә әхлаксыз күренешләрне, ирекле мәхәббәтнең киң таралыш алуын бирүдә дә драматург натуралистик картиналарга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, тулай торакта ирекле мәхәббәтнең урын алуын автор студент егет Фердинандның яшәү рәвеше аша тасвирлый. Яисә, төрмә колоритын бөтен тулылыгы белән күрсәтү өчен, драматург тоткыннарның сөйләменә хас жаргон сүзләрне киң куллана.

Ташландык авылда урнашкан иске мәчет образы да игътибарны җәлеп итә. Ул – халыкның ислам дине кануннарыннан, гореф-гадәтләребездән читләшә баруын күрсәтүче образ. Әмма, Тәлгать әлеге мәчеттә җанына рәхәтлек, тынычлык таба, Зөбәрҗәтнең үле гәүдәсен шунда алып килә. Пьесаның финалы трагедия белән тәмамлануга карамастан, биредә милләтебезнең киләчәгенә ишарә бар.

Билгеле булганча, Г. Камал театры 2009 елда М. Гыйләҗев һәм Р. Хәмид тарафыннан язылган «Курчак туе» спектаклен тамашачыларга күрсәтте. Билгеле булганча, милләт язмышы – элек-электән күтәрелгән проблемаларның берсе [Закирҗанов, б. 7]. Пьеса Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз», «200 елдан соң инкыйраз» әсәре

нигезендә иҗат ителгән. «Курчак туенда» татар милләтенә бетү куркынычы янау искәртелә. Г. Исхакыйның әлеге әсәрләре шул заманда ук яшьләрне милләт өчен куркыныч афәтнең киң җәелә башлавы хакында кисәтә. Ул чорның драмасы бүген дә актуаль. Элек татар байлары арасында курчак туе ясау гадәте булган. Төп герой Камәр – курчак тегүче. Әсәр Казанның иң бай, иң дәрәҗәле сәүдәгәре Сәлим бай өендәге курчак туе белән башлана. Шул вакыйгаларда Сәлим байның курчаклар белән генә түгел, кешеләр язмышы белән дә уйнавы күренә. Компаньоны Гайни байны банкротка әйләндерә. Байларга кәләпүш тегеп көн күрүче Кәримәнең кызы – 15 яшьлек Камәргә күзе төшә. Камәр яшьли әтисез кала һәм үзен чолгап алган мохитнең корбаны буларак җанлы курчакка әверелә. Камәрнең сөйгәне приказчик Вафаның да курчак уеннары белән мавыгуы, калган байлардан әллә ни аерылмавы ачыклана. Үз язмышын үзе хәл итә алмаслык дәрәҗәгә җиткән Камәр Оренбургка китә, фәхешханә хуҗасы Наташа белән таныша. Оренбургның иң затлы фахишәсенә әйләнә. Шул рәвешле, байларның әлеге уеннары бозыклык, азгынлык билгесе буларак бәяләнә. Камәр әсәрнең финалында берүзе салга утырып китә. Беренче карашка, әлеге вакыйга геройның һәм туачак баласының өметле киләчәге буларак кабул ителә. Икенчедән, салның Камәрне еракка, билгесез тарафка илтеп җиткерә алуы да шикле.

2019 елда М. Гыйләҗевның «Исәнмесез?!» пьесасы Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды. Аны театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштерде. Пьесаның геройлары – Исламовлар нәселенә караган гаилә әгъзалары. Әсәрнең нигезендә туганнар арасындагы мөнәсәбәтләрне яктырту ята. Беренче карашка пьеса гади бер нәсел турында кебек тоелса да, анда милләт язмышы ярылып ята.

Пьесаның төп герое, пенсиядәге травматолог Тамерлан Исламов башта әти-әнисенең үлемендә гаепле дип санаган кияүне үз араларына кертергә теләмәсә дә, аның рак белән авыруын белгәч үзгәрә. Аны Германиядә дәвалау өчен, акча җыя башлый. Туганнарыннан җитәрлек күләмдә акча җыя алмагач, йортын сата. Дөрес, Германиядән терелгән кебек булып кайтса да, Мөслимнең гомере бик аз калганлыгы билгеле була. Тамерлан аңа үзе операция ясарга алынмакчы. Пьесада ул аны ясый, Мөслим операция өстәлендә җан бирә. Ә спектакльдә төп герой операция ясарга өлгерми – Мөслим вафат була. Спектакльдә сабантуй колгасы актив кулланыла. Вакыйгалар сабантуй чоры белән бәйле һәм шушы колга тирәсендә әйләнә. Колганы утырталар, төбендә утырып эчәләр, сугышалар, кисеп аудармакчы булалар, саклап калалар, тагын утырталар. Нәтиҗәдә, колга сакланып кала. Язмыш сынаулары, тормыш кыенлыкларында да кеше булып кала белү белән бәйле гуманлылык идеяләре алга сөрелә. Алар эчке, гаилә мөнәсәбәтләре кебек төшенчәләр турында уйландыра, комсызлык, эчкечелек кебек иҗтимагый-сәяси проблемаларны күтәрә. М. Гыйләҗев, чорга бәйле рәвештә, халыкның мөстәкыйльлеккә

омтылышын яклап, барлык татар халкының берләшүе генә киләчәк уңышларга нигез була алуын ассызыклый. Символик төшенчәләргә нигезләнгән пьесада милли бердәмлек идеясе өстенлек итә.

М. Гыйләҗев әсәрләре тарихи, фәлсәфи, социаль эчтәлекләре белән күп проблемаларны һәм төрле заманнарны иңләргә мөмкинлек бирә. Шул рәвешле, аянычлы язмышлы шәхесләр образлары аша халык драмасы чагылыш таба. Батырлыкка, азатлыкка, дуслыкка, саф мәхәббәткә омтылу рухы әсәрләрне берләштерә. Драматургны кеше рухы, аның Җир йөзендәге хәяте кызыксындыра. Авторны татарның яшәү рәвеше, яшәү мәгънәсе, милли рух югала бару борчый. Бу – халык язмышы, халык драмасы, аерым кешеләр фаҗигасеннән бигрәк, җәмгыятьнең авыру икәнен күрсәтүче фактор буларак кабул ителә. Драматург иҗатында заман концепциясе байый, катлаулана.

Соңгы елларда шартлылыкка, символик образ-сурәтләргә, метафорик күренешләргә игътибар аеруча артты. Драматурглар ялгызлыкка дучар ителгән, якыннары белән уртак тел таба алмаган, яшәешкә үтеп кергән миһербансызлыкларга каршы тора алмаудан гаҗиз калган шәхесләрне әдәбият мәйданына чыгаралар. Герой фаҗигасен тудыручы сәбәпләр социаль җирлек белән бәйләп аңлатыла. Бер төркем әсәрләрне милли тема берләштерә, аларда милләт язмышы, гореф-гадәтләрнең сакланышы күтәрелә. Шулар белән янәшә совет тәртипләрен фаш итү, идеологиянең кешене шәхес буларак юк итүдәге роленә дә басым ясала. Фаҗигалелек категориясенең шәхес ялгызлыгында, чынбарлык белән трагик каршылыкта чагылуы ассызыклана. М. Гыйләҗев укучы-тамашачы игътибарын татар халкының яшәешенә бәйле мөһим проблемаларга юнәлтә (гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, авылларның бетүе һ. б.). Әрнү һәм хыял ташып торган бу әсәрләр татар милли идеясен уяту ягыннан зур әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

*Әхмәдуллина А.* Һәр Баткаклының үз Сократы булса иде // Мәдәни җомга. 2002. 8 март.

*Батталова А.Д.* Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар). Казан, 2009.186 б.

*Гыйләҗев М.* Бичура. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 161 б.

*Гилязов М.* Словарь любви: Пьесы. Казан: Татар. кн. изд-во, 2005. 399 с.

*Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 175 б.

*Миңнуллина Ф.Х.* М. Гыйләҗевның «Бичура» драмасында мифологик образлар // Ислам и тюркский мир: проблемы образования, языка, литературы, истории и религии. Материалы VIII Международной тюркологической конференции. Елабуга, 2016. Б. 131–133.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Г.Р. Гайнуллина***

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА ИҖАТ ӘҺЕЛЛӘРЕНӘ ХАС СЫЙФАТЛАР ТУРЫНДА

Публицистика А. Еники – одна из малоизученных областей в творческой биографии классика татарской литературы. Публицистика писателя интересна тем, что в ней ставятся вопросы о языке художественного произведения, об отношении писателя к творчеству, к вопросу интеллигентности, народности творца. В статьях, воспоминаниях, написанных в 1960–1970-х годах, посвященных великим татарским художникам слова, А. Еники ставит проблемы служения национальной культуре и литературе.

**Ключевые слова:** публицистика, воспоминания, язык художественного произведения, творчество, А. Еники, Л. Толстой, Г. Тукай, С. Сайдашев, Н. Исанбет, А. Файзи

A. Eniki's journalism is one of the poorly studied areas in the creative biography of the classic Tatar literature. The writer's journalism is interesting in that it raises questions about the language of artwork, the attitude of the writer to creativity, to the question of intelligence, the creator's nationality. In the articles, memoirs, written in 1960–1970s and devoted to the great Tatar artists of the word, A. Eniki poses the problem of serving the national culture and literature.

**Keywords:** journalism, memories, language of artwork, creativity, A. Eniki, L. Tolstoy, G. Tukay, S. Saidashev, N. Isanbet, A. Faizi.

Егерменче йөзнең 60–80 еллары – татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту чоры – татар прозасында яңа эзләнүләр, яңа сукмаклар, психологизм, тәнкыйди, лирик-эмоциональ, публицистик башлангычлар көчәю, стиль тенденцияләре, сәнгати алымнар байлыгы белән билгеләнә [Заһидуллина, 2011, б. 28]. Хәлбуки, милли нигезләргә кайту чоры әдәбиятында әдәби тәнкыйть тә, милли әдәбиятны бәяләү җәһәтеннән, башка югарылыкка күтәрелә. «Әдәбият тарихында, иң беренче чиратта, язучылар һәм шагыйрьләр буларак бәяләнгән каләм ияләре чор тәнкыйтендә актив катнаша» [Гыйләҗев, б. 8]. Әдәбият галиме Ә. Закирҗанов карашынча, әдәби тәнкыйтьнең зур өлешен язучы тәнкыйте тәшкил итә [Закирзянов, с. 250]. Галим соңгы елларда бу күренешнең аеруча активлашуын билгеләп үтә. Аерым бер проблеманы бергәләп хәл итү турында уйлану, әдәби барышның киләчәген фаразлау максатыннан әдәби тәнкыйтьнең язучы тәнкыйте дип исемләнгән төре аеруча әһәмияткә ия. Язучыларның тәнкыйди язмалары матбугат битләрендә һәрдаим дөнья күрә. Тәнкыйть үзенең игътибарын (әдәбият белән берлектә) милли эчтәлекле мәсьәләләргә – рухи бәйләнешләр өзелү, традиция-гадәтләрнең, телнең югала баруы, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе, туган җир, туган нигез кадеренең кимүе кебек проблемаларга юнәлтә.

1960–1980 елларда Әмирхан Еники милли әдәби-мәдәни мохит, каләмдәшләре, остазлары турында шактый бай эчтәлекле мәкаләләр яза. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина милли нигезләргә кайту дәвере татар прозасындагы үзгәрешләрнең башында Ә. Еники тора дип билгеләп үтә: «Алга таба башка язучылар иҗатында дәвам итәчәк авангард эзләнүләрнең чишмә башы шушы иҗатта булуы, милли әдәбиятны яңа сыйфат үзгәрешенә китерүе бәхәссез» [Заһидуллина, 2015, б. 158–159]. Мәкаләләрендә дә милләткә хезмәткә гомерен багышлаган бөек әдипнең фикер-карашлары, әрнү-сызланулары чагылыш таба. 1960–1980 еллар әдәби барышын бәяләгән вакытта Ә. Еникинең истәлек язмалары гаять зур әһәмияткә ия.

Әдипнең бу чор публицистикасы «Хәтердәге төеннәр» (1983) дип исемләнгән җыентыгында дөнья күрә. Биредә тупланган мәкалә, язмаларда гомерләрен халыкка хезмәткә багышлаган Г. Тукай, Г. Ибраһимов, С. Сүнчәләй, Н. Исәнбәт, Г. Кутуй, Х. Туфан, Ә. Фәйзи, С. Сәйдәшев һ. б. кебек олуг шәхесләребез яңа яктан ачыла.

Могтәбәр язучыларның иҗат юлын тасвирлап, Ә. Еники берничә мәсьәләгә аерым туктала. Беренчедән, әдипне язучының иҗатка мөнәсәбәте мәсьәләсе борчый, уйландыра, кулга каләм алырга мәҗбүр итә. Һәр мәкалә-язмасында бу проблемага кагылышлы бер фикер-караш җиткерелә, язучының әдәбиятка мөнәсәбәте ачык билгеләнеп куела. Әйтергә кирәк, татар әдәбиятының иң якты йолдызларын ул һәрвакыт бөек Г. Тукай белән янәшә куя, әдәби барыштагы иң шәрәфле исемнәрне шул үлчәмгә сала.

«Нәкый Исәнбәт» (1960) дигән баш астында бирелгән мәкаләсендә Ә. Еники «Тукай исән вакытта ук яза башлаган» олпат шәхеснең күптармаклы иҗади эшчәнлеген гади һәм төгәл, анык итеп бәяләүгә ирешә. Олы исемле шәхеснең зур уңышка ирешүенең бер сәбәбен ул түбәндәгечә билгели: «Мин аны язучының әдәби мирасыбызга, әдәбиятыбызның алдынгы традицияләренә һәм, ниһаять, корымас чишмә кебек өзлексез бәреп торган халык иҗатына таянуын атар идем. Билгеле инде, таза җирлеккә нык басып тору язучыбызга халык рухын дөрес хис итүдә һәм милли үзенчәлекне саклауда, һичшиксез, зур ярдәм иткән булырга тиеш» [Еники, б. 6].

Язучы иҗатының төп нигезе – әдәби мирас, халык рухын тоя белү булырга тиеш дигән караш әдипнең публицистик мирасында кызыл җеп булып сузыла.

Ә. Еники әдәби әсәргә нәзари яссылыкта бик таләпчән якын килә. Язучы иҗат иткән вакытта әдәби төр, жанр таләпләренә таянып язарга бурычлы дигән карашны мәкаләләрендә еш кабатлый. Н. Исәнбәт драматургиясен бәяләгәндә, Ә. Еники бу төрнең аерым закончалыкларын ассызыклап үтә: «Нәкъ сәхнә таләп иткәнчә, эчке интонациягә бай, үткер сөйләм теле, индивидуаль характерларга ия чын кеше образлары. Оста һәм тыгыз үрелгән конфликт – менә аның әсәрләренә хас сыйфатлар» [Еники, б. 5].

Г. Ибраһимов шәхесенә мөнәсәбәтле язылган «Безне ул өйрәтте» (1962) дип исемләнгән мәкаләдә ул Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовны «прозаны яңа биеклеккә күтәрүчеләр дип олылый [Еники, б. 8]. Шул урында язучының нәзари мәсьәләләрне дә калкытуы игътибарга лаек: «Иң элек ул хикәяләү чарасының компонентларын бик нык арттырды һәм киңәйтте: без инде аның әсәрләрендә кешеләрнең, примитив прозага хас булганча, исемнәрен һәм дә хәрәкәтләрен генә түгел, тулы портретларын күрәбез, характер үзенчәлекләрен, рухи кичерешләрен ачык сизәбез. ... Һәр хикәясенә, һәр романына диярлек я вакыйганың фоны-җирлеге, я образның рухи халәтен ачыклаучы чара, я авторның фикерен көчәйтүче символик образ булып, табигать күренешләре әсәрнең тукымасына органик рәвештә керә. ...Ниһаять, ул диалог формаларын төрләндерә, эчке монологларга киң урын бирә, хикәяләүне һәрвакытта киеренке-хәрәкәтчән итеп алып бара» [Еники, б. 8].

Ә. Еники каләмдәшләренең замана хакыйкатенә күз йоммыйча, дөреслекне әйтү юлларын табуларына игътибар итә: «Ләкин Исәнбәт нәрсә турында гына язмасын, ул – барыннан да элек замана язучысы. Күп әсәрләрен ул үзе яшәгән заманның зур вакыйгаларына багышлый, күп әсәрләрендә ул замандашларын борчыган мәсьәләләрне күтәреп чыга... Хәтта аның бик борынгы темаларга язылган әсәрләрендә дә хәзерге заман белән аваздашлык бик ачык сизелеп тора [Еники, б. 6].

«Халык күңеленә юл салу ансат эш түгел: язучыдан саф вөҗдан, чын гаделлек, искиткеч зур тырышлык һәм батырлык сорый ул» [Еники, б. 3] , – дип яза Ә. Еники. Әдипне иҗат әһеленең, аның әсәрләренең халыкка мәгълүм булу-булмавы уйга сала. Н. Исәнбәт турында: «Бер нәрсә күңелне юата: халкыбыз Нәкый Исәнбәтнең кем икәнен бик яхшы белә. Ул аны үзенең иң өлкән, иң популяр милли язучысы итеп таный, ярата һәм хөрмәт итә» [Еники, б. 3]. С. Сүнчәләй турында язылган «Шагыйрь ерак сәфәрдән кайтты» (1962) мәкаләсендә Ә. Еники «Тукай, Дәрдемәнд, Рәмиевләр белән бер заманда яшәгән, башта ук Тукайның фатихасын алып әдәбиятка кергән» шагыйрьнең «билгеле бер тарихи сәбәпләр аркасында утыз елдан артык безнең әдәбияттан югалып торуын» [Еники, б. 10] эчке бер әрнү белән билгеләп үтә. Шул ук вакытта Ә. Еники С. Сүнчәләйнең шигъри җыентыгы басылу уңаеннан төзүчеләргә, кереш сүз язучы Гали Халиткә аерым мәсьәләләргә бәйле тәнкыйтен җиткерә: «Менә кулыбызда шагыйрьнең утыз биш ел үткәннән соң беренче тапкыр дөньяга чыккан кечкенә җыентыгы. Шулай булгач, хәзер Сүнчәләй әсәрләрен җыеп чыгару мәсьәләсенә җитди килергә, һәрьяклап уйларга кирәк иде. ...Ләкин гамәлдә нәкъ киресе: Шәриф Сүнчәләй төзегән һәм мирас комиссиясе (комиссиядә мәрхүм Әхмәт Фәйзи, Риза Ишморат һәм мин идем) карап тәкъдим иткән әсәрләрнең бик күбесе китапта юк» [Еники, б. 15]. Нәшрият төшереп калдырган берничә шигырьне тәкъдим итеп, язучы ачыктан-ачык шелтә белдерә: «Сайланма әсәрләр»гә, әлбәттә, сайлап кертергә кирәк! Ләкин шулай

сайларга кирәк ки, китаптан шагыйрьнең күләгәсе генә түгел, ул яшәгән чор үзе ачык күренеп торырга тиеш» [Еники, б. 16]. Гали Халит язган кереш сүзгә мөнәсәбәтле фикердә дә Ә. Еники язучының, әдәбият галименең укучы алдындагы изге бурычын атый, соңгы фикерне ул әйтәчәген искә төшерә: «Теге яки бу язучының иҗатын һәрьяклап ачу һәм тарихи дөрес итеп аңлата белү алар өстенә төшә» [Еники, б. 16]. Язучы гомерен халыкка хезмәткә багышлаган шагыйрьнең Г. Тукай белән дустанә мөнәсәбәтләре темасын да калкыта. Ә. Еники С. Сүнчәләйнең Г. Тукайга багышлап биш истәлек, җиде шигырь язуын билгеләп үтә. «Мәрхүм Ә. Фәйзи Тукайның Сүнчәләйгә язган хатлары һәм Сүнчәләйнең Тукайга багышланган истәлекләре, шигырьләре белән танышкач, боларның барысын да «Тукай һәм Сүнчәләй» дигән исем астында кечкенә бер китап чыгарырга кирәк дип әйткән иде» [Еники, б. 17]. Ә. Еники китапта биш истәлекнең икесе генә урын алуына, җиде шигырьнең берсе дә булмавына карата да тәнкыйть белдерә.

Ә. Еникинең әсәр теле мәсьәләсенә үтә дә җаваплы якын килгәнлеге билгеле. «Әсәрнең теле турында» (1967) исемле язмасында әдип болай дип билгеләп үтә: «Язган чакта әсәрнең теле ниндидер бер кодрәт белән үзеннән-үзе җиңел генә агып бара дип уйлау һич кенә дә дөрес булмас иде. Тел ярдәмендә ни әйтергә, нәрсә күрсәтергә телисең – хикмәт шунда бит. Хәтта әсәрне редактор өстәленә илтеп салганнан соң да баш ватудан туктамыйсың – күңелгә ошамаган берәр сүз сине, җаныңа кадалган шырпы шикелле, гел борчый тора. Әсәр иҗат итүнең бөтен авырлыгы да, минемчә, нәрсә хакында язудан бигрәк, ничек итеп язуга кайтып кала» [Еники, б. 18].

Әсәрнең теле мәсьәләсендә ул Г. Ибраһимовны үзенең остазы дип атый, аны «әдәбиятыбызда хикәяләүнең үрнәк булырлык гүзәл бер стилен тудыручы» аерым мәктәп булдырган әдип дип олылый: «Галимҗан теле – үзенә бер тел ул. Иркен, җиңел, бай, матур тел. Асылда ул безгә проза теленең иң үтемле, саф татарча үрнәген эшләп калдырды. Аның бу үрнәгендә без телебезнең гаҗәп бай эчке мөмкинчелеген, фикерне әйтеп бирә алуда һәм сурәтләп күрсәтүдә зур сәләткә ия булуын күрдек. Галимҗан аркасында безнең телебез, үзенең саф татарча булуын саклаган хәлдә, русның әдәби теленнән үрнәк алып, ничектер мәдәниләште, камилләште, бай телләр рәтенә керерлек хәлгә килде. Тел иркен һәм тигез ага башлады, аның шигърияте һәм аһәңе көчәйде» [Еники, б. 19].

Г. Ибраһимовка иярү күренешләрен билгеләп үткәннән соң, Ә. Еники иҗатта «иярү, күчерү, охшату»ны «кәсепчелек белән шөгыльләнү» кебегрәк бәяли: «Һәрбер язучының теле аның үзенә генә хас табигый тел булырга тиеш» [Еники, б. 19]. Шунда ук әдип: «Мин тел җәһәтеннән үземә охшаган язучыларны өнәп бетермим. Теле минекеннән аерылып торса, шул миңа күбрәк ошый, һәм бу табигый да, минемчә» [Еники, б. 19], – дип белдерә.

Язучы әдәби әсәрдә автор теле һәм персонаж теленә кагылышлы мондый фикерләр җиткерә: «Әсәрдәге персонажларның телен яшенә,

кем булуына, профессиясенә карап индивидуальләштерүне, һичшиксез, кирәк, дип саныйм. Ләкин бер шарты бар: индивидуальләштерү белән кирәгеннән артык мавыгып китмәскә, ягъни персонаж телен махсус терминнар яки жаргон сүзләр белән күп итеп чүпләмәскә кирәк. Билгеле, авторның үз теле персонаж теленнән күпмедер дәрәҗәдә аерылырга тиеш. Бу һәр язучының талантына һәм осталыгына бәйле» [Еники, б. 19].

Әдип әсәрне язу осталыгына бәйле принципиаль карашын түбәндәге юлларда җиткерә: «Әсәрне язу бар, ясау бар. Менә без барыбыз да ясарга шактый остардык. Шуның аркасында шома эшләнгән әсәрдән талантлы язылган әсәрне аера алмый башладык. Гадәттә яңа әсәрнең темасына, эчтәлегенә бөтен игътибарны биреп, аның әдәби сыйфатына, сәнгать дәрәҗәсенә юньләп күз дә салмыйбыз яки ул ягы турында бик аз сөйлибез. Әдәби әсәр барыннан да элек сәнгать әсәре бит әле ул» [Еники, б. 28] .

Ахыр килеп, милләтебезнең иң затлы сыйфатларын күңелендә кадерләп саклаган зыялы әдип Ә. Еники үзенең мәкалә, очерк, истәлекләрендә зыялылык мәсьәләсенә кайта-кайта туктала. Зыялылар рәтенә Ә. Еники Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Миркасыйм Госманов кебек олпат шәхесләрне кертә. Ә. Фәйзи турында әдипнең шактый югары фикердә булуы сизелеп тора: «Бик белемле, бик мәдәни, гимназия тәрбиясе алган. Үзен тотышында, кешегә мөнәсәбәтендә зыялы булуы сизелеп тора иде» [Еники, б. 194]. «Чын кеше, чын иҗатчы» (1960) дип исемләнгән мәкаләсендә Ә. Фәйзи шәхесенә бәйле зыялылык мәсьәләсен язучы шәхесенә бәйләп күтәрә: «Шактый сыналган бер нәрсә бар: тормыштагы тере язучы үзе һәм әсәрләре аша укучы хыялында туган аның образы күп кенә очракта ни өчендер туры килеп бетмиләр. Образ үзенең асылыннан яхшырак булып чыга (хәер, киресенчә дә булырга мөмкин). Менә мин үзем Фәйзидә әнә шул «туры килеп бетмәүне» күрми идем. Фәйзи өчен әдәби иҗат хәят иде. Шуның белән яши, шуның белән сулый иде ул. Язучының сафлыгы, гаделлеге, һәртөрле фани исәп-хисаплардан өстен торуы, үзе инанганга тугрылыклы булып калуы – аның өчен язылмаган кануннар иде» [Еники, б. 110].

Ә.Еники татар зыялылары Н. Исәнбәт, Ф. Хөсни, К. Тинчурин, С. Сәйдәшев һ. б. замандашлары белән бәйле истәлекләре белән дә бүлешә. Зыялылык мәсьәләсен әдип халык күңеленә юл салу җәһәтеннән кузгата. Н. Исәнбәтне әдип «саф вөҗдан, чын гаделлек, искиткеч зур тырышлык, батырлык иясе» [Еники, б. 3] дип бәяли. Зыялылык турында сүз кузгатканда, Шакир Шамилскийга бәйле фикерләре дә игътибарга лаек: «Чөнки артистлык аның өчен бары кәсеп кенә булмады, артист дип аталу аның өчен сәнгать кешесе, зур культура иясе булу дигән сүз иде» [Еники, б. 65]. Әдип чын талант ияләренә гадилек, тыйнаклык, затлылык, әдәп хас дип саный: «Шул ук вакытта аның бөтен торышыннан затлылык, культура, әдәп сизелеп тора. Ул бик пөхтә киенеп йөри, хәрәкәтләре аның салмак-нәфис, сөйләшүе, үз дәрәҗәсен

яхшы белгәнлектән, беркадәр генә горур, әмма масаюсыз, ачык күңелдән» [Еники, б. 66]. Халыкның тирән мәхәббәтен яулау өчен, «көч һәм гүзәллекне җыйган» булу тиеш, дип билгеләп үтә язучы.

Ә. Еники татар музыка сәнгатенең беренче профессиональ композиторы С. Сәйдәшев иҗатына аеруча игътибарлы: публицистикасында да, әдәби иҗатында да аның эчке дөньясына кайта-кайта мөрәҗәгать итә: «Сәйдәш шәһәр баласы, үз заманының алдынгы татар зыялылары арасында үсеп җитешә, шәһәр культурасы белән сугарыла. Салих Сәйдәш бөтен килеш-килбәте белән бик пөхтә, чибәр, нәфис бер кеше иде. Һәм музыкасы да аның якты, нәфис ... һәм күтәренке-дәртле дә иде» [Еники, б. 76]. Композиторның эчке зыялылыгы турында сөйләгәндә, әдип бер вакыйгага туктала: «Бер заман газетада ниндидер уңай белән бүләкләнгән сәнгать әһелләренең исемлеге басылып чыга. Вакыйганы сөйләүче – шагыйрь – шул газетаны сатып алып, урамда карый-карый бара. Аңа Сәйдәш очрый. Туктыйлар, исәнләшәләр. Шагыйрь газетаны күрсәтеп әйтә: менә монда ни өчендер синең исемең юк, ди. Шуңа каршы Салих тыныч кына: «Ник булмасын, минем Салих Сәйдәш дигән исемем бар», – дип җавап бирә» [Еники, б. 80].

Зыялылык мәсьәләсен әдип, аңлашыла ки, язучы буларак күтәрә, бәяли, иҗат кешесенә хас булган сыйфатларга аерыбрак туктала. Шул ук вакытта әдипне «чын кеше булу» мәсьәләсе гел борчып торганлыгы, уйланырга мәҗбүр иткәнлеге сизелә: «...Белгеч яки галим булу, хәтта язучы булу авыр түгел, әмма чын кеше булу – шактый читен эш. Талантың һәм көчле теләгең булып инде әдәбиятка килгәнсең икән, дан-дәрәҗәң турында уйламый тор, күбрәк укучың турында уйла, борчыл. Син аңа белгәнеңне, ышанганыңны яз, ул да сиңа ышансын. Әдәби осталыгыңны камилләштерү турында көн-төн кайгырт, эзлән, тырыш. Таләпчәнлек, тагын бер мәртәбә таләпчәнлек» [Еники, б. 33].

Бу җәһәттән, татар язучысының бөек рус язучысы Лев Толстой турында уйлануларын билгеләп үтү мәслихәт. Ясная Полянага сәяхәттән соң, әдип фикер-карашларын «Косогор заводы – Муса Җәлил –Ясная Поляна» (1955) дип исемләнгән мәкаләсендә теркәп калдыра. Әдипнең игътибарын Л. Толстой яшәгән усадьбаның затлылыгы, олпат гадилеге җәлеп итә, «нәкъ хыялда яшәгән күренеш иде бу...» [Еники, б. 90] дигән кичереш мәкаләдә кызыл җеп булып сузыла.

Татар язучысын бөек шәхеснең киңкырлы гыйлем иясе булуы хәйран калдыра: «Түбән каттагы алгы бүлмәгә керү белән күзгә бәрелгән нәрсә сары төстәге китап шкафлары булды. Бу шкафлар Толстойдан калган күп телләрдәге китаплар белән тулы. Гомумән, ике катлы зур йортның һәр бүлмәсендә гел китап очрап торды. Югары катта без язучының аерым бүлмәгә урнаштырылган китапханәсен күрдек. Нинди генә телдә һәм нинди генә эчтәлекле китап юк биредә!» [Еники, б. 91].

Ә. Еники Л. Тостойның унөч тел, шул исәптән гарәп һәм татар телләрен белгәнлеген, яһүд телен «укып аңларлык дәрәҗәдә

өйрәнгәнлеген» әйтә: «Инҗил, Коръәннән алып Маркснең «Капитал»ына һәм Ленин мәкаләләренә кадәр укыган ул» [Еники, б. 92]. Л. Толстой шәхесенең йогынтысын ассызыклау өчен, ул үзе игътибарга алган фактларны теркәп куя: «Толстойга гомеренең соңгы елында көн саен егерме-егерме бишләп хат килеп торган. Иптәш Пузинның әйтүенә караганда, Толстой үлгәннән соң бу йортта илле меңләп хат торып калган» [Еники, б. 92].

Л. Толстойның замандашлары, зыялылар даирәсе турында әдип аерып билгеләп үтә: «Заманында кемнәр генә булмаган биредә! Семьяның үз, якын кешеләре Тургенев белән Фет еш кына килеп йөргәннәр; Лев Николаевичның ихлас күңелдән яраткан әдибе («прозабызның Пушкины» дип атый ул аны), «кызлардай мөлаем Чехов бу өйдә тансык кунак булган; заманның тынгысыз кешеләре, бөек язучының игътибарын һәрвакыт үзенә биләп торган Горький белән Короленко, әледән-әле килеп, бу залда хуҗа белән кызыклы һәм мәгънәле әңгәмә алып барганнар. Шулай ук биредә Репин, Крамской, Нестеров, композиторлардан Танеев, Аренский еш кына кунак булганнар» [Еники, б. 93].

Әдипне аеруча тәэсирләндергәне – «бөек язучының эш кабинеты» [Еники, б. 94]. Ә. Еники һәр җиһазны, һәр детальне тәфсилләп тасвирлый, язу өстәле, кара савыты, китапларга аеруча мәгънә сала: «шушы өстәлдә «Сугыш һәм тынычлык». «Анна Каренина», «Яңадан туу» романнары язылган» [Еники, б. 93]. Һәм татар язучысын гаҗәпкә калдырганы – «бүлмәдәге бөтен җиһазның, бөтен обстановканың нәкъ Толстойдан торып калган хәлдә саклануы» [Еники, б. 95].

Әдип мәшһүр рус язучысының тәрәге, йөрәге Софья Андреевнага соклануын белдерми кала алмый. Аның гаилә фотоальбомы эшләгәнен, әдәбият белән шөгыльләнгәнен, нәсерләр, балалар өчен хикәяләр язуын, гомере буе көндәлек алып баруын, сигез томнан торган бик бай мемуар әдәбият калдыруын ассызыклап үтә.

Әдипнең күңелен әрнеткәне – 1941 елның көзендә фашистларның Ясная Полянаны камап алып, «хәкарәт итүләре». Шул урында Ә. Еники рус язучысын хөрмәтләгән милләт алдында баш ия. Ләкин татарда тарихи мираска мөнәсәбәтнең тиешле дәрәҗәдә булмавына ачынуын яшерә алмый: «Шул ук вакытта йортның беренче бүлмәсенә кереп карый башлагач та минем йөрәктә бер әрнү, ачыну хисе кузгалды. Бу хис бүлмәдән бүлмәгә күчә барган саен көчәя барды. Нидән туды бу әрнү һәм ачыну хисе? Моның сәбәбе безнең үзебездә – татарларда тарихи мираска, бөек кешеләребездән калган кадерле реликвияләргә хөрмәтсез карау, аларны җыймау, сакламау, әрәм-шәрәм итү, кыскасы, бу эштә искиткеч ваемсыз булу, соң чиктә культурасызлык күрсәтүдә иде» [Еники, б. 97–98].

Ә. Еники, якын дусты, гаҗәеп зыялы әдип Ә. Фәйзи амәнәте буенча, Л. Толстой кабереннән бер уч туфрак ала, һәм татар зиратына килеп, Г. Тукай каберенә сала. Гүяки, ике бөек әдипне берләштерү аша ике милләтне үзара тоташтыра язучы.

Ә. Еникинең әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге әдәби иҗатыннан аерым алып барылмый. Әдип 1960–1980 елларга караган публицистик хезмәтләрендә олпат шәхесләргә соклану аша әдәби иҗатка мөнәсәбәт проблемасы, чын әдәбиятның, мәдәниятнең туу шартлары, саклану мөмкинлеге, шуңа мәнәсәбәтле иҗади шәхеснең зыялылыгы турында кабатлап сөйли. XX йөзнең икенче яртысы әдәби хәрәкәтенә күзәтү ясаганда, язучының әдәби тәнкыйтен жанрлар төрлелеге, тема-проблематика җәһәтеннән бәяләү мәсьәләсе калка.

**Әдәбият**

*Гыйләҗев Т.Ш.* Татар әдәби тәнкыйте (1920–1930 еллар). Казан: Отечество, 2016. 240 б.

*Еники Ә.* Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 224 б.

*Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.

*Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. 198 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Статья написана и опубликована при финансовой поддержке РФФИ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта № 18-412-160016 р/ а*

***Гайнуллина Гөлфия Расил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 94(5)+(470.41)

*К.Г. Әхсәнов*

# ФАТИХ КӘРИМИ, ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ҺӘМ 1913 ЕЛНЫҢ 23 (10) ГЫЙНВАРЫНДА ИСТАНБУЛДА БУЛГАН ДӘҮЛӘТ ТҮНТӘРЕЛЕШЕ

Актуальность исследуемой проблемы обусловлена необходимостью освещения малоизвестных эпизодов в турецкой истории и российско-турецких отношениях, которыми является период балканских войн. Тема государственного переворота 23 января 1913 года в целом достаточно подробно не исследована в отечественной исторической науке, а вопрос вовлеченности в события выходцев из России почти не затрагивается в научной литературе. Цель статьи заключается в анализе материалов татарских журналистов, работавших в Стамбуле с ноября 1912 по январь 1913 гг., касающиеся внутриполитической ситуации в Османской империи. Изучив материалы, находившихся в Стамбуле во время Балканской войны татарских журналистов, можно сделать вывод, что они имели тесные связи с местными коллегами по перу, а также со многими османскими политиками, и были свидетелями, возможно, и участниками внутриполитической борьбы в столице Османской империи.

**Ключевые слова:** Балканская война, Османская империя, Турция, Ф. Карими, «Вакыт», «Йолдыз», «Иттихад ве теракки» (Младотурки), Г. Камал.

The relevance of the investigated problem is caused by the need of the coverage of little-known episodes in the Russian-Turkish relations, which is the period of the Balkan wars. The topic of the coup d'état of January 23, 1913, as a whole, has not been studied in sufficient detail in Russian historical science, and the issue of involvement in the events of people from Russia is almost not addressed in the scientific literature. The purpose of the article is to analyze the materials of the Tatar journalists, who worked in Istanbul in the first months of the Balkan War (November-December 1912) and studied the political situation in the Ottoman Empire. Having studied the materials of the Tatar journalists that were in Istanbul during the Balkan War, we can conclude that they had close ties with their local counterparts, as well as many Ottoman politicians, and have seen, and possibly were the members of the political struggle in the capital of the Ottoman Empire.

**Keywords:** The Balkan War, Ottoman Empire, Turkey. F.Karimi, «Vakyt», «Yoldyz», «Ittihad ve terrakki» (Young Turks), G. Kamal.

Мәкаләдә тикшерелгән теманың актуальлеге Төркия тарихындагы һәм Россия белән Госманлы дәүләте арасындагы аз билгеле вакыйгаларны, шулай ук XX гасыр башы рус-төрек мөнәсәбәтләрендә татар зыялыларының ролен яктырту зарурлыгыннан чыгып билгеләнә. Татар ханлыкларын Россиягә кушканнан соң, күп кенә милләттәшләребез Госманлы империясенең ислам дине терәге, Россия самодержавиесенең колониаль сәясәтенә каршы көрәштә терәк булырга мөмкин союздаш икәнен төшенәләр. Идел-Урал төбәгендә яшәүче татарлар һәм Госманлы империясе арасындагы мәдәни бәйләнешләр

берничә гасырны колачлый. XIX гасыр урталарында Госманлы империясенең алдынгы Европа илләреннән артталыгын бетерүне максат иткән Танзимат (үзгәртеп кору, реформалар) чоры башлангач, Россия мөселманнарының Төркия белән кызыксынуы яңадан көчәя.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 1905–1907 еллардагы Рус революцияләре чорында барлыкка килгән татар вакытлы матбугатында госманлы төрекләре темасы, традицион рәвештә, үзәк урыннарның берсен алып тора.Татар газета-журналлары Госманлы империясендә барган вакыйгалар белән бик нык кызыксына. Шул ук вакытта кайбер татар журналистлары һәм мөхәррирләренең тормышы теге яки бу дәрәҗәдә Төркия белән бәйләнгән була: алар анда йә белем алалар, йә туганнары яши (Йосыф Акчура, Фатих Кәрими). Госманлы империясенең иҗтимагый-сәяси тормышы белән бәйле вакыйгалар татар матбугаты аудиториясендә бик тиз яңгыраш таба. 1908–1909 еллардагы Яшь төрекләр инкыйлабын татарлар дәртләнеп каршы алалар. Госманлыларның Африкадагы соңгы биләмәләре – Триполитания һәм Киренаикины (хәзерге Ливия) яулап алу максаты белән Италия хәрби кампания башлап, 1911–1912 еллардагы Триполитания сугышы барганда да, татар матбагалары Төркиягә теләктәшлек белдереп чыга. 1912–1913 еллардагы Балкан сугышлары белән бәйле вакыйгалар татар матбугатында аеруча зур резонанс тудыра. Албания, Македония һәм Фракия территорияләрендә җәелгән Беренче Балкан сугышының башында госманлылар гаскәре авыр җиңелүләргә дучар була. Болгарлар Адрианопольне камап алалар һәм Истанбул шәһәре читендәге Чаталҗага килеп җитәләр. Союздашлар (Греция, Сербия, Болгария һәм Черногория) туктаусыз һөҗүм итеп торганда, татар җәмәгатьчелеге фронтлардагы хәлне борчылып күзәтә. Аеруча күп укыла торган басмалар мәкаләләрне күчереп басу һәм сылтама бирү белән генә чикләнми, ә сугыш хәрәкәтләре барган районнарга үз хәбәрчеләрен җибәрә. Әмма Төркиягә килгән журналистлар хәрби хәрәкәтләрне генә бәян итеп калмыйлар. Шул заманда Төркияне чолгап алган кискен эчке сәяси көрәш эченә үзләре дә тартылалар.

Балкан сугышлары чорында татар журналистларының Төркиядәге эшчәнлеге темасы татар галимнәренең хезмәтләрендә кабат-кабат күтәрелә. Фатих Кәримигә багышланган фәнни-биографик җыентыкка кереш мәкаләсендә академик М.Г. Госманов, «Истанбул мәктүбләре»нә бәя биреп, татар журналисты 1913 елда ук империячел «госманчылык» идеологиясенең банкротлыкка чыгуын күрде, дип яза [Фатих Карими, с. 320]. Бүгенге көндә татар хәбәрчеләренең Истанбулдагы эшчәнлеге темасына үзенең хезмәтләрендә Әлфинә Сибгатуллина кагылып үтә: «Фатих Кәрими кебекләр Төркия өчен «үз» кешеләр булып, шул ук вакытта аларның Госманлы империясендә барган вакыйгаларга, «читтән күзәтүче» сыйфатында, үзенчәлекле карашы барлыкка килә. Алар Төркияне эчтән яхшы беләләр, әмма шуның белән бергә, аңа чит күз белән карау сәләтенә ия булалар, ягъни сугышлар һәм халык күтәрелешләре чорында илнең халыкара

хәлен исәпкә алып, объектив һәм киңрәк караш ташлыйлар. Ф. Кәрими «хатлары»ның оригинальлеге шуның белән аңлатыла да» [Сибгатуллина, с. 146]. Балкан сугышлары вакытында татар журналистларының Төркиядәге эшчәнлеге темасы белән кызыксынучылар күп булса да, аларның Госманлы империясендәге эчке сәяси вазгыятьне яктырту һәм үзләренең дә сәяси көрәшкә тартылу мәсьәләләре тарихи әдәбиятта чагылыш тапмаган диярлек.

Бу мәкаләне язганда, 1912–1913 елларда Беренче Балкан сугышы фронтларындагы вазгыятьне яктырткан, шулай ук Госманлы дәүләте тормышындагы сәяси вакыйгаларга бәя биргән татар вакытлы матбугаты материалларына мөрәҗәгать иттек. Без «Йолдыз», «Вакыт» газеталарыннан, Ф. Кәриминең «Истанбул мәктүбләре» китабыннан файдаландык.

Шул рәвешле, Төркиягә килгән татар журналистлары сугыш хәрәкәтләрен тасвирлау белән генә чикләнмиләр. Алар Госманлы империясендә барган көчле эчке сәяси көрәшнең үзәгенә эләгәләр, дидек. 1912 елның ноябреннән 1913 елның мартына кадәр Ф. Кәрими «Вакыт» газетасының Истанбулдагы хәбәрчесе була һәм Оренбургка материаллар җибәреп тора. Балкан сугышлары чоры Госманлы империясендәге вазгыять аеруча тулы яктыртылган «Истанбул мәктүбләре» китабын Ф. Кәрими шул материалларга таянып язган. 1912 елның ноябреннән 1913 нең гыйнварына кадәр Истанбулда яшәгән Г. Камал Казанда чыккан «Йолдыз» газетасына җибәргән корреспонденцияләрендә Төркиядәге вакыйгаларга үз карашларыннан чыгып бәя бирә. Шул рәвешле Россиядәге төп мөселман газеталарының берсенең мөхәррире һәм татар драматургиясенә нигез салучы Госманлы империясе элитасы каршы торуының шаһитләре булалар.

1912 елның көзендә Төркия үз тарихында аеруча драматик эпизодларны кичерә. Балкан сугышының беренче көннәрендәге авыр җиңелүләргә илдәге киеренкелек тә өстәлә. Госманлы империясенең Италия белән сугышта җиңелүеннән файдаланып, яшь төрекләрнең сәяси дошманнары («Иттихад[1] вә тәрәккый[2]» фиркасе, яисә «иттихадчылар») 1912 елның июлендә илдә түнтәрелеш (переворот) ясыйлар. Аның башында 1911 ел башында оешкан «Хөррият вә иттиляф» фиркасе тора. Аңа күп кенә оппозицион фиркаләр һәм төркемнәр керә. Яңа фиркане күп кенә милли азчылык вәкилләре дә хуплый. Чөнки ул аларга, илнең сәяси бөтенлеген саклаган хәлдә, милли өлкәләр автономиясе принцибын тормышка ашырырга вәгъдә бирә. «Хөррият вә иттиляф[3]» шактый катлаулы күренеш булып, төрле сәяси карашлы кешеләрне – милләтчеләрне, либералларны, көнбатышчыларны, секулярлаштыручыларны һ. б. үз эченә ала. Моннан тыш аның составына, мөселман төрекләр белән беррәттән, Госманлы

[1] Иттихад – берләшү, бер фикердән эш итү.
[2] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[3] Иттиляф – килешү, уртак фикергә килү.

империясенең мөселман түгел халыклары вәкилләре дә керә [Genel Turk tarihi, s. 352].

1912 елның июлендә, иттиляфчылар тырышлыгы белән, иттихадчылар яклаган хөкүмәт отставкага китәргә мәҗбүр була. Яңа Министрлар кабинетына рәсми рәвештә партиясез, әмма тулаем алганда лояль иттиляфчы Әхмәд Мөхтәр-паша җитәкчелек итә. 1912 елның августында соңгылары иттихадчылар күпчелекне тәшкил иткән парламентны таркатуга ирешәләр. Аннан амнистия игълан ителә, ул тәхеттән бәреп төшерелгән солтан Габделхәмид II тарафдарларына да кагыла. Яшь төрекләр, җиңелүгә дучар булып, яңа шартларда көрәшкә әзерләнә башлыйлар. 1912 елның августында Истанбулда фирканең чираттагы корылтаен уздыралар, ә аннан соң Үзәк комитет Салоникига күченә. Октябрьдә Истанбулда тагын зур үзгәрешләр күзәтелә. Министрлар кабинеты отставкага китә. Ә яңа хөкүмәт белән иттиляфчылар куйган Кямил паша җитәкчелек итә. Хөкүмәт башлыгына, егерме елдан артык Бөекбритания белән тыгыз элемтәдә торуын сәбәп итеп, «инглиз» дигән кушамат тагыла [Финкель, с. 716].

Иттиляфчылар сугыш вазгыятен сәяси дошманнарын репрессияләү өчен файдаланалар. Иттихадчыларның күп кенә актив эшлекләре кулга алына [Петросян, с. 375]. Хөкүмәт башлыгы Кямил паша конституцион җыелыш чакырырга тәкъдим итә. Әмма кабинетның башка әгъзалары аның фикерен уртаклашмый. Яшь төрекләр әлеге бәхәскә катнашмыйлар [Feroz Ahmad, s. 148]. 1912 елның азагында Госманлы империясе башкаласында сәяси вазгыять әнә шулай катлаулы була.

Истанбулга килү белән язган беренче мәкаләләрендә («мәктүбләрендә») үк Ф. Кәрими укучыларның игътибарын яңа госманлы хакимиятенең яшь төрекләр өстенә репрессияләр белән ябырылуына юнәлтә. Ул эре дәүләт эшлеклеләренең – министрлар, министр ярдәмчеләре, депутатлар, партия функционерларының кулга алынуын хәбәр итә. Ил җитәкчелегенең кайбер вәкилләре чит илләргә китеп өлгерә. Журналистның яшь төрекләрнең гаебе нәрсәдә булуы турындагы соравына шул заманның рәсми фикерен тәңгәл җавап яңгырый: «Безнең шушы хәлгә төшүебезнең сәбәпчеләре – алар». Яңа хакимиятнең яшь төрекләргә шундый кырыс мөнәсәбәте сәбәбен эзләп, Ф. Кәрими, солых төзелгәннән соң, хөкүмәткә җиңелгән өчен дә, гаять зур территорияләрдән колак каккан өчен дә җавап бирергә туры киләчәген аңлый. Һәм ризасызлык дулкынында кабат яшь төрекләргә ихтыяҗ туачак, алар берсүзсез хакимиятне кире үзләренә кайтарырга теләячәк. Берничә ай үтүгә, нәкъ шулай була да.

Фиркаләр арасындагы каршылыкларның тулаем Төркия язмышына куркыныч тудыруын ассызыклап, Ф. Кәрими беренче хатязмаларында ук яшь төрекләрне яклап чыга. Төрекләрнең бөтен гаепне иттихадчыларга кайтарып калдырырга омтылуы, Ф. Кәрими фикеренчә, объектив информация булмаудан, шулай ук «тәмле телле» грек һәм әрмәннәрнең сүзенә ышанудан. «“Иттихад вә

тәрәккый”чылар Төркиядә төрек хакимияте (ягъни Европа державалары һәм алар белән бәйле башка милләт вәкилләрендән булган компрадор буржуазия даирәләренең түгел, барыннан элек, төрекләрнең үз мәнфәгатьләрен кайгырткан хакимият. – *К.Ә.)* ясау иҗтиһадында[1] иделәр, бәгъзы[2] бу хосусда артыграк ашыгычлык итүб эшне боздылар, ләкин максадлары тугры иде. Әмма иттиляфчыларның дусталары булган арнаудлар[3] вә греклар үзләренең һөнәрләрен күрсәтделәр: Яурупада госманлы хакимияте кимүгә яки бетүгә иң зур сәбәбчеләр шулар булды. Бичара, садәдил[4] төрекләр халән[5], арнаудларны мактыйлар вә «иттихад вә тәрәкъкый»чыларны яманлыйлар» [Кәрими, б. 33].

Ф. Кәрими Истанбулдан җибәргән хат-язмаларында яшь төрекләрне кулга алу темасына кабат-кабат әйләнеп кайта: «Ватан шул кадәр зур тәһлекәгә[6] төшкән бер заманда мәмләкәтнең иң мөнтәхәб[7], иң фәгъгал[8] вә иң хәмиятпәрвәр[9] кешеләрнең төрмәләргә тутырылулары яки, хәятләрен коткару өчен, чит мәмләкәтләргә качарга мәҗбүр булулары никадәр шаян[10] тәәссеф[11] бер эшдер. Мондый бер вакытда бөтен сәяси ихтиляфлар[12] бер якга ташланурга вә бөтүн ватан уллары бергә сарылуб ватанны мөдафәга[13] итергә тийүш иде. Монда исә балигъкәс[14]... [Кәрими, б. 38]. Үзенең мәкаләләрендә Ф. Кәрими иттихадчыларны Төркиянең чын патриотлары дип атый, шул ук вакытта аларның оппонентлары – иттиляфчыларга чит илләрдәге көчләрнең һәм ил эчендә төректән башка милләт кешеләреннән торган төркемнәрнең йогынтысы көчле дип саный.

Яңа Балкан сугышындагы уңышсызлыклар Кямил паша хөкүмәтенең абруен бик нык төшерә. Төркия өчен үтә нык файдасыз вакытлы солых төзелгәннән соң, вазгыять үзгәрә башлый. Ф. Кәрими дә үзенең хат-язмаларында шул турыда хәбәр итә. Ул шулай ук элек кулга алынган яшь төрекләрнең азат ителүләрен хәбәр итә [Кәрими, б. 92]. 1912 елның соңгы көннәрендә Истанбулда сәяси вазгыять бик нык кискенләшә, хөкүмәт болай да какшаган абруен тәмам югалта, ә яшь төрекләрнең йогынтысы киресенчә үсә. «Иттихад вә тәрәккый» фиркасе лидерларының берсе – Әнвәр бәкнең итальяннар кул

[1] Иҗтиһад – тырышу, тырышлык.
[2] Бәгъзы – кайбер, кайвакыт.
[3] Арнауд – албан.
[4] Садәдил – саф күңелле.
[5] Халән – хәзер.
[6] Тәһлекә – һәлакәт, куркыныч хәл.
[7] Мөнтәхәб – сайлап алынган.
[8] Фәгъгал – бик эшчән.
[9] Хәмият – башкаларның зарар китерүеннән саклау.
[10] Шаян – тиешле дәрәҗәдә.
[11] Тәәссеф – үкенү, ачыну.
[12] Ихтиляф – каршылык.
[13] Мөдафәгә – каршы торып сугышу.
[14] Балигъкәс – бөтенләй киресе.

астындагы Триполитаниядан[1] кайтуы җәмәгатьчелекнең һәм матбугатның игътибарын җәлеп иткән мөһим вакыйгага әйләнә. Ф. Кәрими һәм Г. Камал, аның белән очрашып, интервью алмакчы булалар. 1912 елның 14 декабрендә Ф. Кәрими Әнвәр бәк белән әңгәмә кора. Г. Камал үз теләгенә ирешә алмый, ул Әнвәр бәк үзе юк вакытта аның өендә була һәм бары әтисе белән генә очрашып сөйләшә. Әнвәр бәк квартирының җиһазланышын тасвирлаганда, Г. Камал анда Наполеон Бонапарт сурәтләренең артык күп булуына игътибар итә. Күрәсең, Әнвәр бәк, Г. Камал язганча, элеге шәхес алдында баш игән [«Йолдыз», 1912].

Ф. Кәрими үзенең хат-язмаларында Әнвәр бәк шәхесенә соклануын яшерми: «Төркия инкыйлабы вә Траблис сугышы вакытында зур каһарманлыклар күрсәткән Әнвәр бәк исеме ишетелгән вакытда бөтен төрекләрнең йөзендә шул нисбәтдә ифтихар вә мәгърурият галәмәтләре заһир була, һәркем аның исемен хөрмәт илә яд итә, һәркем аны күрәсе вә рәхмәт әйтәсе килә» [Кәрими, б. 143]. Очрашуга да ул «Төрек йорты» журналын чыгаручы Йосыф Акчура белән бергә бара. Очрашуның башында ук Әнвәр бәк татар журналистында яхшы тәэсир калдыра. Ф. Кәрими нигездә Италия белән сугыш вакытында Әнвәрнең Триполитаниядә булуын бәян итә. Әңгәмә вакытында бүлмәдә тагын ике офицер була. Моннан тыш, Ф. Кәрими аның янында утырганда, Әнвәр янына берничә кеше килә. Кем беләндер ул журналистлар алдында сөйләшә, кемнедер башка бүлмәгә алып чыга һәм көтеп торуын үтенә. Һәм, ниһаять, Ф. Кәриминең Әнвәр турындагы язмасының ахыры кызыклы: анда ул Әнвәр бәк кебек бөек һәм хөрмәтле шәхесне уңайсыз хәлгә куймас өчен, кайбер темаларга сорау бирүне мәгъкуль күрмәве турында әйтә. Күрәсең, бу очракта сәяси вазгыять һәм Әнвәрнең шул замандагы Төркия хакимнәренә мөнәсәбәте турында сүз бара.

Ф. Кәрим Әнвәр бәкнең планнары турында белгәнме? Бу сорауга анык җавап юк. Чөнки берничә атна узуга Әнвәр Төркиядәге заговор белән җитәкчелек итә. Нәтиҗәдә хөкүмәт бәреп төшерелә, яшь төрекләр хакимияткә килә һәм 1918 елга кадәр Госманлы империясенә җитәкчелек итә. Асылда Ф. Кәрими Әнвәр бәкнең йортына гына түгел, заговорчылар штабына килгән булып чыга. Ул үзенең язмаларында Әнвәр бәкнең түбәндәге сүзләрен китерә: «Яшәр өчүн бары үлемдән генә курыкмаска кирәк. Үлемдән курыкмаган кеше яки милләт озак һәм рәхәт яши ала» [Кәрими, б. 143]. Әнвәр бәк чыннан да үлемнән курыкмаган, кыска, әмма якты һәм тулы тормыш белән яшәгән. Ф. Кәрими белән очрашудан соң берничә атна үтүгә, Әнвәр бәк заговорчыларның әйдаманына әверелә һәм хөкүмәт бәреп төшерелә. Бераздан ул үзен хәрби министр итеп куйдырта. Һәм Госманлы империясенең факттагы өч хөкемдарының берсе – кодрәтле Әнвәр паша була. Төркия Беренче бөтендөнья сугышында җиңелүгә дучар

[1] Триполитания – хәзерге Ливия.

булгач, Германиягә китеп бара, аннан революцион Россиягә килеп эләгә, әмма большевиклардан гайрәте чигеп, Урта Азиядәге басмачылар хәрәкәтенә кушыла һәм чекистлар белән бәрелештә һәлак була.

Ф. Кәриминең яшь төрекләрнең тагын бер күренекле лидеры – принц Сәед Хәлим паша белән очрашуы шулай ук кызыклы һәм әһәмиятле. Хәлим паша – Мисыр хөкемдары Мөхәммәд Гали оныкларының берсе. Ф. Кәрими Хәлим паша турында «Мисыр принцы» буларак язса да, Мөхәммәд Галинең чыгышы белән европалы албан булуын әйтеп үтәргә кирәк. Хәлим паша бик хәлле кеше була. Байлыгы миллионнар белән исәпләнеп, Босфордагы күп кенә сарайлар һәм биналар да аның милке санала. Еникёй дигән җирдә урнашкан шундый сарайларның берсенә Ф. Кәрими күренекле татар җәмәгать һәм дин эшлеклесе Габдррәшид Ибраһимов белән бергә килә. Рәшид казый Хәлим пашаны яхшы белеп, татар журналисты белән төрек сәясәтчесе арасында арадашчы ролен үти. «Мисыр принцы» кунакларны гаҗәеп зиннәтле йортында кабул итә, хуҗа кешенең тәрәзәләре туп-туры Босфор суларына чыга. Ф. Кәрими белән танышканнан соң, Хәлим паша кунагына Россия мөселманнары тормышының төрле өлкәләренә караган сораулар бирә: мәгариф (мәктәп һәм мәдрәсәләр), һөнәрләр һәм сәнәгать, муллаларның укымышлылыгы, мөселманнарның һәм рус халкының үзара мөнәсәбәте турында.

Сәед Хәлим паша Ф. Кәримигә җавапларында Балкан сугышында җиңелүдән соң Төркиянең киләчәген яшь төрекләр хакимиятен яңадан торгызуда гына күрүен әйтә: «Әгәр тиздән «Иттихад вә тәрәккый» җәмгыяте эш башына менүб, бетүн куввәтне үз кулына алса вә үткәндә ясаган бәгъзе хаталарын бетерүб, үзенең пруграмын гамәлгә кую хакында һичнәрсәгә карамый, хәтта лязем[1] булса диктатуралык итүдән дә курыкмый эшкә керешсә, Төркиянең мөстәкыйль бер хөкүмәт хәлендә яшәве мөмкин, юкса Рум илендәге[2] вакыйгалар гыйнилә Анатулидәдә[3] дәвам итәчәк вә ниһаять Төркиянең истикъляленә[4] хатимә[5] биреләчәкдер» [Кәрими, б. 207].

Ф. Кәрими үзе Сәед Хәлим паша турында бары мактап кына сөйли, аны үз иленең патриоты һәм «Иттихад вә тәрәккый»ның тугрылыклы тарафдары дип атый. Сәед паша кашеләренең атнасына ике-өч мәртәбә Истанбул мәчетләрендә һәм шәһәрдән читтә яшәүче качак мөселманнарга хәер-садака өләшүләрен билгеләп үтә. Ф. Кәрими һәм Сәед Хәлим паша әңгәмә корганда булган бер кызыклы фактны билгеләп үтәргә кирәк: татар журналисты белән сөйләшеп утырганда, хезмәтче кереп, полковник Зәки бәкнең килүен һәм пашаны күрергә теләвен хәбәр итә. Яшь төрекләр тарафыннан оештырылган дәүләт переворотына санаулы көннәр генә калганда, хезмәттәге хәрби

[1] Лязем – кирәк.
[2] Рум иле – Төркиянең Европа өлеше.
[3] Анатули – Төркиянең Азия өлеше.
[4] Истикъляль – бәйсезлек.
[5] Хатимә – ахыр.

кешенең оппозизиядәге, һәм хәтта каһәрләнгән сәясәтче янына килүе бик тә сәер тоела. Сәед Хәлим пашаның язмышы да көрәштәше Әнвәр пашаныкы кебек якты һәм фаҗигале: яшь төрекләр хакимияткә кайткач, ул хәтта күпмедер вакыт садразам – хөкүмәт башлыгы булып тора. 1921 елда Римда әрмән террорчысы тарафыннан үтерелә [Feroz Ahmad, s. 209].

Шулай итеп, яшь төрекләр һәм хөкүмәт тарафдарлары каршы торышының иң югары ноктасы 1913 елның 23 (10) гыйнварындагы түнтәрелеш була. Яшь төрекләрнең хакимияткә кайтуына багышланган хат-язмасының башында Ф. Кәрими 10-нчы гыйнвар вакыйгаларына кыскача йомгак ясый. Ул Истанбулда ике сәгать эчендә акылга сыймаслык инкыйлаб булды, дип хәбәр итә. Кямил паша хөкүмәте бәреп төшерелә, ә аның урынына Мәхмүд Шәүкәт паша җитәкчелегендәге кабинет килә, шул рәвешле ил белән «Иттихад вә тәрәккый» фиркасе тарафдарлары, ягъни яшь төрекләр идарә итә башлый. Шул ук вакытта Ф Кәрими, яшь төрекләргә симпатиясе булса да, бәреп төшерелгән хөкүмәтнең хәрби министры, дәүләт түнтәрелеше барышында һәлак булган Назыйм пашаны зур ихтирам белән искә ала, аны сәләтле һәм намуслы дәүләт ире дип атый. Ф. Кәрими яшь төрекләрнең хакимиятне шулкадәр тиз арада яулап алуларына бөтен халыкның гаҗәпләнүен ассызыклый, әйтерсең, аларга ниндидер тылсым көче ярдәм иткән [Кәрими, б. 229]. Аннан соң Ф. Кәрими Истанбулдагы вакыйгаларны һәм үзенең тәэсирләрен тәфсилләп сөйләүгә күчә. 10 гыйнвар көнне иртән Европа державалары ультиматумын кабул итүе – ягъни Госманлы Төркиянең Балкандагы союздашлар белән үтә нык файдасыз, хурлыклы шартларда солых төзергә ризалык бирүе турында хөкүмәт карары басылып чыга. Ф. Кәрими фикеренчә, бу – җәмгыятьтә чуалышлар китереп чыгарырга тиеш була. Көннең беренче яртысында Истанбулда тынлык хөкем сөрә. Сәгать икеләрдән соң, хөкүмәт резиденциясе (Югары Порта) каршындагы кунакханәдә яшәгән Ф. Кәрими Бәйоглы тарафына, Алтын Мөгез култыгының икенче ярына юнәлә. Хөкүмәтнең бәреп төшерелүе турында ул шунда ишетә. Ф. Кәрими кире кунакханәгә кайта, хөкүмәт йорты янында шаккатырлык бер нәрсә дә күрми. Шуннан соң ул Истанбулда чыга торган бер газета редакциясенә кагылып чыкмакчы була, әмма полиция аны бинага үткәрми. Ф. Кәрими кабат хөкүмәт йорты янына килә һәм анда халык төркеме җыелуын, митинг баруын күрә.

«Йолдыз» газетасына язган хәбәрендә Г. Камал да 23 (10) гыйнвар вакыйгаларын тасвирлый. Түнтәрелешкә берничә көн кала Г. Камал яшь төрекләр һәм хөкүмәт арасында каршы торыш тәгаенләнүен яза. Күрәсең, Г. Камал Ф. Кәрими белән бер үк кунакханәдә яшәгән: тәрәзәдән шау-шу ишетеп, ул урамга чыккан һәм хөкүмәт резиденциясе янына җыелган халык төркеменең «Яшәсен Әнвәр бәй!» дип өзеп-өзеп кычкыруын күргән. Әйтергә кирәк, Г. Камал, яшь төрекләр хакимиятне яулап алганда турыдан-туры катнашкан кешеләрнең сүзләренә дә таянып, вакыйгаларны тәфсилләбрәк тасвирлый. Г. Ка-

мал мәкаләсендә яшь төрекләрнең Югары Порта бинасын алуы һәм аларга каршылык күрсәтергә маташкан хәрби министр Назыйм пашаның һәлак булуы детальләп сурәтләнә [«Йолдыз», 1913].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: 1912 елның көзендә Госманлы империясе үз тарихында аеруча драматик чорларның берсен кичерә. Балкан сугышы барышында ул Европадагы барлык биләмәләрен диярлек югалта һәм Истанбулга болгар гаскәрләре тарафыннан яулап алыну куркынычы яный. Сугышта җиңелүнең аяныч нәтиҗәләренә Төркиянең идарә итүче элитасы фиркаләре һәм төркемнәре арасындагы эчке каршылыклар да өстәлә. Госманлы гаскәрләренең җиңелүе һәм империянең җимерелү куркынычы туу Россия мөселманнарын (Идел-Урал татарларын) бик нык борчуга сала. Татар газета һәм журналлары Төркиядәге вакыйгаларны даими яктыртып баралар. Шушындый катлаулы заманда берничә татар журналисты Истанбулга килә. Алар хәрби хәрәкәтләрне яктыртырга тиеш булалар, әмма Төркия башкаласында эчке сәяси көрәшнең нәкъ үзәгенә килеп эләгәләр. Татар репортерлары хәрби хәрәкәтләр барышын бәян итүдән бигрәк, Госманлы империясенең иҗтимагый һәм сәяси тормышына күбрәк игътибар бирәләр, кайберләре, күрәсең, элеге вакыйгаларда үзләре дә турыдан-туры катнаша**.**

**Әдәбият**

«Йолдыз», 1912.

«Йолдыз», 1913.

*Кәрими Ф.* Истанбул мәктүбләре. Оренбург, 1913. 454 б.

*Петросян Ю. А.* Османская империя: могущество и гибель. Исторические очерки. М: Изд-во Эксмо, 2003. 416 с.

*Сибгатуллина А.Т.* Контакты тюрок-мусульман Российской и Османской империй на рубеже XIX – XX вв. М., 2010.

Фатих Карими: научно-биографический сборник. Казань 2000. 320 с.

*Финкель К.* История Османской империи: видение Османа. М.: АСТ, 2010 С. 730.

Genel Türk tarihi. Cilt 7. Osmanlı. 2002. Ankara, pp: 714 s.

*Feroz Ahmad*. İttihad ve terraki. İstanbul, 2010. 256 s.

***Әхсәнов Камил Госман улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94

***Н.М. Мифтахетдинова***

# ТАТАРЧА ЯЗУ МАШИНАЛАРЫ ТАРИХЫ

В данной статье рассматривается история появления и функционирования пишущих машин на татарском языке; разъясняется суть научных подходов к данной теме у ряда татарских ученых-изобретателей, в частности, у Шейх Али и М. Идрисова. Автором исследуются и технические аспекты проблемы, среди них – возможность модификации иностранных пишущих машин применительно к татарскому письму: с изменениями в механизме для приспособления шрифтов (Шейх Али) и без них (М. Идрисов).

**Ключевые слова**: Шейх Али, М. Идрисов, Г. Мадъяров, пишущая машинка «Яналиф».

This article discusses the history of the appearance and functioning of typewriters in the Tatar language; explains the essence of scientific approaches to this topic among a number of Tatar scientists and inventors, in particular, Sheikh Ali and M. Idrisov. The author also studies the technical aspects of the problem, among them the possibility of modifying foreign typewriters with reference to Tatar writing: with changes in the mechanism for adapting fonts (Sheikh Ali) and without them (M. Idrisov).

**Keywords:** Sheikh Ali, M. Idrisov, G. Madjarov, «Yanalif» typewriter.

Язу машиналары – җәмгыять үсешенең бер этабы. Төрле гасырларда бер-берсеннән бәйсез рәвештә язу җайланмалары булдыру очраклары билгеле. Әмма язу машиналарын XIX гасырның икенче яртысыннан гына серияләп эшләп чыгара башлыйлар. Шул вакытларда Германиядә, Америка Кушма Штатларында «Империал», «Мерседес», «Ундервуд», «Континенталь», «Ремингтон» кебек данлыклы язу машиналары җитештерелә.

Россия империясендә язу машиналары җитештерелмәү сәбәпле, чит илләрдән сатып алынган машиналар кулланыла. Әлеге машиналарның үрнәкләре Татарстан Республикасы Милли музеенда да саклана һәм аларны музейның төрле экспозиция мәйданчыкларында күрергә мөмкин.

XX гасыр башында татар җәмгыяте җитди үзгәрешләр кичерә. Бу бигрәк тә техник яктан алга киткән илләргә тартылуда чагыла: Европача киенү, татар мәдәниятенә сәнгатьнең яңа төрләрен кертү, фән-техника казанышлары белән уртаклашу. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында күп кенә татар зыялылары, эшмәкәрләр, галимнәр, язучылар Европага сәяхәт итә, тәҗрибә уртаклаша, җитештерүнең яңа алымнарын үзләштерә. Әлеге тенденция китап басу эшчәнлегендә дә чагылыш таба. И. Харитонов, М. Идриси, Ф. Кәрими, Ә. Хәсәни һ. б. басмаханәләр эшчәнлегендәге яңа алымнарны Германия предприятияләрендә өйрәнәләр.

Татар җәмгыятенең алга үсешен тәэмин итү өчен, язу машиналарын «татарча» яздыру ихтыяҗы туа. Бу эшчәнлек өч яссылыкта бара: беренчесе – татар теленең орфографиясен камилләштерү, икенчесе – язу машиналарын татар язуына хас булган калыпларга җайлаштыру һәм өченчесе – шрифтларны клавиатурага яраклаштыру.

Әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәсе – 1929 елдан Советлар Союзында беренче язу машинасын – «Яңалиф»не серияле җитештерә башлау. «Яңалиф» маркалы Казанда җитештерелгән язу машиналары Милли музейда да саклана. Алар икәү: берсе – латин графикасында, икенчесе – кириллицада. «Яңалиф»нең татарча кириллицада булуы, әлеге маркалы язу машинасының XX йөзнең 40 нчы елларында да җитештерелүе турында сөйли.

Союз күләмендә беренче язу машинасын уйлап табуда Г. Алпаров, Г. Мадьяров, Ә. Шәйхгали, М. Идрисов кебек татар галимнәренең, һәвәскәрләрнең эшчәнлеге ята.

«Жизнь национальностей» газетасы 1922 елның 26 апрель санында редакциядән яңалыклар рубрикасында татарча язу машинасы уйлап табылу һәм аның авторлары турында мәкалә бастыра. Анда түбәндәге юллар бар:

«Башкорт кызыл армия солдатлары Т.М. Туганов һәм командир Г.Г. Мадьяров гарәп шрифтында язу машинасы уйлап таптылар. Башкорт Үзәк Башкарма комитеты язу машинасын «Башкурдистан» (Башкирия) дип атарга һәм шул исем астында патент алырга тәкъдим итте.

Билгеле булганча, якынча 150 знаклы гарәп шрифтын язу машиналарында куллану мөмкин түгел диярлек. Европа фирмаларының язу машиналарына гарәп шрифтын көйләү уңышлы булмый: алар зур, авыр һәм бик акрын баса, шунлыктан Шәрыкта кулланылыш тапмый.

Т. Туганов белән Г. Мадьяров клавиатураның үлчәмнәрен үзгәрешсез калдырып, билгеләрне алтмышка кадәр кыскартуга ирешәләр. Әлеге язу машинасында гарәп язуы үз рәвешендә сакланып кала.

Язу машинасы Мәскәүгә китерелә һәм рәсми рәвештә экспертлар, мөселман язуы белгечләренең уңай бәяләмәләрен ала. Язу машинасында башкорт, кыргыз, үзбәк, татар һәм төрек, гарәп, фарсы, азәрбайҗан һәм хәзерге һинд телендә язарга мөмкин.

Язу машинасының эшләнелеш теориясен командир Г. Мадьяров, ә гамәли-техникасын кызылармеец Т. Туганов башкара» [Печатная машинка... № 8].

Патентка гариза 1922 елның 9 сентябрендә бирелә (Таныклык №75838) һәм 1924 елның 20 ноябрендә унбиш елга исәпләнгән патент алына.

Бу елларда Казанда да язу машиналарын татар алфавитына яраклаштыру һәм аларны үзебездә җитештерә башлауга әзерлек эшләре бара. Бу өлкәдә Әскәр Шәйхгали эшчәнлеге игътибарга лаек. Ул 1924 елның октябрендә язу машиналары остаханәсе мөдире итеп билгеләнә. Ә. Шәйхгали эшләгән язу машинасы, читтән кертелгән

машина конструкциясен сүтеп, яңадан татар шрифты, татар язуы үзенчәлекләре белән тулыландырылып җыела.

1928 елда чит ил язу машиналарының төрле механизмнарын татар язуына яраклаштыруга, Казанда эшләнгән язу машинасы «Яңалиф»нең үрнәк экземпляры Мәскәүгә җибәрелә һәм хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнә. Шуннан соң Союз күләмендә производство масштабларында җитештерелә башлый. Бу – илебездә ясалган беренче язу машинасы. Ә. Шәйхгали турында, Казанда язу машиналары җитештерүче завод тарихы, аның казанышлары хакында Казан исәп-хисап техникасы тарихы музее директоры М. Бәдретдинова һәм Г. Галимуллина хезмәтендә язылган [Бадрутдинова, Галимуллина, с. 92–106].

Әмма машиналарны «җимерү», беренчедән, аларның сыйфатына зыян китерә, икенчедән, бәяләрен арттыра. Ә бу исә тормыш шартлары авыр булган халык, дәүләт өчен хәлиткеч роль уйный.

Гомерен полиграфия сәнәгатен фәнни, техник, сәнгати яктан үстерүгә багышлаган талантлы шәхес Мөхәммәд Идрисов әлеге өлкәдә туган мәсьәләләрне чишүне үз өстенә ала.

М. Идрисов глобус, географик атамалар татарча бирелгән дөнья картасы эшли. Ул – хәрефләрне сулдан уңга җыюга көйләнгән язу машинасын һәм полиграфия сәнәгатендә яңа алымнарны кулланылышка кертүче киңкырлы галим-практик. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан гади, матур һәм уку өчен уңайлы хәреф булдыру проблемасы белән шөгыльләнә. Бу турыда үзенең автобиографиясендә дә яза: «В 1914–1915 годах занимался гравировкой новых татарских шрифтов по своему проекту и применением татарского алфавита к пишущей машине «Гаммонд»» [Автобиография М. Идриси]. Әмма сугыш бу эшне читкә куеп торырга мәҗбүр итә.

1917 елда М. Идрисов Казанда хәреф кою эшен оештыра: Көнчыгыш халыклары бик озак көткән гадиләштерелгән конфигурацияле гарәп хәрефләре коела. М. Идрисов хәрефләренең яңа гарнитурасын алу өчен, хәтта Урта Азия һәм Казакъстаннан да киләләр.

Истәлекләрдән күренгәнчә, 1926 елның февралендә М. Идрисов Америкада эшләнгән язу машинасы сатып ала һәм шунда ук, татар шрифтларын клавиатурага яраклаштырып, яңа принципка нигезләнгән язу машинасы эшли. М. Идрисовның яңалыгы шунда: ул чит илдән килгән машинаны «җимерми» генә, аның клавиатурасына татар шрифтларын урнаштыра. Машинаның эшләү механизмы үзгәртелмәү аркасында, читтән кайтарылган машина ике көндә «татарча» яза башлый. Шунысы да әһәмиятле: М. Идрисовнең машиналарын башка төрки халыклар да, гарәпләр дә куллана ала.

Татар алфавиты реформасы буенча киңәшмәдә М. Идрисовның 37 билгеле шрифт проекты югары бәяләнә. Ул эшләгән хәрефләр Мәскәүдә Үзәк китап фабрикасы нәшриятында кулланылышта йөри, башка илләргә дә җибәрелә.

Соңрак М. Идрисов үзенең эшчәнлеген Мәскәүдә дәвам итә. Ул гарәп хәрефе белән файдаланучы төрле милләтләр әдәбиятында

бер төрле хәрефләрнең кабатлану ешлыгын билгели. Шуннан чыгып, яңа набор кассаларының, язу һәм хәреф җыю машиналарының клавиатуралары проектын эшли. Бу турыда М. Идрисовның Мәскәүдә Бөтенсоюз Үзәк Комитеты тәкъдиме белән эшләгән буклетлары аша танышырга мөмкин [Идрисов, 12439-56 М., 12439-54 М.].

М. Идрисов эшләгән язу машинасының клавиатурасы ун бармак белән тоемлап текст җыюга корылган, ягъни дөньякүләм стандартлар таләпләренә туры килә. Ул уку йортларында гамәли сынау үтә һәм уңай яктан бәяләнә. М. Идрисов стенография курсларында дәресләрне үзе дә алып бара.

Әлеге материаллар киңкырлы талант иясе М. Идрисов эшчәнлегенең бер өлешен генә чагылдыра. Галимнең полиграфия өлкәсендәге фәнни-гамәли эшләнмәләре төрки халыкларның телен, мәдәниятен, үстерергә ярдәм итә.

Татарстан Республикасы Милли музеенда сакланган документлар, кулъязмалар, фоторәсемнәр исә аның эшчәнлеген тагын да тирәнтенрәк өйрәнергә мөмкинлек тудыра.

Татар телендә басучы язу машинасы җитештерү – күп елларга сузылган эш нәтиҗәсе. Алфавитлар алышу белән, язу машиналары да үзгәртелә. Бу өлкәдә Г. Мадьяров, Ә. Шәйхгали, М. Идриси кебек милләтәшләребезнең эшчәнлеге зур игътибарга лаек. Әйе, язу машиналарының «вакыты узды», әмма алар үз заманында җәмгыятьне алга җибәрүче бер корал булды.

**Әдәбият**

Автобиография М. Идриси. НМ РТ КП 124639-23.

*Бадрутдинова М.Ш., Галимуллина Г.Х.* Изобретатель А.А. Шейх-Али – основатель Казанского завода пишущих машин // История России и Татарстан проблемы энциклопедических и науковедческих исследований. Сборник статей. Казань, 2013. Вып. 5. С. 102–111.

Пишущая машинка с арабским шрифтом // Жизнь национальностей. № 8. 26 апреля, 1922.

*Идрисов М.* Схема унифицированной клавиатуры наборной машины «Линотип» на Ново-Тюркском алфавите. М., 1929. (НМРТ КППи-12439-56 М.)

*Идрисов М.* Схемы унифицированной клавиатуры пишущей машины «Ундервуд» на Ново-тюркском наречия. М., 1929. (НМРТ КППи 12439-54).

***Мифтахетдинова Нурия Мидхәт кызы,***
*ТР Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.Х. Дәүләтшина*

# БАЛА ТУУ ЙОЛАСЫ: ТРАДИЦИЯ ҺӘМ БҮГЕНГЕ ХАЛӘТЕ (Норлат һәм Чистай районы татарлары мисалында)

В статье рассматривается современное состояние обрядов послеродового этапа в структуре семейно-бытовой обрядности татар на примере Нурлатского и Чистопольского районов Республики Татарстан. В основу исследования легли материалы, записанные автором в ходе фольклорно-этнографической экспедиции 2018 года. Автор приходит к выводу, что в своей основе обряды, связанные с социализацией ребенка, сохраняют структуру и особенности, характерные для комплекса семейно-бытовой обрядности татар, но в то же время претерпевают неизбежные изменения по истечении времени и теряют магическую основу.

**Ключевые слова:** традиция, обряд, фольклор, родильный обряд, имянаречение.

The article discusses the current state of the rituals of the postpartum stage in the structure of the family and everyday rituals of the Tatars on the example of the Nurlatsky and Chistopolsky districts of the Republic of Tatarstan. The study was based on the materials recorded by the author during the folklore-ethnographic expedition of 2018. The author comes to the conclusion that, basically, the ceremonies associated with the socialization of the child retain the structure and characteristics usual for household ritual complex of the Tatar family, but at the same time undergo inevitable changes after time and lose their magical basis.

**Keywords:** tradition, rite, folklore, maternity rite, naming.

Яшәү дәверендә елның һәр мизгеле, көне, ае һәркемнән билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлүен таләп итә. Адәм баласының һәр адымы, хәтта ният-максатлары әүвәл-әүвәлдән кануннарга яраклаштырылган, алар бөтен кешегә дә фарыз исәпләнгән. Фәндә «берәр коллективның (гаилә, ыру, кабилә, кабиләләр берлеге) яисә аерым кешенең иҗтимагый-хуҗалык һәм гаилә тормышының иң җитди мизгелләрендә башкарыла торган, борынгыдан килгән һәм төрле магик сүз, сүз тезмәләре, җыр-такмак-такмаза, музыка һәм бию белән барган традицион хәрәкәт-гамәлләрне йола дип атыйлар» [Урманче, с. 22]. Һәркем тарафыннан үтәлергә тиешле әлеге кануннар кешенең борын-борыннан табигать күренешләренә, физик һәм физиологик үзгәрешләргә, гаиләдә, җәмгыятьтә булган хәлләргә үзе теләгәнчә йогынты ясарга, аларга яраклашырга тырышуыннан бар булган.

Фольклористика һәм этнография фәннәрендә кабул ителгән гомуми классификация нигезендә халыкның йола мәдәниятен ике төргә бүлеп йөртәләр: 1) ел фасыллары белән бәйләнгән календарь йолаларга, 2) гаилә-көнкүреш йолаларына. Татарларның традицион мәдәниятендә таралыш тапкан гаилә-көнкүреш йолалары арасында бала

туугa бәйле йола һәм гадәтләр байтак. Гомумән, баланың дөньяга яралуы элек-электән зур бер сер буларак күзаллана. Кешелекнең бик борынгы заманнарында, бу сергә әле аңлатма табылмаганда, шуңа бәйләп бик күп ырымнар, йола-гадәтләр барлыкка килгән, һәм аларның шактые гаилә көнкүрешендә бүгенгәчә сакланып калган. Татарстан Республикасының Норлат һәм Чистай районнарында гомер итүче татарлар да бала туугa бәйле йола-гадәтләрне түкми-чәчми саклап килә. Әлеге йолаларның нигезендә ана һәм баланың саулыгына, баланың киләчәк тормышына, аның уңышларына, гаилә коруына тәэсир итә дип саналган күзаллаулар ята.

Бала туганнан соң аның тормышына бәйле йола-гадәтләр бик күп. Дөньяга килүнең беренче кырык көнен, беренче атнасын барлык халыклар да үзенчә бер гадәт белән билгеләп үтә. Чөнки әлеге аралык бәбинең үзе өчен дә, аның әнкәсе өчен дә аеруча әһәмиятле чор санала. Нәкъ шушы көннәрдә баланы карау мәшәкатьле дә, мавыктыргыч та бер төс ала, аны яман күзләрдән-көчләрдән саклау өчен бөтен йолалар да җиренә җиткереп башкарыла.

Татарлар да баланың беренче кырык көненә аерым бер әһәмият бирәләр. Кырык көн тулу – җанның кешегә иңүе һәм кешедән китүе белән тәңгәлләштерелә. Кешенең вафатыннан соң да кырык көн үтүне билгеләп үтү гадәткә кергән. Баланың тууына кырык көн булгач, сәдака бирү тиешле санала. Бала хөрмәтенә дип, гадәттә, өлкән хатын-кызларга, әбиләргә сәдака бирелә. Себер татарлары телендә «*арыслан сәтәкәсе*» дип аталган бу гадәтнең асылында балага саулык, бәхетле киләчәк юрау ята. Мондый балага арыслан да, кеше дә зарар китерә алмас, аңа хәтта пычак та кадала алмас дип ышана халык. *«Умбиш тин көмөшне арыслан сәтәқәсе тип, башыннан әйләндереп бер әбигә бирә. Шул умбиш тин көмеш бирелсә, арыслан да һөҗүм қыла алмыйты, кеше тә тийә алмыйты. Үтерәм тип килгән пыцак, та төшеп китәр ти»* [Баязитова, с. 22].

Кырык көн дәвамында бала тапкан хатынның үзен дә, аның сабыен да һәрдаим кайгыртып, алар өчен борчылып торалар. Чөнки нәкъ менә шушы вакыт эчендә күз тиюләр дә, һәртөрле авырулар да якында гына йөри; бала тапкан хатын да, йөкле чагындагы кебек, әлегәчә «теге» һәм «бу» дөнья аралыгында яши дип санала. *«Бала ана карынына кырык бер тамыр белән ялганыр ди, бала туган вакытта шул кырык бер тамырның кырыгы өзелеп, берсе генә калыр ди. Кырык көн буена гүр авызы ачык торыр ди, бәбиләгән хатынга: алам, алам, алам! – дип торыр ди»* [Брусько, Завгарова, с. 45].

Норлат һәм Чистай районнарында яшәүче татарлар баланы яман көчләрдән саклар өчен, аны бала тудыру йортыннан алып кайтканчы ук, кечкенә мендәр ясап куялар. Матурлап чигеп ясалган бу мендәр белән баланы имлиләр, күз тигән дип уйласалар, һәр почмагын сабыйның эченә серле сүзләр белән тидереп-тидереп алалар. *«Минем үземнең кайнәм әни бик гыйлем иде. Шул менә кечкенә мендәр ясаган иде. Кечкенә мендәр ясап куй, бала елый торган була ди. Балага күз*

*тисә, еласа, Аятел көрси укып, мендәрнең дүрт почмагын да баланың корсагына тидереп, «Каян килдең, шунда кит, кемнең күзе тигән, шунда кит» дип әйтәсең. Изрәп йоклый иде бала шуннан соң. Мендәр ясаганда, кечкенә мендәр ясыйсың инде. Каз мамыгыннан. Бала үскәч, зур мендәргә өстисең аны»* (Миңнегулова Люция Харис кызы, 1953, Каргалы авылы).

Күз тия дип борчылганга, баланы кырыгына кадәр чит кеше күзенә күрсәтү тыела. Яшь әнинең хәлен белергә килгән кеше, бәби яткан бүлемгә, бик теләсә дә, үрелеп карый алмый: *«Кырыгына кадәр баланы чит кешегә күрсәтергә ярамый. Кырыгына хәтле тигән күз бетми диләр»*. Шуңа күрә ана белән баланы кырык көн үткәнче мөмкин кадәр чит-ятлар белән аралаштырмаска тырышалар, алар өчен аерым бүлмә дә әзерлиләр. Алда әйтеп үткәнчә, ул бүлмәне явыз көчләрдән саклау өчен, саклау магиясенең төрле формалары кулланыла.

Теге яки бу гаиләдә бәби туса, яшь ананың хәлен белергә, аны котларга килү, саулыгын кайгырту якын кешеләре өчен язылмаган бер бурыч булып тора. Хәл белергә берәү дә буш кул белән килми, сый-нигъмәт белән килә. Чистай районында әлеге йола *«бәбәй туе»*, Норлат районында *«бәбәй ашы»* дип атала һәм бүгенге яшәештә дә зур урын алып тора. *«Бәбәй туе үткәрәбез диләр инде. Якын туганнары, туганнарның балалары киләләр. Менә шунда бәбәй бәлеше алып киләләр атап»* (Миңнегулова Люция Харис кызы, 1953, Каргалы авылы). *«Исем кушканнан соң, әбиләрне чакырып, Ясин укытканнар. Әбиләр киленнәр белән торган бит инде. Шул киленнәре атна саен җомга көнне бәби бәлеше пешереп килә торган булганнар. Җома көнне генә. Чиратка сала торган булганнар. Алып килгән кеше белән чәй эчә торган булганнар. Карабодай ярмасын бүрттереп, киптереп, тарткычтан тарттырып, шуннан пешерә торган булганнар. Ит булса, ит тә куша торган булганнар»* (Сабирова Гөлмиҗиһан Мирсәет кызы, 1930, Хисамова Алия Насыйх кызы, 1975, Кычыткан-лы авылы). Бүген, әлбәттә, күчтәнәчкә карабодай бәлеше килми, әмма камыр ашы әзерләү традициясе саклана. Бәби тапкан яшь әни күчтәнәчкә килгән бу ризыкларның һәммәсен дә авыз итеп карарга тиеш. Йоланың төп максаты – ыру-кардәшләр тарафыннан баланың кабул ителүе, үз кеше булып китүе.

Бәби туганнан соңгы йолалар арасында *«исем кушу»* аерым бер игътибарга лаек. Исем үзе дә сакраль мәгънәгә ия. Бала үлгән очракта, аны хәтта исемсез җирләргә дә ярамый, чөнки исем кушкан очракта гына аның җаны тынычлык табачак һәм оҗмах кошына әвереләчәк, дип ышана халык. Шуңа күрә татарларда яңа туган баланы озаклап исемсез тоту куркыныч санала, балага беренче көннәрдә үк, һәрхәлдә, кырыгы тулганчы, ничек тә исем кушарга омтылалар. Исеме булмагач, бала яклаучысыз, саклаучысыз калгандай кабул ителә, кеше күзе тию ихтималыннан да, явыз көчләрнең тәэсиреннән дә ныграк сакларга тырышалар. Бары тик колагына азан әйтеп исем кушкач

кына Аллаһы Тәгалә аны саклый, яклый дигән ышану яшәп килә. *«Җиде көнгә хәтле исем кушарга кирәк. Исемсез торырга ярамый. Кем табын төзи. Якыннарын чакыра. Дүрт бала таптым. Дүрт балага да өйдә куштырдым исем. Мулла килеп исем куша. Исем кушу мәҗлесе дип атала инде. Туганнарың килә мәҗлескә. Бүләкләр алып килә. Бәбәй бүләге дип, гаиләдә кемнәр бар барысына да бүләк алып килә. Кызның әнисе тәмле иттереп бәбәй бәлеше пешереп алып килә иде. Йөзем салып, дөге, кабак белән бәбәй бәлеше. Иң беренче бәбәй тапкан әни кабырга тиеш. Бәбәйгә каптыралар, авызына тидерәләр. «Баллы булсын, татлы булсын, тәмле телле булсын» дип»* (Миңнегулова Люция Харис кызы, 1953, Каргалы авылы). *«Өч көннән ары тормасын диләр иде. Кайткач ук кычкырта идек. Минә күршенең каенатасы бар иде. Шуңа кычкырта идек. Аннан мәҗлес җыясың инде. Бәби бүләге, сәдака алып киләләр иде. Бәлеш тә пешереп кертәйем»* (Халиуллина Нурҗиһан Шәймордан кызы, 1926, Бикүле авылы).

Бүген татарларда исем кушу йоласы ислам динен тотучы башка төрки халыклардагы шикелле үк, бер үк канунга нигезләнеп башкарыла. Мендәрдә яткан сабыйны, башын кыйблага каратып, өстәл өстенә куялар. Мулла, «Аллаһу әкбәр!» дип өч тапкыр азан әйтә, аннан, баланың башта уң, аннан сул колагына иелеп, әкрен генә аның исемен кабатлый. Бүгенге көндә Чистай районының кайбер авылларында исем кушу мәҗлесен мәчеттә үткәрә башлаганнар. Традициядән читкә тайпылу, гомумән исем кушу йоласының сакраль мәгънәсе югалудан килә булса кирәк.

Татарларда ир баланы сабый чакта ук *сөннәткә утырту* йоласы бар. *Сөннәт* – гарәп теленнән кергән сүз, традиция, гадәт дигәнне аңлата. Ә менә баланы *сөннәтләү*, *сөннәткә утырту* беркадәр таррак мәгънәгә ия, ул малайларны мөселман гадәте буенча физик пакьләндерү.

*Сөннәтләү* – һәр ир баланың тормышында шактый зур урын алып торган, аны шартлы рәвештә булса да чын ир-егет исемлегенә керткән мөһим бер вакыйга ул. Элек-электән авылда халык арасында даны чыккан Сөннәтче бабай булган. Кендек әби шикелле үк, ул да хөрмәткә һәм ихтирамга лаек заттан саналган, аңа бүләк-күчтәнәчләр китергәннәр, илтифат күрсәткәннәр. Чөнки аның бик җаваплы һәм саваплы, шул ук вакытта бик катлаулы эш башкарганын яхшы аңлаганнар. Сөннәтче бабай кулында – баланың сәламәтлеге, киләчәктә нәселне дәвам итүе. Бу вакыйгага һич кенә дә бармак аша карамаганнар, зур игътибар биргәннәр. Сөннәтче бабайга 99 баладан артык сөннәтләргә ярамаган да әле, чөнки йөзенче баланың ирлек көче бетә дип исәпләгәннәр. Безнең көннәрдә дә ир баланы сөннәтләү үз әһәмиятен җуймаган. Борынгыдан килгән гадәт буенча, сөннәткә утырту балага 1, 3, 5, 7 яшь тулганда башкарыла, чөнки 2, 4, 6 һ. б. җөп яшь тулганда үтәлгән гамәл баланың үлеменә китерәчәк дип ышана халык. Гаиләдә малай туса, озакка сузмый әлеге йоланы башкарырга тырышалар. Дөрес, хәзерге заманда әлеге эш сөннәтче бабайлар кулына

түгел, ә тәҗрибәле табиблар кулына тапшырыла. Чистай районында бу йоланы кунаклар чакырып, сөннәт боткасы пешереп, зурлап бәйрәм итәләр. *«Малаема да сөннәт боткасы үткәрдек. Оныгыма да үткәрдек. Чәй куябыз, чәй янына камыр ризыгы пешерәбез, ботка пешерәбез. Я карабодай боткасы, я дөге боткасы, я тары боткасы. Кем ничек ярата. Туганнарны чакырабыз. Киленнең әти-әнисе килә, тирә-күрше килә. Бер адәм баласы да буш килми»* (Закирова Саимә Лотфулла кызы, 1947, Кызыл Болгар авылы).

Бала тууга бәйле йола-гадәтләрне барлап чыккач, бер нәрсәгә инанасың: еллар, гасырлар дәвамында аларның байтагы онытылган, югалган, үзгәреш кичереп, башка төсмер алган. Әмма асылы шул ук калган. Һәр йола сабый баланың «яңадан тууына», җәмгыятьтә үз урынын алуга, анда әдәп-әхлак кагыйдәләре тәрбияләүгә хезмәт итә. Заман белән бергә йолалар онытылып бара дисәк тә, шунысы сөенечле: сабыйның беренче көннәреннән үк аңа үзгә бер игътибар күрсәтү, туган-тумачаның моны уртак бәйрәм буларак кабул итүе, үзара ярдәмләшеп, кунакларга йөрешеп аралашуы, өлкәннәргә ихтирамлы мөнәсәбәт татар халкы өчен бүген дә җуелмас рухи кыйммәтләрнең берсе булып кала.

**Әдәбият**

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан, 2011. 331 б.

*Брусько З.М., Завгарова Ф.Х.* В круге жизни (фольклор семейно-бытовой обрядности татар Заказанья). Казань: Ихлас, 2014. 224 с.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д–С). Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 378

***Ф.Ф. Харисов***

# УКУЧЫЛАРДА КОМПЕТЕНЦИЯЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ МӘСЬӘЛӘСЕ: ЛИНГВОМЕТОДИК АСПЕКТ

В данной статье раскрывается тесная взаимосвязь между образовательным процессом и формированием и развитием различных компетенций в ходе обучения родному (татарскому) языку. Среди них наиболее значимыми считается общественно-политическая, коммуникативная, информационная, культуроведческая компетенции. Наряду с этим в условиях Республики Татарстан подчеркивается особая актуальность формирования и совершенствования у учащихся коммуникативной, лингвистической, национально-культуроведческой компетенций как социально значимых.

**Ключевые слова:** компетенция, лингвометодика, культуроведческая компетенция, коммуникативная компетенция, Стандарт, татарский язык.

This article reveals the close relationship between the educational process, formation and development of various competences in the course of language learning. Among them, the author considers the most significant socio-political, informational, communicative and cultural competence. Along with this, special relevance of the formation and improvement of the communicative, linguistic, and national cultural competences of the students in the conditions of the Republic of Tatarstan is emphasized.

**Keywords:** competence, linguistic methods, cultural competence, communicative competence, Standard, Tatar language.

Белемле булу үзе генә, куллану осталыгы һәм күнекмәләр булдырудан башка, мәктәптән тыш эшчәнлеккә әзерләү мәсьәләсен хәл итә алмый. Шуңа да бүгенге лингвометодикада бу проблема киңрәк һәм башка төрле яссылыкта куела: белем алуның максаты белем һәм осталыкка ия булу гына түгел, бәлки иҗтимагый тормышка әзерләү өчен, укучыларда кирәкле компетенцияләр булдыру.

XX гасыр ахырларында телләр укыту методикасында «компетенция» термины кулланыла башлый.

1996 елда «Европада урта белем» проекты кысаларында Берн шәһәрендә үткәрелгән симпозиумда кабул ителгән компетенцияләр рәтенә түбәндәгеләр кертелгән:

1. Икътисади-сәяси компетенция яки көндәлек тормышта туган проблемаларны чишүгә әзерлек (кирәкле карарны кабул итү һәм аны гамәлгә ашыру җаваплылыгын үз өстеңә алу).

2. Мәгълүмати компетенция (яңа алынган мәгълүмат чыганаклары белән эшләүгә әзерлек һәм аңа ихтыяҗ булу): тиешле хәбәрне төрле чыганаклардан эзләп табу; аның дөреслеген, яңалыгын һәм тормыштагы әһәмиятен ачыклау; яңалыкны куелган бурычларны хәл итүгә бәйле рәвештә эшкәртү, саклау (архивка урнаштыру) һәм кирәк вакытта аларны эзләп табып файдалану.

3. Коммуникатив компетенция (аралашу компетенциясе). Укучыларны өйрәнелә торган телдә дөрес итеп аралашырга өйрәтү.

4. Иҗтимагый-мәдәни компетенция. Күп мәдәниятле җәмгыятьтә үзара хезмәттәшлек итүгә һәм иҗтимагый тормышка әзер булган шәхес тәрбияләү.

5. Гомер буе белем алуга әзер булу компетенциясе югарыда саналган максатларны гамәлгә ашырудан килеп чыга [Соловьёва, 2002, с. 11–14; 228].

Телгә яңа стандартлар нигезендә өйрәткәндә, укучыларның универсаль танып белү компетенцияләрен үстерүдә һәм камилләштерүдә түбәндәгеләргә өстенлек бирелә:

• проектлау-тикшеренү күнекмәләрен гамәли яктан үзләштерү;

• текстның мәгънәсенә төшенеп уку һәм алган мәгълүмат белән эшли белү күнекмәләрен бирү;

• танып белү ысулын гамәли яктан куллана белергә өйрәтү, тел дәресләрендә логик фикерләү алымнарына ия булу.

Мәсәлән, башлангыч сыйныфларда үзләштерелгән мәгълүмат белән эшләү күнекмәләре тагын да камилләштерелә, үстерелә һәм түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелә:

• әзер мәгълүмат чыганакларындагы фикерләрне системага салып, чагыштырып, тикшереп һәм гомумиләштереп, мөстәкыйль аңлатмалар бирергә өйрәтү;

• аерым текстлар белән эшләгәндә, төп фикерне аерып алып, аны тезис рәвешендә кыска, җыйнак һәм төгәл итеп, график формада (таблица, схема, карта яки диаграмма) җиткерү;

• таблица һәм схемаларны тутыра, график рәсемнәрне тулыландыра белү. Моның өчен тел дәресләрендә мәгълүматны төрле чыганаклар һәм заманча техник чаралар ярдәмендә эзләп табарга өйрәтү, Интернет челтәреннән чамасын белеп һәм дөрес файдалану.

Укучыларның *танып белү компетенциясен* Стандарт нигезендә үстерүдә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү күздә тотыла:

• тел дәресләрен туган ил тарихы һәм географиясе, мәдәни мирасы һәм традицияләре белән бәйләнештә алып бару;

• дәресләрдә үтелә торган темалар нигезендә туган илнең иҗтимагый-сәяси төзелешен, анда булып узган тарихи вакыйгаларны хронологик һәм фактик яктан белү; шуңа бәйле рәвештә дәүләт символларын – герб, флаг һәм гимнны, дәүләт бәйрәмнәрен белү;

• илнең гражданнары һәм аерым милләт вәкилләре буларак, үз хокукларын һәм бурычларын аңлау, милли традицияләрне, мәдәниятне һәм кыйммәтләрне аңлау, белү.

Югарыда саналган компетенцияләрнең уку-укыту эшчәнлегендәге әһәмиятен һич тә инкяр итмичә, татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге компетенцияләрне булдыру мөһим.

*1. Аралашу компетенциясе.* Узган гасырның 80 нче елларында «коммуникатив компетенция» дигән төшенчә барлыкка килә. Бу терминны Америка социолингвисты Делл Хаймс тәкъдим итә.

Ул аралашу өчен тел тамгаларын һәм аларның кушылу кагыйдәләрен белү генә җитмәвен, мәдәни һәм иҗтимагый яктан әһәмиятле шартларны, вакыйгаларны белү кирәклеген дә әйтә. Шуңа күрә коммуникатив компетенцияне «интегратив белем бирү» дип атый һәм аның эчтәлегенә лингвистик һәм иҗтимагый-мәдәни компонетларны да кертә [Соловьёва, 2002, с. 10]. Бу фикер күп кенә чит ил галимнәре тарафыннан кабул ителә һәм кулланылышта йөри башлый, ләкин аңа өстәмәләр дә кертелә. Мәсәлән, Америка галимнәре М. Кэнэл һәм М. Свейн дүрт хосусый компетенцияне аерып чыгара: грамматик (лингвистик), дискурсив, социолингвистик һәм стратегик [Соловьёва, 2002, с. 18–22].

Аралашу компетенциясе үз эченә түбәндәгеләрне ала:

• башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы;

• хәзерге татар әдәби теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын һәм сөйләмнең грамматик ягын дөрес үзләштерү;

• бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен телдән һәм язма формада булдыру;

• урта һәм өлкән сыйныф укучыларының кызыксыну даирәсен киңәйтү, туган телдә психологик һәм төрле аралашу ситуацияләренә бәйле рәвештә аралаша белүләренә ирешү, дәресләрдә үзләштергән белем һәм күнекмәләрдән нәтиҗәле итеп файдалана белү һ. б.

Шуның белән беррәттән, аралашу эшчәнлеген үстерүгә караган универсаль күнекмәләрдән түбәндәгеләргә өстенлек бирелергә тиеш:

• төркем белән эшләү күнекмәләрен булдыру (укучының иптәшләре һәм укытучы белән бергәләп эшләве мораль-әхлакый һәм психологик яктан гамәли эш алымнарына өйрәтә);

• аралашу компетенциясе нигезендә төрле бурычларны хәл итү алымнарын үзләштерү, тел өйрәнүнең башка кешеләр белән аралашу нигезен тәшкил итүен аңлау, шул максаттан чыгып, тормыш хәлләренә бәйле рәвештә иптәшең белән аралашу нормаларын һәм формаларын үзләштерү;

• тел өйрәнүдә акыл һәм сөйләм эшчәнлеген үстерүне һәм камилләштерүне алгы планга кую (укучыларның ана телен өйрәнүендә аралашу компетенциясен истә тотып эш итүенә этәргеч ясый).

*2. Лингвистик компетенция* укучыларның сөйләмне грамматик яктан дөрес формалаштыруларын, өйрәнелә торган телнең төрле яруслары буенча (лексика, фонетика, грамматика) телдән һәм язма формада ирекле аралашуларын оештыра алырлык белемгә ия булуларын аңлата.

*3. Милли мәдәният өлкәсенә караган компетенция,* ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү укучыларны сөйләмгә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләре мисалында татар сөйләм әдәбе

нормаларын үзләштерү, шулар аша халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен белү, телнең милләтләр арасында аралашу-аңлашу чарасы булуына төшенү; тел тарихы белән халык тормышының аерылгысыз булуын аңлау.

*4. Иҗтимагый-мәдәни компетенция.* Иҗтимагый-мәдәни белем бирү – мәгариф системасында чагыштырмача яңа төшенчә. Ул иҗтимагый-мәдәни компетенция формалаштыру белән бәйле аралашу компетенциясе составына керә һәм аның бер өлеше булып санала.

Укыту процессына иҗтимагый-мәдәни яссылыкта якын килү телгә татар мәдәнияте аша өйрәтү юнәлешен билгели. Бу компетенциягә түбәндәгеләр керә:

• телнең танып белү һәм аралашу чарасы гына түгел, бәлки иҗтимагый хәтер формасы да икәнлегенә төшенү;

• һәр тел берәмлеге эчендә аңа хас булган мәдәни эчтәлекне күрә белү;

• өйрәнелә торган тел вәкилләре һәм сөйләм белән милли-мәдәни мохит арасындагы бәйләнешне аңлау;

• тел һәм җәмгыять үсеше турындагы белемнәр җыелмасын куллану, татар телендә аралашу осталыгына ия булу;

• иҗтимагый-мәдәни эчтәлектәге белем (Туган ил яки туган төбәк, өйрәнелә торган тел, аның рухи байлыклары, мәдәни традицияләре турында мәгълүмат) алу;

• аралашу тәҗрибәсен туплау;

• телне куллану алымнарын белү;

• чит тел мәдәнияте күренешләренә шәхси мөнәсәбәт белдерү;

• мәгълүмати яктан бай булу;

• актуаль һәм заманча булу;

• аутентик текстларның күплеге;

• татар мәдәниятен чагылдырган текстлар булу;

• укучыларның кызыксыну даирәсен истә тоту;

• сөйләмнең татар әдәби теле нормаларына туры килүе;

• өйрәнелә торган текстларның катлаулана бару принцибына туры килүе;

• рус мәдәниятен чагылдырган материалларны даими куллану;

• сайлап алынган материалларның аңлаешлылык һәм көч җитү принципларына туры килүе.

Мондый таләпләр тел чаралары ярдәмендә укучыларда иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыруның нәтиҗәлелеген яхшыртырга ярдәм итә.

Яңа буын Стандартта укучыларны иҗтимагый тормышка әзерләү мәсьәләсенә зур урын бирелә. Мондый эшчәнлек – өзлексез дәвам итә, киң кырлы шәхеснең психик сыйфатларын үзгәртә һәм үстерә торган процесс. Аның иң мөһим өлеше кешенең балачак һәм яшүсмер чорларына туры килә, чөнки бу вакытта киләчәк тормышка әзерлекнең нигезе салына, әйләнә-тирәдәге күренешләр белән кызыксыну да көчәя.

Гомуми белем бирү оешмаларында, төрле компетенцияләрне булдыру максатыннан чыгып, укучыларны иҗтимагый тормышка әзерләү һәм тәрбияләү мәсьәләсе түбәндәге юнәлешләрдә алып барылса отышлы була:

• гражданлык, патриотизм хисләре тәрбияләү, кеше хокукына, ирегенә һәм бурычларына хөрмәт белән карау;

• Россиягә, Татарстанга һәм, гомумән, туган төбәккә мәхәббәт тәрбияләү;

• яшәү һәм аның мәгънәсе, гаделлек, мәрхәмәтлелек, әти-әниләрне һәм башка кешеләрне хөрмәт итү, җаваплылык, өлкәннәр һәм кечеләр турында кайгырту, шәхеснең рухи-әхлакый үсеше, вөҗдан һәм дин иреге;

• төрле мәдәни мохиттә яшәүче шәхеснең кешеләргә, дәүләт институтларына, җәмгыятькә ышанып каравы, милләтләрне һәм аларның мәдәниятләрен хөрмәт итүе;

• хокукый һәм демократик дәүләттә Ватанга хезмәт итү, илнең бүгенгесе һәм киләчәге өчен иҗтимагый җаваплылык хисе белән яшәү;

• матурлыкка, гармониягә ия булган кешенең эчке дөньясы, иҗатта һәм сәнгатьтә үз-үзен күрсәтә белүе, шәхесне рухи һәм эстетик яктан үстерү һ. б.

Яшь буынны иҗтимагый тормышка әзерләүдә тел дәресләрендә үткәрелә торган рольле уеннарның да әһәмияте зур. Анда катнашучылар рольләрне тәкъдим ителгән проект буенча алдан бүлешәләр. Ул, мәсәлән, бергәләп караган спектакль буенча яки укучылар үзләре уйлап тапкан аерым ситуация нигезендә булырга мөмкин. Уен геройлары, алдан әзерләнмичә, импровизация формасында үз фантазияләрен өстәп, сөйләшү юнәлешен билгеләп, кирәкле тема буенча үзара аралашу оештыралар. Мондый уеннарда төрле һөнәр ияләре, әти-әниләр яисә җәмәгать оешмалары вәкилләре дә катнашырга мөмкин.

Туган (татар) тел дәресләрендә өйрәтү уеннары иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыруда мөһим урынны алып тора. Без аларны фонетик, лексик һәм грамматик төрләргә аерып күрсәтәбез (Харисов, 1994; 1996).

Яңа җәмгыятьтә үз урыныңны табу телләр белүгә бәйле, һәм бу уңайдан гомуми белем бирү оешмаларында аны тиешенчә үзләштергән шәхес тәрбияләү мөһим бурычлардан санала. Проблеманы уңай хәл итүнең бер юлы – дәресләрдә иҗтимагый-мәдәни материалларны кирәгенчә куллану. Билгеле булганча, аерым темага караган текстлар аларның төп эчтәлеген тәшкил итә. Мәсәлән, Татарстан һәм Россия турында матур әдәбият әсәрләреннән алынган өзекләр, диалог (полилог) үрнәкләре, җырлар, шигырьләр, аудио- һәм видеотекстлар һ. б.

Телне мәдәният белеме яссылыгында өйрәнү, мәдәниятькә караган текстлардан файдалану укучыларның тел белән мәдәният бәйләнеше турындагы белемнәрен тирәнәйтергә, бу өлкәгә караган компетенцияләрен үстеререгә мөмкинлек тудыра, яшь буында милли

үзаң булдыруда зур роль уйный, татар телен чит тел буларак өйрәнүчеләргә башка милләт вәкилләренә карата түземле булырга, үз милләтенә караган рухи кыйммәтләр белән чагыштырып карарга һәм дөньяга карашын киңәйтергә ярдәм итә.

Укучыларда иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыру белем бирүдә яңа юнәлешләрнең берсе булып санала. Әлеге мәсьәләнең уңай чишелеше телне милли һәм мәдәни яссылыкта өйрәтү белән бәйле. Бала дәресләрдә үзенең һәм башка халыкларның мәдәниятен хөрмәт итәргә, аны дөрес бәяләргә, төрле халыкларның мәдәни кыйммәтләрен үзара бәйләнештә карарга өйрәнсен. Әлеге материаллар телгә һәм мәдәнияткә кызыксынучанлык, башка милләт вәкилләренә сабыр һәм түземле мөнәсәбәт тәрбияли. Шуңа да тел дәресләрендә татар һәм рус халкының мәдәни традицияләре, гореф-гадәтләре, кыйммәтләре белән танышу өчен зур мөмкинлек тудырыла.

«Иҗтимагый-мәдәни компетенция» төшенчәсен түбәндәгечә аңлап була:

• тел танып белү һәм аралашу чарасы гына түгел, бәлки иҗтимагый хәтер формасы һәм милләтнең мәдәни үсеш күрсәткече дә;

• сөйләм белән мәдәният арасындагы бәйләнеш турында мәгълүматка ия булу;

• тел һәм җәмгыять үсешенә, сөйләм булдыруга башка шартларның (кешенең яшәү рәвеше, мохит, милләтнең рухи байлыклары һ. б.) йогынтысы;

• күпмәдәниятле җәмгыятьтә яши һәм хезмәттәшлек итә белү.

Иҗтимагый-мәдәни компетенция укучыларда түбәндәге осталыкларны булдыруны күзаллый:

• өйрәнелә торган тел нормаларын һәм милли традицияләрне белү;

• иҗтимагый-мәдәни шартларга туры килгән уңайлы аралашу стилен сайлау;

• иҗтимагый-мәдәни эчтәлектәге ыгы-зыгыларны булдырмау һәм, килеп чыккан очракта, аларны уңай хәл итә белү;

• җәмгыятьтә, гаиләдә һәм эштә шәхеснең үз урынын белүе;

• өйрәнгән телдә аралашканда, сабырлык, түземлелек күрсәтү һәм әңгәмәдәшеңә ихтирамлы мөнәсәбәттә булу һ. б.

Шулай итеп, укучыларда иҗтимагый-мәдәни компетенцияне булдыруның һәм үстерүнең кирәклеге Стандартның эчтәлегеннән үк аңлашыла. Мондый юнәлеш телгә өйрәтүне милли һәм мәдәни яссылыкта алып баруның стратегиясен билгели. Кыскача гына әйткәндә, иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыру хәзерге күптөрле мәдәниятләр яшәгән җәмгыятьтә үзара дустанә мөнәсәбәткә ия булган хезмәттәшлеккә әзерлекне дә аңлата. Укучыларда аны формалаштыру һәм үстерү уку-укыту процессына куела торган белем бирү, үстерү һәм тәрбияви максатларны да хәл итүгә юнәлтелгән.

Билгеле булганча, милли мәдәният өлкәсенә караган компетенция белән иҗтимагый-мәдәни компетенция үзара тыгыз бәйләнештә

яши. Әлеге проблеманың бүгенге көндә аеруча актуаль булуын, татар теле укыту методикасына караган элеккеге һәм хәзерге хезмәтләрдә тиешле дәрәҗәдә чагылыш тапмавын истә тотып, шуңа да аңа киңрәк тукталдык.

Югарыда әйтелгәннәрдән түбәндәге гомуми нәтиҗәне чыгарып була:

1. Аралашу компетенциясе әйдәп баручы, башка компетенцияләрнең нигезен тәшкил итүче булып санала.

2. Хәзерге мәгарифнең уңышлы үсеше өчен, түбәндәге гамәлләрне тормышка ашырырга кирәк:

• уку эшчәнлегенең нигезенә салынган гамәли һәм белем бирү максатларының белем алуга юнәлтелгән булуы;

• белем бирүне үстерү максатын метапредмет һәм предмет буенча осталык һәм күнекмәләрне булдыруга, укучыларның фикерләү сәләтләрен үстерүгә тиңләштерү;

• тәрбияви максатны белем бирүдән көтелгән нәтиҗә һәм компетенцияләрнең җыелмасы итеп карау.

**Әдәбият**

*Крючкова Л.И.* Русский язык как иностранный. М.: Флинта; Наука, 2011. 215 с.

*Соловьёва Е.Н.* Методика обучения иностранным языкам: базовый курс. М: Просвещение, 2002. 256 с.

*Харисов Ф.Ф.* Рус телендә сөйләшүче балаларны татарчага өйрәтүнең башлангыч чоры. Казан: КДПИ, 1996. 48 б.

*Харисов Ф.Ф.* Экспериментальная программа по обучению татарской устной речи русских учащихся на первоначальном этапе. Казань: КГПИ, 1994. 34 с.

***Харисов Фираз Фахраз улы,***
*педагогика фәннәре докторы, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы профессоры*

УДК 81.246.6

***Ч.З. Абдуллина***

# МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕСЕ

В статье анализируется современное состояние функционирования татарского языка как языка обучения в образовательном пространстве, являющееся результатом и следствием факторов, условий его становления и развития в истории. Исходя из этого, оно рассматривается как исторически развивающееся явление. На сегодняшний день положение о создании полингвальных школ в Республике Татарстан может решить проблемы, которые возникли в системе образования.

**Ключевые слова:** национальное образование, язык образования, обучение на татарском языке, двуязычие, полилингвальное образование, языковая политика, история национального образования в Татарстане.

The article analyzes the current state of the functioning of the Tatar language as a language of learning in the educational space, which is the result and consequence of the factors and conditions of its formation and development in history. On this basis, it is considered as a historically developing phenomenon. To date, the provision on the establishment of multilingual schools in the Republic of Tatarstan can solve the problems that have arisen in the education system.

**Keywords:** national education, language of education, education in the Tatar language, bilingualism,polylingual education,language policy,history of national education in Tatarstan.

Күпмилләтле дәүләттә тел мәсьәләсен хәл итүдә төп ике фактор зур әһәмияткә ия. Аның беренчесе – илдә алып барыла торган тел сәясәте, икенчесе – бу телдә сөйләшә (аны үзенең туган теле итеп саный) торган халыкның үзаңы. Мәгариф системасында нинди телгә өстенлек бирү мәсьәләсен хәл иткәндә дә шушы ук факторларның йогынтысы зур. Татарстан Республикасы күпмилләтле Россия Федерациясенең бер субъекты һәм үзе дә милли яктан бик төрле булганлыктан, мәгариф системасында бер телгә генә өстенлек бирелә алмый.

Татарстанда барлыгы 173 милләт яши. Узган гасырның 90 нчы елларында килеп туган билгеле сәбәпләр дә Татарстанда тугандаш республикалардан, башка өлкәләрдән, илләрдән килгән төрле милләт вәкилләренең саны артуга китерде. Шунлыктан белем бирү өлкәсендә тел мәсьәләсе һәрвакыт аерым игътибар һәм дәүләт тарафыннан контрольдә тотуны таләп итә. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, бу соңгы елларда гына барлыкка килгән проблема түгел.

Мәгариф системасында татар теленең белем бирү сферасында кулланылышы бай тарихка ия. Мәсьәләнең асылын аңлау өчен, беркадәр үткәнгә күз салу да дөрес булыр. Россиядә белем бирү дәүләт тарафыннан көйләнә башлаган чордан ук, мәгариф системасындагы мәктәпләрнең белем бирү теленә мөнәсәбәтле бүленеше турында сүз

алып барганда, ике төрле мәктәп аерып күрсәтелә: рус телендә белем бирүче һәм башка халыкларның үз туган телләрендә белем бирүче мәктәпләр (инородческая). Әлеге бүленеш хәзер дә саклана, әмма без аны рус мәктәпләре һәм милли мәктәпләр дип бераз башкачарак атыйбыз. Шуның белән ул сорау тудыра да, чөнки рус мәктәпләре дә милли мәктәп санала. Моны дәлилләү өчен *милли* төшенчәсенең асылын ачыклап китик. Аңа билгеләмәләр бик күп, алар арасында тирән эчтәлеклеләре, катлаулы һәм гадиләре дә очрый. Без аларны файдаланып, мөмкин кадәр гади аңлатма биреп китүне кирәк санадык. Милли мәктәп – аерым бер халыкның мәнфәгатьләрен күздә тотып, аның телен һәм мәдәниятен өйрәнүне беренче планга куйган белем бирү учреждениесе ул. Алар шәхескә милли яктан үзбилгеләнү, милли тәңгәллеген тану, милли принципларга нигезләнеп, үзенә белем алу юнәлешен билгеләү өчен шартлар тудырырга тиеш. Рус мәктәпләре эшчәнлегенең дә әлеге таләпләргә туры килгәнлеген истә тотып, аларны да һич икеләнүсез милли мәктәп дип атыйбыз. Аерма шунда гына, рус мәктәпләре Россиядә иң күпсанлы милләт (титул милләт) мәнфәгатьләрен кайгыртса, милли мәктәп атамасын йөрткәннәр сан ягыннан азрак булган милләтләргә хезмәт күрсәтә. Рус мәктәпләрендә белем бирү – рус телендә, милли мәктәпләрдә билгеле бер халыкның туган телендә алып барыла.

Татар милли мәктәпләренең тарихы бик тирәнгә, беренче язу барлыкка килгән ерак гасырларга тоташа. Ләкин аның татар ханлыклары Россия дәүләтенә кушылганнан соңгы дәвере аерым игътибар сорый. Революциягә кадәр барлык татар мәктәпләренең 3% ы гына дәүләт карамаганда булган [Нигматов, 2001, с. 43]. Шунлыктан дәүләт милли мәктәпләрне сан ягыннан киметү максатын алгы планга куймаган, әмма аларның белем бирү эчтәлеге игътибардан бөтенләй үк читтә дә калмаган. Ул бигрәк тә революцион күтәрелеш елларында аерым күзәтү астына алынган.

Аңлашыла ки, Россия дәүләте составындагы күпсанлы милләтләр үз телләрен генә кулланып яши һәм эш йөртә алмаганнар. Дәүләт теле һәм милләтара аралашу теле булып саналган рус телен белү, иртәме-соңмы, һәркем өчен мәҗбүрияткә әверелгән.

Октябрь революциясенә кадәр рус телендә белем бирүче мәктәпләргә татар халкының, аның зыялыларының карашы каршылыклы булган. Алар тел белән бергә чит халыкның рухы да үтеп керәчәгән, моның иҗтимагый һ. б. өлкәләрдә күп кенә үзгәрешләр китереп чыгарачагын ачык аңлаганнар. Бу чор зыялыларының карашларын ачыграк аңлау өчен, күренекле галим, педагог Һ. Максуди фикерләренә игътибар итик. Татарлар өчен рус телендә белем бирүче мәктәпләр (ышкуллар) ачу турындагы бәхәсләргә ачыклык кертеп, 1914 елда «Йолдыз» газетасының 25 февраль санында (№ 1132) ул түбәндәгеләрне яза: «Әүвәлдә халык ышкулның мәктәп вә мәдрәсәләргә керүеннән курка иде, чат русча гына укыла торган ышкулларга балаларын бирүдән хафаланалар иде. Бу хәвеф вә каршылыклар

нәтиҗәсез калмадылар: хөкүмәт, мөселманнарның хәвефләрен бетерер өчен, 1907 елның 15 ноябрендә ышкуллар хакында яңа бер низам чыгарды. Бу яңа тип ышкуллар мәктәп вә мәдрәсәләргә кермиләр, үз алларына аерым ачылалар. Янә бу ышкулларда русча гына укытылмаячак. Һәркөнне ике сәгать кадәр мөселманча дин вә тел дәресләре укытылачак. Димәк, хәзер ышкуллар безнең мәхәллә мәктәпләренә кермәячәкләр, киресенчә, безнең дин вә тел дәресләребез ышкулларга керәчәк» [Максуди, 2018, б. 171].

Әлеге фикердән шулар аңлашыла: татар халкы, бигрәк тә аның зыялылары, татар-рус икетеллелегенә дә, балаларын рус телендә белем бирә торган мәктәптә укытуга да каршы килмәгәннәр. Әмма алар милли тәрбия бирүне һәм телне саклауны төп максатлары итеп санаганнар. Шуны искә алып, хөкүмәт тә рус мәктәпләрендә (ышкулларда) татар балаларына тел һәм дин дәресләрен укыту өчен махсус мөмкинлекләр (бала атнага 12 сәгать туган телен һәм милли яшәү кануннарын үзләштерә алган) тудырган. Димәк, татар телендә белем һәм тәрбия бирүче мәктәпләр һәм рус телендә белем биреп, укучыга милли тәрбия һәм туган телен өйрәнү мөмкинлеге тудырган ышкуллар барлыкка килгән.

Әгәр тарихка күз салсак, милли мәктәпләрнең белем бирү системасы да бер тел белән генә чикләнмәгән. Әйтик, татарлар белем алган җәдит мәдрәсәләрдә татар теле белән беррәттән гарәп, фарсы, төрек телләре дә укытылган. Шәкертләр белемнәрен алга таба Төркиядә, Гарәбстанда дәвам итә алырлык дәрәҗәдә бу телләрне дә үзләштергәннәр. Патша Россиясендә дә, рус теле генә түгел, француз, немец, инглиз телләре дә популяр булган, латин һәм грек телләрен дә өйрәнгәннәр. Географик янәшәлек һәм тормыш шартлары таләп иткәнлектән, төрки халыклар белән элемтәләр урнаштыру максатында, билгеле бер чорда руслар өчен татар телен өйрәнү дә максатчан юнәлеш алган. Бу уңайдан бер генә мисал китереп үтик, 1759 елда Казанда ирләр гимназиясе ачыла. Беркадәр вакыт үтүгә гимназия директоры **М.И. Веревкин** юллаган хатта түбәндәге юлларны укыйбыз: «Здешний город – главный для татарского национального диалекта. Не повелено ли будет завести при гимназии класс татарского языка?» [Рафикова, 1998]. 1769 елның 12 маенда Екатерина II аңа рөхсәт бирә. Гимназиядә татар сыйныфы да ачыла һәм Россия дворяннарына татар теле дә укытыла. Бу вазифаны **Сәгыйть Хәлфин** башкара һәм әлеге эш дәвамлы булып, анда Хәлфиннәрнең өч буыны хезмәт күрсәтә. Димәк, белем бирүдә иҗтимагый-сәяси шартлар тиешенчә исәпкә алына икән, белем бирү теле буларак нинди телне сайлау һәм тагын өстәмә нинди телләрне өйрәнү мәсьәләсе һәрвакыт нәтиҗәле хәл ителә.

Беренче рус революциясе тәэсирендә училищеларда укытуның яңа тәртипләре билгеләнә. Укуның беренче ике елында һәркем туган телендә белем ала. Алдагы елларда ул рус телендә белем алырга тиеш була, әмма туган телен уку предметы буларак өйрәнүне дәвам итә. Югары сыйныфларда һәм югары уку йортында туган телләр өйрәнел-

ми, моның өчен укытучылар да әзерләнми, туган телне өйрәтү буенча дәреслек, программалар әзерләү юнәлешендә эшли торган бер генә дәүләт оешмасы да булмый. Әмма татарлар моның дәүләт тарафыннан җайга салынуын көтеп тормый. Аерым шәхесләр үз мөмкинлекләре белән бу мәсьәләне хәл итәргә алыналар. Уку китабы рәвешендә төзелгән җыентыклар, аларны ничек һәм ни өчен укырга кирәклеген аңлаткан беренче язмалар шул эшнең башлангычы булып тора.

Мәгариф системасы алып барган эшчәнлек илнең мәдәни-рухи яктан үсешен тәэмин итеп кенә калмый, ул сәяси, икътисади үсешнең дә асылын тәшкил итеп, илнең киләчәген билгели.

Милли сәясәтнең бер өлеше булган тел сәясәте тулысынча дәүләттәге гомуми сәясәт белән бәйле. Тел сәясәте фән, мәгариф, массакүләм мәгълүмат чаралары, дәүләт эшләре һәм аларны алып баруга мөнәсәбәтле эш кәгазьләре (делопроизводство) һәм башка күп кенә өлкәләрне үз эченә ала. Күпмилләтле дәүләттә тел сәясәте иҗтимагый, этник, тел факторларына һәм милләтара мөнәсәбәтләрне көйләүгә дә йогынты ясауны күздә тота. Нәтиҗәдә, белем бирүдә нинди телгә өстенлек бирү мәсьәләсе, илдәге сәясәткә турыдан-туры бәйле булып, билгеле бер максатларны күздә тотып хәл ителә. Россиянең бер субъекты буларак яшәүче Татарстанда соңгы йөз елда барган үзгәрешләр дә шуны ачык күрсәтә.

Нинди телдә белем бирү проблемасы бервакытта да игътибардан читтә калмаган. Халык мәгарифенең I бөтенроссия съезды (1913) рус телендә генә түгел, туган телдә дә укытуның һәм шулай ук рус һәм ана телләрендә тигез дәрәҗәдә белем бирүнең мөһимлеген һәм кирәклеген раслаган резолюция кабул итә. 1914/15 уку елында Казан губернасының яртысын татарлар тәшкил итсә дә, татар телендә дөньяви белем бирүче, дәүләт тарафыннан финансланган мәктәпләр 56 дан артмаган. Бу барлык мәктәпләр санынының 3% ын тәшкил иткән, анда ике меңгә якын укучы белем алган [Нигматов, 2001, с. 43].

Октябрь революциясеннән соң, наданлыкны бетерү (ликбез) мәктәпләре ачылып, укырга-язарга өйрәтү массачыл төс алган чорда, үз әлифбалары булмаган, мәгариф системасы җайга салынмаган халыклар аны турыдан-туры руслардан кабул итәргә тиеш була. Нәтиҗәдә рус теле үзеннән-үзе алар өчен белем алу теленә әйләнә. Күп гасырлар дәвамында үзенең мәгариф системасын камилләштереп, белем бирүдә үз милли юнәлешен тудырган татарларда бу башкачарак юнәлеш ала. Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы игълан ителгән 1920 елда, республика җирлегендә 2,8 миллион кеше исәпләнә, аның 2,6 миллионы авылларда яши. Халыкның 55% ы татарлар, 42% ын руслар тәшкил итә [Сабирова, Шәрәпова, 2001, б. 263].

1921 елда ТАССРда татар теле дәүләт теле дип игълан ителә. Аны өйрәнергә теләүчеләр өчен төрле мөмкинлекләр тудырыла. Татар телен гамәлгә кую буенча үзәкләштерелгән комиссия эшли. Республикада яшәүче башка халыкларга татар телен үзләштерүдә аның гарәп графикасына (соңрак латин графикасына) нигезләнүе авырлык

тудыра. Әлеге чорда рус-татар икетеллелеге барлыкка килмәүдә әлеге факторның да өлеше зур. 1922 елның 21 декабрендә, Татарстан халык мәгарифе комиссариаты күрсәтмәсе нигезендә, барлык икенче баскыч мәктәпләрдә (шәһәр мәктәпләрен дә кертеп), һөнәри училищеларда, партия мәктәпләрендә, рабфак һәм югары уку йортларында татар телен укыту мәҗбүри куела. Югары уку йортлары студентлары аннан зачет тапшырырга тиеш була. Моның өчен шартлар тудыру максатыннан, программага кертелгән һәр фәннән татар телендә дәреслекләр бастырыла, югары уку йортлары милли мәктәпләр өчен укытучылар хәзерләүгә зур игътибар бирә. Мәктәпләрдә Туган якны өйрәнү, Татарстан географиясе, Татарстан тарихы кебек предметлар укытыла. 1930 елга татар һәм рус телләренең юридик һәм практик яктан дәүләт һәм иҗтимагый оешмаларда тигез хокуклы кулланылышта булуына ирешү бурычы куела. Бу рус-татар һәм татар-рус икетеллелегенең камил чагылышы буларак күзаллана.

Әмма 1924 елдан соң инде татар балаларына рус телен өйрәтүгә күбрәк игътибар бирелә башлый. Халыкның күпчелек өлеше (90% тан артыгы) авылда яши һәм туган телендә аралаша. Әмма төрле өлкәләрдә югары белем алу һәм төп аралашу теле сыйфатында рус теле кирәк була башлый. Димәк, бу телне өйрәнү беренчел максатка әверелә. Бу чорда аның киләчәктәге нәтиҗәләрен фаразлаудан, татар кешесе туган телен югалтырга мөмкин, дигән фикердән ерак торганнар. 1938 елда инде КПСС ҮК һәм СССРның Халык комиссарлары советы тарафыннан «Милли республика һәм өлкәләрдәге мәктәпләрдә рус телен укытуның мәҗбүрилеге турында» карар кабул ителә. Уку планнары һәм программалары бердәм таләпләргә туры китерелгәч, татар телендә белем бирүче мәктәпләр дә акрынлап рус телендә белем бирүгә күчә, туган тел уку предметы буларак кына укытыла башлый. 1930/31 уку елында татар балаларының 96,9% ы милли мәктәпләрдә белем алса, 1947/48 уку елында 95% ы туган телендә белем ала, 1958 елда бу күрсәткеч 70% ны гына тәшкил итә. Татарстанның татарлар иң күп яшәгән, укучыларның 98,5% ы татар балалары булган районарында да мәктәптә рус телендә белем бирелә [Шамсутдинов, Шайдуллин, 2012, с. 101–102]. 1958 елда СССР Югары Советы «Мәктәпнең тормыш белән бәйләнешен ныгыту турында» канунын кабул итә. Аның нигезендә ата-ана баласының нинди телдә белем алуын үзе сайлый. Нәтиҗәдә милли мәктәптә рус телен дә, татар телен дә өйрәнергә кирәк булганлыктан, бала өчен мәктәп программасының авырлыгын сәбәп итеп, ата-аналар балаларын милли мәктәпкә бирүдән читләшә башлыйлар. Рус телендә белем бирүче мәктәпләргә бу телне бөтенләй белмәгән, гап-гади сорауга да русча җавап бирә алмаган татар балалары килә. Мәктәптә алар бөтен фәннәрне дә рус телендә өйрәнә башлый. Балаларның һәм күп вакытта укытучыларның да тиешле әзерлеге җитмәү белем бирү процессын шактый катлауландыра. 1966/67 уку елында рус мәктәпләрендә укырга теләге булган балалар өчен II–X сыйныфларда татар теле ирекле

рәвештә атнага ике сәгать, ә татар мәктәпләрендә V–VIII сыйныфларда туган тел атнасына нибары 11 сәгать укытыла. 1973/74 уку елында яңа укыту программалары нигезендә генә туган тел атнасына 39 сәгать (I – X сыйныфларда) укытыла башлый [Чехоева, 1974, с. 34–36].

1980 еллар ахырына Россиядә милли мәктәпләр саны бик нык кими. Бу елларда татар телендә белем бирә торган мәктәпләрне дә милли мәктәп дип карау бик үк дөрес булмас иде, чөнки аларда интернациональ тәрбия бирелә. Казан шәһәрендәге 1 нче мәктәп һәм 10 нчы интернат-мәктәп кенә чын мәгънәсендә татар телендә белем һәм тәрбия бирә. Шәһәрләрдә мәктәпкәчә тәрбия бирү оешмалары рус телендә хезмәт күрсәтә, мәктәпләрдә белем рус телендә бирелә, татар балаларына татар теле факультатив буларак кына укытыла. Әмма республика авылларында татар телендә белем бирүче мәктәпләр эшли әле.

1989 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча, татарларның 36,8% ы шәһәрдә яши. Димәк, аларның балалары туган телдә белем һәм тәрбия алу мөмкинлеген югалткан дип исәпләргә мөмкин. Әмма сан ягыннан күрсәткечләр тагын да ныграк уйландыра. Республика күләмендә карасак, татар балаларының 28% ы гына туган телендә белем алган [Исхакова, Зиннурова, Мусина, 2002, с. 83]. Татар телендә белем бирү, туган телне өйрәнү мәсьәләсе бары узган гасырның 90 нчы елларыннан гына кабат уңай якка үзгәреш кичерә. 1992 елда «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы канунның кабул ителүе, татар теленең дәүләт теле статусы алуы аңа төп этәргеч бирә. Әлеге вакыйга белем бирү системасына да зур йогынты ясый. 2000 елларның башына инде республикадагы мәктәпләрнең яртысы диярлек (2455 мәктәпнең 1219 ы) татар телендә белем бирә. Әлеге мәктәпләрнең 60% ка якыны – инновацион юнәлештәге белем бирү оешмалары. 455 рус мәктәбендә татар телендә белем бирә торган 3 меңгә якын класс ачыла. Республикада яшәгән халыкларга туган телләрендә белем бирүне җайга салу 100% рус балаларына, 51% татар балаларына, 55% чуваш балаларына, 67% удмурт балаларына, 51% мари балаларына, 8% мордва балаларына туган телдә белем алу мөмкинлеге тудыра [Харисов, 2005, с. 105]. Россия халыкларының дәүләт телен өйрәнүләре юнәлешендә 2001 – 2005 елларда «Татарстанда рус теле» дип аталган максатчан программа тормышка ашырыла. Татарстан мәктәпләрендә, туган телдән тыш, рус һәм татар телләре дәүләт теле буларак укытыла. Барлык укучыларның 99,3% ы татар телен өйрәнә. Димәк, мәктәптә белем бирү икетеллелек өчен киң мөмкинлекләр тудыра. Мәктәпкәчә тәрбия бирү оешмаларының да бу юнәлештә зур тырышлык куюын искә алганда, бу мөмкинлекнең тагын да артуын, күрәбез. «Россия Федерациясендә белем бирү турында»гы (2012 ел, 29 декабрь) федераль канун нигезендә Россия гражданнары мәгариф системасының барлык этапларында да туган телдә белем алу хокукына ия (14 маддә). Әмма югары белем системасында аның сакланмавы мәктәпләрдә туган телдә генә белем алу теләгенә каршылык тудыра.

Белем бирү системасында туган телнең саклануы, дәүләт телләренең (безнең очракта татар һәм рус телләре) бертигез дәрәҗәгә ирешүләре өчен, әлеге телләрнең иҗтимагый тормышта тигез хокуклы булып, бердәй функциональ мөмкинлекләргә ия булулары кирәк. Шуның белән бергә тел өлкәсендә демократик принципларны саклау сорала, белем бирү системасында милли телләрнең дәрәҗәсен күтәрү өчен, комплекслы чаралар күрелергә тиеш. Татар телендә югары белем бирүче уку йортлары булмаганда, татар телендә урта белем бирү дә ясалма хәлдә генә саклана ала [Сагдеева, 2003, с. 89–90].

Милли үсеш концепциясендә туган тел һәрвакыт беренчел фактор буларак күрсәтелә. Милли мәгариф халыкның туган теленә нигезләнеп кенә үсә ала. Милләт һәм телне саклауга мөнәсәбәтле мәсьәләләр күтәрелгән һәр очракта туган телдә югары белем бирүнең зарурилыгына аерым игътибар юнәлтелү дә шуның белән аңлатыла. СССР составындагы союздаш республикалар бу мөмкинлекне һәрвакыт файдаланып килделәр. Ә мөстәкыйль дәүләт статусын алу аларга бу өлкәдә тагын да киңрәк юл ачты.

Узган гасырның 90 нчы елларында Татарстан Республикасында да бу юнәлештә эш алып барыла. Татар дәүләт милли университеты ачу идеясен күпләр хуплап каршы ала. Аерым югары уку йортларында татарча укытыла торган төркемнәр оештырыла. Беренчеләрдән булып Кама политехник институты башлаган юнәлеш КДАТУ, КАИ, КХТИ, Казан авыл хуҗалыгы институтларында дәвам итте [Сагдеева, 2003, с. 91]. Әмма бу идея тулысынча тормышка ашырылмый калды. Белем бирү өлкәсендә Бердәм дәүләт имтиханнары кертелеп, аларны бары рус телендә генә тапшыру мәҗбүрияте туу татар телен урта белем алу системасыннан шактый кысрыклады. Татар мәктәпләрендә дә төп фәннәр рус телендә укытыла башлады. Бу татар телендә югары белем бирүгә юлны ябып чикләде.

2017 елдан мәктәпләрнең күбесендә татар теле туган тел буларак кына калдырылып, дәүләт теле буларак укытылудан туктады. Туган телгә бирелгән сәгатьләр саны аз булу телне өйрәтү мөмкинлеген киметсә, рус телен туган тел дип санаганнар шул ук вакытны рус телен өйрәнүгә сарыф итеп, рус теленнән Бердәм дәүләт имтиханына ныклап әзерләнү мөмкинлегенә ия булганлыктан, татар милләтеннән булган ата-ана һәм бала туган телен сайлау алдына куела. Ул сайлау татар теле файдасына булмаска да мөмкин.

Заман таләбеннән чыгып, Татарстанда полилингваль мәктәпләр челтәре булдыру максаты куелды. Әлеге мәктәпләрдә белем бирү теле өч телдән дә ким булмаячак һәм аның берсе татар теле булачак. Бу мәктәпләр белән генә чикләнмичә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын да үз эченә алып, татар телен, Россия халыкларының дәүләт телен һәм ике чит тел үзләштергән зыялы шәхес үстерүне максат итә.

Фән-техника үсеше, чит илләр белән икътисади, сәяси, мәдәни бәйләнешләрнең көннән-көн үсүе полилингваль белем бирү мәсьәләсенең әһәмиятен тагын да арттыра. Заман таләпләрен икетеллелек кенә

канәгатьләндерә алмый. Полилингваль мәктәпләрдә телләр, уку предметы сыйфатында гына түгел, белем бирү теле буларак та кулланыла. Әйтик, татар теленең белем бирү дәрәҗәсендә кулланылуы укучыларга аны камил үзләштерергә ярдәм итә. Ә бу үз чиратында киләчәктә төрки дөнья белән мөнәсәбәтләр урнаштыруга юл ача.

Күзәтүләрдән чыгып шундый нәтиҗә ясарга була: татар теле халкыбыз өчен һәрвакытта да аның белем алуга булган ихтыяҗын канәгатьләндереп килгән, белем бирү теле буларак үз вазифасын үтәгән, күрше халыклар тарафыннан өйрәнелгән, аралашу, икътисади-мәдәни бәйләнешләрне үстерүгә хезмәт иткән. Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр аның бу вазифасына төрлечә йогынты ясап торган. Әмма мәгариф системасында ул үзенең тотрыклы урынын барыбер саклап кала алган. Гуманитар, табигать, төгәл фәннәрдән терминнар эшләнү, урта һәм һөнәри белем бирү өчен татар телендә дәреслекләр басылу, аерым юнәлешләрдә югары белем бирүгә тулы мөмкинлекләр булу шуны раслый.

Хәзерге көндә бары татар телен генә белем бирү теле буларак куллану дөрес тә булмас иде. Татар телен белем бирү теле буларак файдалану һәм туган тел буларак укытуның чикләрен дөрес билгеләү һәм тормышка ашыру тел һәм милләт язмышына уңай йогынты ясаячак.

**Әдәбият**

*Әхмәтһади Максуди* мәкаләләре // Казан утлары. 2018. № 9. Б. 170–175.

*Исхакова З.А., Зиннурова Р.И., Мусина Р.Н.* Современная этноязыковая ситуация в Республике Татарстан. Казань: Печатный двор, 2002. 92 с.

*Нигматов З.Н.* Общие вопросы развития национального образования и воспитания личности в РТ. // Актуальные проблемы современного образования / под.ред. академика М.И. Махмутова. Казань: Центр инновационных технологий, 2001. 390 с.

*Рафикова Г.* Первой Казанской мужской гимназии – 240 лет // Эхо веков [Электронный ресурс]. 1998. № 1/2. Режим доступа: http://www.archive.gov.tatarstan.ru/magazine/go/anonymous/main/? path=mg:/

*Сабирова Д.К., Шәрәпова Я.Ш.* Ватаныбыз тарихы: югары уку йорты өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2001. 383 б.

*Сагдеева Ф.К.* Проблемы культуры татарской речи в условиях активного двуязычия. Казань: Фикер, 2003. 160 с.

*Харисов Ф.Ф.* Региональная система образования: состояние и стратегия эволюции. М.: ГосНИИ семьи и воспитания, 2005. 544 с.

*Чехоева С.А.* Некоторые итоги работы национальных (нерусских) школ РСФСР по новым программам и учебникам родного языка и литературы // Вопросы подготовки учителей родного языка и литературы. Казань, 1974. 232 с.

*Шамсутдинов Д.З., Шайдуллин Р.В.* Особенности развития татарской национальной школы в ТАССР в 50–60-е годы XX века // Ученые записки Казанского университета. Гуманитарные науки. Том 154, кн. 3. Казань, 2012. 234 с.

***Абдуллина Чулпан Зөфәр кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 792

*А.Р. Салихова*

# АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ Г. КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ КУЕЛГАН ӘСӘРЛӘРЕНӘ ХАС СӘНГАТИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

В статье рассматриваются спектакли ТГАТ им. Г. Камала по произведениям Аяза Гилязова. Разные режиссеры по-разному раскрывали в своих постановках художественное своеобразие писателя. Отличительными чертами пьес А. Гилязова были их острая современность, четкая постановка нравственных проблем, пристальное внимание к внутреннему миру человека. На материале его пьес смогли раскрыть свой творческий потенциал не одно поколение актеров.

**Ключевые слова:** повесть, спектакль, режиссер, театр, актер, сцена.

The article analyzes the performances of the Tatar State Academic Theater named after G.Kamal based on Ayaz Gilyazov’s works. Different directors in their staging revealed the artistic originality of the writer in different ways. The distinctive features of A. Gilyazov’s plays were their acute modernity, a clear statement of moral problems, and close attention to the inner world of man. More than one generation of actors was able to reveal their creative potential on the material of his plays.

**Keywords:** story, performance, director, theater, actor, stage.

Аяз Гыйләҗев иҗаты татар әдәбияты тарихында иң якты сәхифәләрнең берсен тәшкил итә. Әдипнең кызыксынучанлыгы һәм тормышны яратуы, дөньяга үзгә карашы һәм иҗади кыюлыгы заманы өчен үтә актуаль үзенчәлекле әсәрләр тудырырга ярдәм итте. Аяз Гыйләҗев үзен иң яхшы психологик проза остасы итеп танытты. Ул татар драматургиясе үсешенә дә шактый зур өлеш кертте.

Аяз Гыйләҗев кырыктан артык пьеса язган. Кызганычка каршы, аларның барысына да озын һәм бәхетле сәхнә тормышы насыйп булмаган.Әмма Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелганнары шөбһәсез татар драматургиясе һәм театры үсешенә сизелерлек йогынты ясады.

Аяз Гыйләҗевнең пьесалары сәхнәгә беренче мәртәбә 1960 еллар башында менде. 1960 елның 19 ноябрендә «Җиз кыңгырау» драмасының премьерасы булды. Аны сәхнәгә Р. Тумашев куйды. Ә 1961 елның 13 февралендә тамашачылар «Киек каз юлы» спектаклен (режиссеры Ш. Сарымсаков) карадылар. Театр тәнкыйтьчесе Г. Кашшаф бу турыда шулай яза: «Яшь язучы Аяз Гыйләҗев бер сезонда ике драма тәкъдим итте. Ләкин аның ике драмасы да тиешле югарылыкта куелмады. Беренче чиратта аңа режиссер ярдәме булмады. Режиссерлар Р. Тумашев һәм Ш. Сарымсаков иптәшләр яшь язучы алып килә торган яңалыкны, яңа сүзне, яңа идеяне аңлап бетерә алмадылар һәм шуңа күрә драмаларның зур идеясе залда тиешенчә яңгырый алмады.

Постановкалар академия театры маркасы белән чыгарырлык югары квалификацияле дип танырлык түгелләр. Моның белән мин А. Гыйләҗев әсәрләре кимчелексез, бары режиссерлар гына гаепле дип әйтмим. Ләкин драмалардагы яхшы орлыкны, җимеш бирергә тиешле орлыкны иң беренче чиратта режиссерлар күрергә тиеш иде» [Кашшаф, 1962, б. 6].

«Җиз кыңгырау» һәм «Киек каз юлы» спектакльләре театр тормышында зур вакыйгага әверелә алмадылар, әмма аларда күтәрелгән әхлакый проблемалар бөтен җәмәгатьчелекне уйланырга мәҗбүр итте.

Беренче тапкыр 1961 елның 18 декабрендә уйналган «Көзге ачы җилләрдә» спектакле тамашачыларда зур уңыш казанды. Әсәр бик яшь һәм саф күңелле кыз баланың язмышы турында. Ул тормышта беренче мәртәбә өзелеп яраткан егетенең хыянәте белән очраша. Мәхәббәт һәм тугрылык, тормыштагы ныклык һәм яхшылыкка ышану темасы тамашачыларның күңелен биләп ала. Спектакль тагын шул ягы белән дә игътибарны җәлеп итә, анда яңа гына Мәскәүдә укуларын тәмамлап кайткан яшь артистлар – Н. Ихсанова, Н. Дунаев, Р. Таҗетдинов, Д. Хәйруллин, Р. Батулла һ. б. уйный. Спектакльнең режиссеры – щепкинчыларның яраткан остазы, тәҗрибәле режиссер Габдулла Йосыпов. Яшьләр белән бергә өлкәнрәк буын артистлар да катнаша: Х. Уразиков, Г. Ибраһимова, Р. Җиһаншина, В. Минкина һ. б. Алар спектакльгә психологизм, тирәнлек һәм ритм өстиләр. Г. Арсланов сүзләренә караганда, Г. Йосыпов зур тәҗрибә туплаган өлкәнрәк буын артистларга хас җанлы, мәгънәле уен традицияләренең яшьләрнең энергиясе, дәрте, ихласлыгы белән кушылуына, спектакльдәге барлык рольләрнең диярлек үзара ярашып башкарылуына ирешкән [Арсланов, 2002, с. 55].

Театр белгече Д. Гыймранова болай дип искә ала: «Өстәвенә бу спектакльнең эчке атмосферасында А. Чехов әсәрләренә хас ниндидер бер аерым моңсу тынлык, кырыс һәм җилле-яңгырлы, йөрәкләрне җилкетә торган шигъри дәрт бар иде» [Гимранова, 2008, с. 3].

«Көзге ачы җилләрдә» спектакле тәүге буын щепкинчыларның беренче «визит карточкасы»на әверелә. Кыска гына вакыт аралыгында 300 тапкыр сәхнәдә уйнала. Спектакль аркасында тамашачы яшь артистларны таный башлый һәм яратып та өлгерә.

1967 елда Г. Камал театры тагын А. Гыйләҗев иҗатына мөрәҗәгать итә. Режиссер Р. Бикчәнтәев совет мәктәбендәге формализм һәм бюрократизмны фаш иткән «Җиргә тапшырылган серләр» драмасын куя.

Шул ук 1967 елда А. Гыйләҗев һәм А. Яхинның «Шамил Усманов» тарихи-драматик пьесасының премьерасы була. Режиссер М. Сәлимҗанов тарафыннан героик-романтик планда куелган спектакль Татарстанның театр тормышында күренекле вакыйгага әверелә. Рәсми идеология кысаларыннан чыкмаса да, әсәрдә чын драматизм, тормыш дөреслеге ярылып ята. Матбугаттагы язмалар да шуны

раслый. « Пьеса авторлары А. Гыйләҗев һәм А. Яхин Усмановның яшьлеге, В.В. Куйбышев кушуы буенча ул татар доброволецлары батальонын җитәкләгән чор турында сөйләргә телиләр. Спектакль (режиссеры М. Сәлимҗанов) Самара ревкомында Куйбышев кабинетындагы күренештән башланып китә дә. Тамашачыны 1918 елның шомлы вакыйгаларына алып керүче әлеге күренеш ике капма-каршы характерны бирүгә корылган: тыныч, сабыр, тирәнтен уйлап эш итүчән Куйбышев (Ш. Биктимеров) һәм ашкынучан, ашыгучан, бик тиз кызып китүчән Шамил Усманов. Әлеге рольне уйнаган Н. Дунаев тамашачының игътибарын тиз арада үзенә җәлеп итәрлек кызыл комиссар образын тудыра алган, аны ягымлы, көчле, энергияле, революциягә ихлас күңелдән ышанып, башкаларны да үзенә иярттә алырдай кеше итеп гәүдәләндергән.

Спектакльнең уңышы – күмәк күренешләрдә. Аларны куйганда тапкырлык һәм үткен фикер эшкә җигелгән. Усмановның акылы, кыюлыгы, тәвәккәллеге кебек менә дигән сыйфатлары нәкъ менә күмәк күренешләрдә ачыла. Сәгъдетдинне – революцион идеяләрне дә кабул иткән, Аллага да ышанган һәм борынгы гореф-гадәтләргә тугрылык та саклаган авыл картын Ф. Хатыйпов яратып һәм юмор кушып уйный. Беркатлы һәм тиз ышанучан Сәхи (Х. Җәләлов) үзенә карата симпатия һәм кызгану хисе уята. Ул Сәкинәне ярата. Сәкинә үзе, Н. Ихсанова уйнавында, сөйкемле, оялчан, сөйгән ярына чиксез тугрылыклы кыз булып күз алдына килеп баса» [Горова, 1970, с. 4].

Г. Камал театры сәхнәсендә А. Гыйләҗевнең башка пьесалары да куела: «Эңгер-меңгер» (режиссеры П. Исәнбәт, 1971 ел), «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз» (режиссеры М. Сәлимҗанов, Р. Хаҗиәхмәтов, 1975 ел), «Көйсезләнгән сәфәр» (режиссеры Д. Сираҗиев, 1988 ел). Аларның һәрберсе үзенчә кызыклы булды.

Шулай да Аяз Гыйләҗев, беренче чиратта, прозаик буларак ачылды. Нәкъ менә эпик әсәрләрендә ул үзен, форма һәм эчтәлек ягыннан театр өчен котылгысыз кысалар белән чикләмичә, иркен һәм ирекле тота. Шуңа күрә аның иң яхшы, тирән эчтәлекле, үзенчәлекле повестьлары үз вакыты белән сәхнәгә юл алды.

1987 елның 1 апрелендә театр тамашачыларга «Өч аршын җир» спектакленең премьерасын тәкъдим итте. А. Гыйләҗевнең шул исемдәге повесте 1963 елда ук дөнья күрә һәм республиканың мәдәни тормышында күренекле вакыйгага әйләнә. 1970 еллар башында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов А. Гыйләҗевкә әсәрнең сәхнә вариантын эшләргә тәкъдим итә. 1972 елда театр спектакль өстендә эшли башлый, әмма бу вакытка иҗтимагый вазгыять, алтмышынчы еллар белән чагыштырганда, шактый үзгәрә, спектакль куелмый кала. Әмма М. Сәлимҗанов үз идеясеннән кире кайтмый һәм әсәр барыбер куела.

1980 еллар ахыры – үзенә бер игътибарга лаек заман. Иҗтимагый тормышта бу – күтәрелеш, яңарыш, өмет, тәҗрибәләр... Татар театры өчен осталык ягыннан һөнәри өлгергәнлек, союз күләмендә

танылу чоры. СССРның халык артисты, күренекле режиссер М. Сәлимҗановның көче һәм таланты ташып тора, абруе зур. Камал театры сәхнәсендә ТАССРның һәм РСФСРның халык һәм атказанган артистлары аның җитәкчелегендә бөтен көчләрен куеп эшлиләр. Театрның иҗат коллективы зур юл уза, ә алда иҗтимагый фикердәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә ачылган яңа горизонтлар күренә. Театр сәнгате форма һәм эчтәлек өлкәсендә актив эзләнүләр алып бара. Шул ук 1987 елда Г. Камал исемендәге театрда режиссер Д. Сираҗиев тарафыннан Ч. Айтматовның күп яклары белән революцион «Ахырзаман» романы сәхнәләштерелә.

Болар барысы «Өч аршын җир» спектаклендә дә чагылыш таба. М. Сәлимҗанов эпик, тирән, җитди спектакль иҗат итә. Борынгы грек трагедияләре үрнәгенә ияреп, ул хикәяләү тукымасына язмыш-тәкъдирне, Тарихны гәүдәләндергән хорны кертеп җибәрә. Бу куелышка масштаблылык өсти һәм фаҗигале хисләр ташкынына күмә. Театр белече Р. Игламов болай дип яза: «...Бу спектакль беркемне дә битараф калдыра алмый. Ул йөрәкне авырттыра, күптәнге һәм әле суынып та өлгермәгән хатирәләрне яңарта, анда кешелек өчен тирән кайгыру хисе, ватаныбыз тарихы гелән үзгәреп тормас дигән өмет тә бар» [Игламов, 1987, с. 5].

Шуның белән бергә, режиссер М. Сәлимҗанов спектакльне төрле хисләр, нюанслар белән баета. Анда юмор да җитәрлек. Татар театры «йолдызлары» Р. Таҗетдинов (Мирвәли) һәм А. Гайнуллина (Шәмсегаян) башкаруындагы лирик күренешләр тамашачыны бик нык тәэсирләндерә. А. Миллер юкка гына: « Кырыс фаҗигале гыйбрәтле хикәя тукымасындагы төсләр байлыгы – Марсель Сәлимҗановның спектаклен мин шундый итеп күрәм», – дип язмады [Миллер, 1987, с. 8].

А. Гыйләҗев прозасына Камал театры яңадан 2004 елда мөрәҗәгать итә. Бу – театр тормышында шактый катлаулы чор. Озак еллар театрның сәнгать җитәкчесе булып торган, коллективның тирән ихтирамын яулаган Марсель Сәлимҗанов вафат була. Тулы бер дәвер тарихка китә. Г. Камал театры да юллар чатында кала. Яңа исемнәр, эшкә иҗади якын килүче талантлы шәхесләр, сәнгатьтә лидерлар таләп ителә. Яшь режиссура мәсьәләсе аеруча кискен куела. Һәм, әлбәттә, әдәби материалның сыйфатына игътибар зур була. Яңа шартларда театрга планканы һич кенә дә түбән төшерергә ярамый.

А. Гыйләҗевнең «Яра» повестен улы М. Гыйләҗев сәхнәләштерә. Яшь режиссер, ул вакытта Россия театр сәнгате академиясенең өченче курс студенты Рамил Фазлыевның әсәрне сәхнәгә куюы үзенә күрә бер иҗади имтихан тотуга тиң була. Ул театрның сәнгать җитәкчесе Ф. Бикчәнтәев җитәкчелегендә заманча, җитди, тирән мәгънәле спектакль тудыра.

Барлык күренешләр диярлек сугышта бердәнбер улларын югалткан Сөләйман белән Зөләйханың ишегалдында бара. Пространство мәсьәләсен шулай хәл итү үзе үк картларны беренче планга чыгара,

аларның образларын масштаблы итә, символик гомумиләштерү мәгънәсе сала. Карт белән карчыкның ихлас һәм тирән хисләре, рухи кичерешләре һәм тискәрләшеп өметләнүләре спектакльнең лейтмотивына, куелышның хаклыгын билгеләүче камертонга әйләнә. Н. Әюпов һәм А. Гайнуллина уены гаҗәеп нәзакәтле, зур ышандыру көченә ия. Аларның олы кайгысына беркем дә битараф кала алмый. Иң авыр сынауларны узган, тормыштагы гади генә шатлык-куанычларның да бәһасен белгән бөтен бер буын күз алдына килеп баса.

Яшь артистлар да якты, истә калырлык образлар тудыралар: И. Хәйруллин – Шәкүр, Л. Рәхимова – Зәйтүнә, Ф. Җиһаншин Габдулла ролендә. Стилистикасы һәм рухы ягыннан спектакль туксанынчы елларда зур уңыш казанган «Бичура»ны хәтерләтә. Хәтта геройлар да, асылда, шул ук. Бары бераз өлкәнрәк һәм башка тарихи шартларда. Шул ук композиция – күршеләр булып яшәүче ике пар картлар, аларның шатлыклары һәм кайгылары, фәлсәфи уйланулары һәм рухи кичерешләре. Шул ук темалар: сугышның мәңге төзәлмәс яралары (сугышта ирен һәм бөтен балаларын югалткан тиле Күрше хатынын искә төшерик), ялгыз картлык ачысы, ятим калган гаилә учагы. Шул ук образлар системасы (кыйшайган капка, өрәк тавышлары), курку хисе һәм үзәк өзгеч сагыш [Габаши, 2004, с. 2].

2018 юбилей елында театр кабат А. Гыйләҗев иҗатына мөрәҗәгать итте. «Әтәч менгән читәнгә» повестен режиссер Ф. Бикчәнтәев һәм И. Мөхәммәтгалиев бергәләп сәхнәләштерде. Куелыш импровизация атмосферасы, күмәк иҗат рухы, якты җирсү хисе белән аерылып тора. Матбугатта язылганча: «Әтәч менгән читәнгә» – балачактагы шатлыклы рәсемне хәтерләтә торган спектакль: бөтен төсләр дә ачык, матур булып тоела, ахыры яхшы бетәсен дә аермачык беләсең. Фәрит Бикчәнтәев спектакльгә бераз ирония һәм хәтта сарказм кертеп җибәрсә дә, актерларны үз геройларына сокланырга өйрәтеп, филигран төгәллек белән эш иткән» [Мамаева, 2018, с. 7].

Күренекле татар проза остасы һәм драматург Аяз Гыйләҗев халкыбызның рухи мәдәниятенә бәяләп бетергесез зур өлеш кертте. Ул гаять бай мәдәни мирас калдырды: биш роман, егермеләп повесть, кырыктан артык пьеса, әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, иҗтимагый-сәяси темаларга бихисап мәкаләләр, күпсанлы хикәяләр һәм юморескалар. Аның әсәрләре бүген дә игътибар үзәгендә һәм театр коллективларын яңадан-яңа спектакльләр куярга рухландыра. Аларны Татарстанда да, аннан читтә дә бик яратып карыйлар.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1957 – 1990). Казань, 2002. С. 55.

*Габаши А.* Рана заживет // Время и деньги. 2004. 27 февр.

*Гимранова Д.А.* Гилязов «Осенние ветры» // Татарский государственный театр имени Галиаскара Камала. Сто лет. В двух томах. 1 т. Спектакли. Казань: Заман; Татар. кн. изд-во, 2009. С. 301 – 302.

*Горова Л.* «Театр имени Г.Камала на столичной сцене» (гастрольная афиша) // «Московская правда» 1970. 14 июня.

*Игламов Р.М.* Возвращение. Советская Татария. 1987. 13 августа.

*Кашшаф Г.* Драматург һәм режиссер // Социалистик Татарстан. 1961. 30 май.

*Мамаева Т.* Петухи и куры, разные фигуры Источник: https://realnoevremya.ru/articles/82991-v-kamalovskom-postavili-povest-ayaza-gilyazova

*Миллер А.* О чём не расскажет притча // Вечерняя Казань. 1987. 4 сент.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 72

*З.А. Камалова*

# ТАТАРСТАНДА ЯҢАРТЫЛАСЫ ПАРКЛАРДА МИЛЛИ МОХИТ ТУДЫРУ ЫСУЛЛАРЫ

В статье рассматриваются способы сохранения и восстановления татарского национального стиля при оформлении парков и скверов и ландшафтной архитектуры РТ.

**Ключевые слова:** национальный стиль, ландшафтная архитектура, орнамент, парковые зоны и скверы, историческая значимость.

The article discusses ways to preserve and restore the Tatar national style when designing parks and squares and landscape architecture of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** national style, landscape architecture, ornament, park areas and squares, historical significance.

Милләтнең саклануы телгә турыдан-туры бәйләнгән. Чөнки гыйлем алу, аңны үстерү, дөньяны танып белү һәм аралашу туган тел аша тормышка ашырыла. Тел бетсә – милләт бетә, халык бетә. Телебезне, димәк халкыбызны да саклау һәм үстерүнең яңа юллары һәм алымнары табыла, аларның берсе – югары уку йортларында татар телендә укыту, ул – бүгенге глобальләшү шартларында телне саклап калу һәм үстерүнең төп шарты һәм мөмкинлеге.

Татар халкының мең елларга сузылган тормыш тәҗрибәсе, уйлары, гадәтләре, кешене шәхес итүче сыйфатлары аның телендә, образлы сөйләмдә, мәкаль-әйтемнәрдә, җыр һәм экиятләрдә чагылыш таба. Шуңа күрә, ата-анасы татар булган балага татарча белү, уку мәҗбүри итеп каралырга тиеш. Татар теле – зур үсешкә ирешкән әдәби тел, фән, фәлсәфә, техника теле, абстракт фикерләрне тәфсилләүче тел. Югыйсә ул дөньякүләм әһәмияткә ия булган тел итеп саналмас иде. Гуманитар белем халкыбызның рухи үсешен тәэмин итсә, табигать һәм техник фәннәрне өйрәнү дөньяви үсешкә илтә. Гуманитар белем белән генә чикләнсәк, телебез җәмгыятьнең техник үсешен һәм алгарышын билгеләүче төп хуҗалык тармакларына керә алмыйча югалып бетәчәк. Ә техник белем бирүгә дә игътибарны юнәлтсәк, телебезгә фәнни төгәллек һәм логик төзеклек өстәлер, ул бүгенге һәм киләчәк буыннар өчен әһәмиятен тагын да арттырыр.

Төзелеш өлкәсенең милләт һәм тел яшәеше, саклануы белән бик тыгыз бәйләнештә торуы яхшы билгеле. Татарларда төзү эше борынгыдан килә. Бабаларыбыз яңа эраның беренче гасырларында ук Кытай, Урта Азия, Якын Көнчыгыш илләре белән бәйләнеш тоткан. Утрак тормыш алып барып, алар үз дәүләтләрен булдырганнар, Көнчыгыш Европада беренче булып чуен, тимер коярга өйрәнгәннәр, югары матди культурага ирешкәннәр. Борынгы кулъязмаларда (авторлары Ибне Рөстә, Ибне Фадлан, Истархи һ. б.) болгарның таш һәм

агачтан эшләнгән зур мәчетләре булуы әйтелә. Ибне Хаукәл язганча, болгарлар Итил осталарыннан яхшырак төзегәннәр. Якут Ибне Абдеме язуынча, биредә йортлар – нараттан, ныгытма диварлары имәннән салынган булган [Камалова, 2017].

Паркларда һәм скверларда милли мохит тудыру, иң элек, милли орнаментларны барлауга һәм куллану мөмкинлекләрен ачыклауга барып тоташа. Татар халык орнаменты якты, ачык төсләрне үзенә җыйган үзенчәлекле һәм нәфис халык иҗаты белән таныштыра бит. «Орнамент» сүзе латин теленнән (ornamentum) кергән һәм «бизәк» дигән мәгънәгә ия. Татар халкының гүзәл орнаментлары күп гасырлар буе төрле әйберләрдә урын тапты: ювелир эшләнмәләрнең нәфис бизәкләрендә, тукымаларның бизәкле чигешләрендә, кабер ташларының кисеп-уеп ясалышында, баш киемнәрендә, төрле төстә мозаикалы күн аяк киемнәрендә, торак бизәкләрендә (1 нче рәсем).

Билгеле булганча, татар архитектурасында геометрик, зооморф, соляр (кояштан тарала торган нурлар рәвешендәге), чәчәкле мотивлар күзәтелә.



1 нче рәсем. Татар халык орнаментларының төрләре [Валеев, Валеева-Сулейманова, 2002]

Күптөрле татар орнаментлары һәм бизәкләре арасында геометрик орнамент шактый зур урын ала. Геометрик орнамент – геометрик фигуралар белән ясалган бизәк. Авыл торакларында, ювелир эшләнмәләрдә һәм тукыма бизәкләрендә киң кулланыла. Геометрик татар орнаментлары үзләренә генә хас тылсымы белән аерылып тора. Алар дулкыннарны, йөгерек дулкыннарның әйләнмәләрен, үрелмәләрнең, борылмаларның, йолдызларның-айның формаларын хәтерләтә.

Шулай ук соляр, ягъни кояштан тарала торган нурлар рәвешендәге бизәкләргә дә игътибар итәсе килә. Осталарны гел рухландырган, үзенә җәлеп иткән кояш дөньясы, кояш мотивлары барлык халыкларның сәнгать күренешләрендә киң таралган һәм төрлелеге белән аерыла.

Зооморф төркемнән кошлар сурәте белән бизәкләү зур әһәмияткә ия. Кош татар аңына борынгыдан кояш һәм яктылык символы булып сеңдерелгән. Кошлар Идел Болгарстаны төрки кабиләләре тарафыннан изгеләштерелгән, болгарның декоратив-гамәли сәнгать әйберләрен кош рәсеме белән бизәкләү шуннан килә [Валеев, Валеева-Сулейманова, 2002; Валеев, 1984; Валеев, 1969].

Күп очракта татарларның милли орнаментлары төрле чәчәкләрнең стильләштерелгән рәсемнәреннән эшләнә. Алар ләлә, дәлия, гөлҗимеш мотивларында була (2 нче рәсем).

Төзелеш өлкәсендә татарның милли стильләре югала бара, заманча минимальлек принциплары, югары технологик материаллар



2 нче рәсем. Татар орнаментларының мотивлары



3 нче рәсем. Казан шәһәрендә урнашкан Әҗем мәчетендә татар орнаментының кулланылышы



4 нче рәсем. Авыл архитектурасында татар орнаментларының кулланылышы

аларны акрынлап кысрыклап чыгара. Милләтебезнең камил, искиткеч матур стилен бары авылларда яки мәчетләрдә генә күрергә кала (3 нче рәсем).

Татарларның гореф-гадәтләре, бизәкләре – әби-бабаларыбыздан киләчәк буыннарга мирас итеп калдырылган байлык бит алар [Камалова, Вәлиев, Гыйльманов, 2018; Камалова, Гатауллина, 2018, с. 9; Вәлиева, Камалова, 2017; Камалова, Гатауллина, 2018, с. 390]. КДАТУның татар бүлегендә укыган студентлар, аларның педагоглары татар тарихына кагылышлы һәр бизәкне саклауны кайгырту ягында.

Гореф-йолаларны саклап, татар халкына гына хас бизәкләрне кулланып, милли мохит тудыруның юнәлешләрен һәм мөмкинлекләрен карап үтик (4 нче рәсем).

Туган телен, бабаларыннан килгән гореф-гадәтләрен кадерләгән халык кадерле булыр. Шуңа да белемгә, үсешкә омтылучы барлык халыклар да туган телләрен, тарихларын өйрәнүгә һәм үстерүгә нык игътибар бирәләр. Димәк, безгә дә, куелган максатларга ирешү өчен, татар халкының телен, тарихын, милли бизәкләрен саклау, үстерү юлларын табарга кирәк. Киләчәктә аларны заманча парклар яңартылганда куллану актуаль һәм бик тә мөһим. Зур максатларга ирешергә телибез икән, беренче чиратта эшне фикерләүдән һәм дөрес юл сайлаудан башларга кирәк. Милли мохит тудыру, телне, милләтне саклау кебек идеяләр белән янып яшәгән яңа буын төзүчеләр, яшь белгечләр әзерләү – моның, һичшиксез, дөрес юнәлеше.

Телне саклау дибез – бу гамәл бит
Башлана тик безнең уйлардан.
Куйган максатларга ирешергә
Таяныч аласы кайлардан?
Кемнәр әзер шушы изге эштә
Безгә юлдаш булып барырга?

Кемнәр генә ярдәм итәр безгә
Милли рухны саклап калырга?
Кемнәр йөрер газиз халкым диеп?
Кемнәр саклар милли мохитне?
Нинди киләчәкләр көтә безне
Татар булып кала алмасак?
А. Бикбов, 5ПГ09 төркеме студенты

Әгәр киләчәктә дә үзебезнең алдынгы позицияләрне саклап, Татарстанга туристларның күпләп килүен телибез икән, әлеге проблеманы хәл итү республикабыз төзүчеләре һәм архитекторларының игътибар үзәгендә булырга тиеш. Алдынгы Көнбатыш илләре тәҗрибәсен куллану белән берррәттән, гореф-гадәтләрне, бары безгә хас стильне саклап калу өстендә эшләү мәслихәт, чөнки тарихы булмаган халыкның – киләчәге дә булмый, диләр бит. Киләчәк буыннарга күрсәтерлек мирас калдырырга кирәк. Бу – безнең төп бурычыбыз. Ә инде төп максат  туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, төзелеш өлкәсе аша йогынты ясап, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү [Камалова, Бикбов, 201].

Традицион сәнгать үсеше процессларын, алардагы чимал, демографик, дөньяга караш һәм башка фактларга бәйле күренешләрне өйрәнү бу өлкәдә бернинди дә очраклы элементлар булмавын раслады. Бизәлеш өчен сайланган образларда халыкның тарихи хәтере чагылыш таба (5 нче рәсем).

Киләчәктә дә милләт булып сакланып калу өчен, татар халкы бүген өч алтын баганага таянырга тиеш: алар – үз дәүләтең, үз динең һәм үз телең. Дин турында аеруча басым ясап әйтәсе килә, чөнки мең ел буе ислам дине татар халкы белән янәшә, аны саклап бара. Татар халкы һәрвакыт хәдисләргә җитди караган, һәр өйдә шәмаилләр түргә яки иң кадерле урынга элеп куелган. Безнең меңьеллык данлы тарихыбыз, шушы көннәргә хәтле килеп җиткән әхлагыбыз, татарның тәртипле яшәү рәвеше – барысы да исламнан. «Дине барның киләчәге бар» дип юкка гына әйтмиләр (6 нчы рәсем).



5 нче рәсем. Бөек Болгарның таш плитәләрендә татар орнаментлары кулланылышы

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында, Казан шәһәрендә милли мохит тудыру турында сүз кузгату зарур. Шушы эшчәнлекнең бер юнәлешен тәшкил иткән милли мохит тудыручы парклар, ял итү зоналарын булдыру юлларын карап узыйк.

Дөньяда иң беренче милли парк – «Йеллоустоун» – Америка Кушма



6 нчы рәсем. Шәмаилләрдә татар орнаментларының кулланылыш

Штатларында 1872 елда барлыкка килгән. 2015 елга Россиядә 49 милли парк булса, Татарстанда алар бармак белән генә санарлык. Мәсәлән, Татарстанда «Түбән Кама» милли паркы 1991 елда оеша. Аның табигатен, мәһабәт имәннәрен, изге чишмәләрен рәссам И.И. Шишкин үзенең мәшһүр картиналарында тасвирлаган.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы үзенең тотрыклы үсешен дәвам итә, күп кенә социаль-икътисади күрсәткечләр буенча илдә алдынгылар сафында тора. Әйләнә-тирә мохитне кайгырту юнәлешендә Татарстанда игълан ителгән Парклар һәм скверлар елы (2015) шактый күп уңай үзгәрешләр кертте.

«Безнең төп максат – дөнья тәҗрибәсен һәм шәһәрдә яшәүчеләрнең ихтыяҗларын исәпкә алып, ял зонасын яшелләндерү һәм төзекләндерү генә түгел, аны кызыклы һәм уңайлы да итү» дигән сүзләрне тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Куляжев әйтә. Без шул сүзләргә өстәп кызыклы һәм милли мохитле ял зонасы тудыру идеясен тәкъдим итәбез.

Татарстан Республикасында хәзерге вакытта паркларны массакүләм төзекләндерү эшләре алып барыла. Шуңа күрә хөкүмәт тарафыннан паркларны, скверларны үстерү программасы барланды.

Әлеге программаның төп бурычы халыкны яңа әзер проектлау, төзекләндерү принциплары белән таныштыру гына түгел, ә бу проектларга экспертларны, энтузиаст-белгечләрне, халыкны да җәлеп итү. Программаны популярлаштыру өчен интернет челтәрендә сайт булдырылган (http://park.tatar). Монда архитекторлар үзләренең паркларга һәм скверларга кагылышлы проектларының эскизларын куялар, ә инде экспертлар һәм Татарстан шәһәрләрендә яшәүче һәр кеше үзенең теләкләрен белдереп, проектларны камилләштерүдә катнаша ала. Соңгы елларда башкарылган эшләр уңышлы нәтиҗәләрен бирде, алар республикабыз архитекторларының кызыклы идеяләре белән тагын да тулыландырылды. Татарстан Республикасында 2018 елга 9 ял итү урыны ачылды. Алар арасында «Комсомолец» (Казан), «Тарсус» (Азнакай), «Иске мәйдан» (Алабуга) парклары, Әпсәләмов урамында урнашкан бульвар (Казан), Совет мәйданы урамында урнашкан бульвар (Мамадыш) һ. б. бар.

Бүгенге көнгә Татарстан Республикасында 49 ял итү урыны булдырылган. Узган ел Татарстанда онлайн-сораштыру ярдәмендә

кешеләр 2019–2022 елларда төзеләчәк урыннарны сайладылар. Республикада төзекләндерүне көткән ял итү урыннарының саны 200 дән артты. Шуларның 49 ы 2019 елда ясалачак яки төзекләндереләчәк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов проектларны гамәлгә ашыруга республика бюджетыннан акча бүлеп бирде. Шуңа күрә 2019 елда конкурста җиңгән һәр проект гамәлгә ашырылачак, әмма, кызганычка каршы, төзелгән, яңартылачак һәм төзеләчәк ял урыннарында татар мохите тудыручы бер генә проект та юк. Шуны истә тотып, эшләнелә торган проектларга милли мохит юнәлешен дә кертүне алга сөрәбез. Әлеге планлаштырылган паркларны реконструкцияләү проекты нигезендә безнең тәкъдимнәрне чынга ашыру бик нәтиҗәле булыр иде.

Уңайлы милли мохит тудыручы паркларның генпланда ясалган формасы татар милли бизәге рәвешендә булса, Татарстанда яшәүче халык өчен горурлык, ә инде Казан шәһәре белән танышырга килгән туристларның, һичшиксез, игътибарын җәлеп итәр иде. Күргәнебезчә, татар стилендә генплан булдыру авырлык тудырмый, ә кызыксыну уята (7 нче рәсем).

Бүгенге көндә парклар һәм скверларда нинди генә формадагы чәчәк клумбалары очрамый. Ни өчен аларны да татар орнаментларын кулланып ясамаска?! Чәчәкләрдән, татар милли төсләрен кулланып, гаҗәеп матур татар бизәкләре эшләп була. Ә 2015 елгы программа нигезендә төзелгән паркларда бүген чәчәкләр ярдәмендә милли мохит тудырырга мөмкин. Парк урнашкан территориядә яшел зоналарны, милли бизәкләр кулланып, чәчәк түтәлләре белән бизәргә кирәк. Бу ысул төрле илләрдә бик күптәннән кулланыла. Бу эш республикада ландшафт архитекторлары ярдәме белән башкарыла ала (8 нче рәсем).

Паркка керү юлы якында урнашкан тукталышлардан башлана. Бүгенге көндә тукталышларны бизәү дә гадәткә кертелергә тиеш. Күпләр килешер: әлеге тенденция татар халкы бизәкләрен танып белергә ярдәм итәр, шулай ук үзенчәлекле сокландыргыч объект булыр иде. Тукталыш корылмаларының ян-як пыялаларын үзгәртү дә шуңа кирә. Чөнки тукталышлар – кешеләр өчен көтү урыны гына түгел, ә мәгълүмат чыганагы да. Мәгълүматны чагылдыручы интерактив



7 нче рәсем. Татар милли бизәге рәвешендә ясалган генплан



8 нче рәсем. Яшел зоналарның татар стилендә чәчәк түтәлләре белән бизәлеше

экраннар татар халкына хас бизәкләр белән бизәлсә, Татарстанга килгән туристларның игътибарын җәлеп итәр, татар халкына үз тарихи-мәдәни мирасы белән горурланырга тагын бер сәбәп булыр иде (9 нчы рәсем).

Архитектура элементы буларак паркларда урнаштырылган эскәмияләрне татар орнаментын кулланып бизәү бүгенге көндә шулай ук бик актуаль. Игътибарыбызны урамнардагы эскәмияләргә юнәлтик. Аларда утырып ял итүчеләр дә күп. Эскәмияләрне эшләгәндә нинди дә булса татар бизәкләре кулланылса, халыкның игътибарыннан читтә калмаслар иде. Андый эскәмияләрне, татар милли бизәкләрен кулланып, агачтан яки тимердән коеп ясау мәслихәт (10 нчы рәсем).



9 нчы рәсем. Тукталышларны бизәү буенча тәкъдимнәр

Бүгенге көндә паркларда сәхнә урнаштыру популяр. Төрле бәйрәмнәрдә паркларга ял итәргә кеше аеруча күп килә, аларда төрле милли бәйрәмнәр дә үткәрелә. Сәхнәләрдә дә бернинди дә милли рух чагылмый. Сәхнә бизәлешендә безнең халкыбызга хас булган бизәкләрне «архитектур фантазия» рәвешендә эшләргә тәкъдим итәр идек.

Кайбер паркларда җир тигез булмаганлыктан, бер җирдән икенче җиргә күчеп йөрү өчен өстәмә баскычлар, күперләр урнаштыру сорала. Бүгенге көндә тимердән коеп ясалган элементларны милли бизәк төшереп ясау авырлык тудырмый, ә нәтиҗәдә паркның эстетик үзенчәлеге арта.



10 нчы рәсем. Эскәмияләрне милли стиль кулланып яңарту варианты

Тимердән ясалган җиһазларга да зур игътибар бирәсе килә. Элек татарлар өй түренә тотылган койманың өске өлешен матур итеп челтәрләп эшләгәннәр. Түр тәрәзә каршына орнаментлар уеп эшләнгән мондый рәшәткәләр кую Көнчыгыш халыкларының гореф-гадәтләренә барып тоташа. Урам буе коймаларының тәрәзәләр турысын челтәрле рәшәткәләр белән бизәү – татарларга гына хас күренеш, мондый каралтылар татар авылларына милли үзенчәлек биреп тора. Челтәрле рәшәткәләрне халык бик матур итеп, бизәкләп ясарга тырышкан. Рәшәткә челтәрләренең үрнәкләре төрле, алар халыкның фантазиягә бай

булуын күрсәтеп тора. Рәшәткәләрне халык, тәрәзә яңакларына һәм йортның фронтонына туры китереп, ачык төсләргә буяган. Бүгенге көндә дә шундый бизәкләү эшләре алып барыла. Көнкүрешкә агачка караганда чыдамлырак материаллар керү белән, койма рәшәткәләр бетә бара. Шуңа күрә агачтан түгел, ә тимер коймалар кую мәслихәт. Алар паркларда да кулланылыш таба ала (11 нче рәсем).

Кызганычка каршы, бүгенге көндә Россиядә төзелә торган объектлар күбесенчә типик рәвеш ала. Хәтта кафе, рестораннар – барысы да бертөрле, Америка Кушма Штатларындагы яки бүтән чит илләрдәге ял итү урыннарына охшатып ясала. Аларны паркларда да очратырга мөмкин (12 нче рәсем).



11 рәсем. Авторлары: Б.Р. Гыйлманов һәм Р.Г. Гыйлманов

Казан студентлар шәһәре дә бит әле. Милли мохиткә күндерүне нәкъ менә студент чактан ук башласак, яхшы булыр иде. Казанның барлык югары уку йортларында чит илләрдән һәм чит төбәкләрдән килгән студентлар да укый. Мәсәлән, КДАТУны гына алыйк. Студентларның яртысына якыны гына Татарстан Республикасыннан. КДАТУда татар стилен тудыру өчен университет каршындагы яңа скверда эскәмияләр, клумбалар һәм милли арт-объектлар урнаштырырга мөмкинлек бар. Университет территориясендә урнашкан паркны үзгәртүдән башлап, милли мохит тудыру идеясен барлап, татар бүлегендә укучы студентлар «70 нче Халыкара архитектура һәм төзелеш проблемалары» дигән конференциядә үзләренең тәкъдимнәре белән чыгыш ясадылар.

Студентлар паркларда булдырылачак эскәмияләрне, яктырту приборларын, коймаларны, таганнарны үзгәртүгә кыю тәкъдимнәр керттеләр, тыңлаучыларда бу мөһим проблемага карата кызыксыну уяттылар.

КДАТУның беренче һәм икенче корпуслары арасында урнашкан мәйданчык объект буларак каралды. Ял итү урынына яңа үзгәрешләр кертүдән кала, булганнарын яңарту эшләре башкарылды. Шуларның берсе – агач өслекле утыргычларда халкыбызның милли бизәкләрен куллану (13 нче рәсем).

Күргәнебезчә, бер эскәмияне генә дә төрле татар милли орнаментларын кулланып эшләп була, мондый вариантлар эстетик яктан матур һәм зәвыклы килеп чыга.





12 рәсем. Милли элементлар кертеп эшләнгән павильон





13 нче рәсем. Агач өслекле утыргычларда милли бизәкләрне куллану вариантлары



14 нче рәсем. Татар стилен кулланып эшләнгән койма



15 нче рәсем. Sketchup программасында эшләнгән, милли мохит тудыручы ял итү зоналары варианты



16 нчы рәсем. Sketchup программасында таганнар кулланып эшләнгән, милли мохит тудыручы ял итү зоналары варианты

Үзгәртүләр кертү, милли мохитне саклап калу, киләчәк буында татар мәдәниятенә мәхәббәт уяту чаралары күп. Шуларның тагын берсе – паркны уратып алган коймаларны татар стилендә эшләү (14 нче рәсем).

Шулай ук паркның капкасын орнаментлар кулланып эшләү вариантлары да тәкъдим ителде.

Яңарту эшләреннән кала, КДАТУ территориясендә яки Татарстан Республикасының төрле районнарында төзелә торган ял итү зоналары өчен татар милли мохитен чагылдырган вариантлар Sketchup программасында булдырылды. Бу проект заманча һәм шул ук вакытта милләтнең бай тарихка ия булуын истә тота. Генпланда парк татар милли чәчәк мотивларын кулланып эшләнгән.

Бу кечкенә ял итү урынында татар милләтенә хас бизәкләрнең югалмавын гына түгел, ә киресенчә, паркларның яңа тормыш белән яшәвен күрергә мөмкин. Бу парк заманча матур, ә иң мөһиме – мәгънәле. Паркларда, кафелар каршында мондый ял зоналары шәһәргә аерым заманча милли төс бирер иде (15 нче рәсем).

Бүгенге көндә парклар төзегәндә популяр булган таганнар проекты да студентлар белән бергәләп башкарылды. Яңа архитектур идеяләрне рәсемдә күрсәтелгәнчә башкару ял итү урыннарын эстетик яктан да, инженерлык ягыннан да кызыклы итә, дөньяви яңарыш кертә (16 нчы рәсем).

Проектлар уңышлы булып, әлеге эш бу урында тукталып калмады. КДАТУ студентлары республикабызда яңартыласы паркларга татар милли стилен кертеп җибәрү өстендә эшлиләр. Шәһәр мохитенә, паркларга милли татар

стилен кертергә, һәм шул ук вакытта карап торышка гади, шәһәрдә яшәүчеләргә уңайлы тирәлек тудырырга кирәк. Шуңа күрә массакүләм мәгълүмат чараларында булган проектларны тулыландыру эшләре алып барылды.

Казан шәһәренең паркларына һәм скверларына күз салыйк. Калабыз яшеллек «йортлары»на бай, алар нинди генә стильдә эшләнмәгән! Тик татар милли стиле чагылышы гына юк диярлек. Мәсәлән, күпләрнең яраткан урыны – Горки-Әмәт паркы. Ул җирдә урман эченә кереп китеп, югалып була. Шул вакытта үзеңне шәһәрдә түгел, ә кайдадыр читтә – Татарстанның иң матур җирләренең берсендә дип хис итәсең. Саф һава, кошлар сайравы, яфраклар шаулавы балачакка илтә. Ләкин шуңа да карамастан, үзгәртерлек әйберләр юк түгел. Парктагы буш мәйданчыкларны чәчәк түтәлләре белән бизәп, милли бизәлеш белән тулылындырырга була (17 нче рәсем).

Ял итү зоналарында милли мохит тудыру – катлаулы мәсьәлә. Бүгенге көндә паркларны яңарту программалары тикшерелә. Казан шәһәрендә бу программада җиңгән проектларны карап узыйк. Алар арасында «Имәнлек» урманы янында урнашкан мәйданчык кызыксыну уята. Проектлау территориясе Идел буе районында, «Имәнлек» урман паркы һәм Дубравная урамы арасында урнашкан. Архитектур яктан генплан табигатькә якын мотивларда башкарылган. Архитектур формалар һәм павильоннар табигать күренешеннән алынган күп катламлылык образын искә төшерә. Бүгенге көндә заманча архитектурада түбәгә эленгән таганнар куллану популяр. Ут белән яктыртылган таганнарда татар орнаментларын куллану бик отышлы вариант була ала (18 нче рәсем).



17 нче рәсем. Горки-Әмәт паркын яңартуга тәкъдим



18 нче рәсем. «Имәнлек» паркында төзеләчәк түбәгә эленгән таганнарны куллану тәкъдиме

Хәзер паркларда, җәяүлеләргә уңайлы булсын дип, брусчатка җәю гаять актуаль. Бу эшләрдә дә татар милли стилен тудырып була. Мисалга, гади брусчатканы ләлә чәчәген хәтерләткән орнамент белән бизәүне карап узыйк (19 нчы рәсем). Парк юлларын



19 нчы рәсем. Брусчатканы милли стильдә куллану варианты



20 нче рәсем. Эскәмия модельләрен татар орнаментларын кулланып эшләү вариантлары



21 нче рәсем. «Revit» программасында эшләнгән, милли мохит тудыручы эскәмияләрнең 3D моделе

яңартуда мондый үзгәрешләр, һичшиксез, Татарстан Республикасына килгән туристларда, Казан шәһәрендә яшәүче кешеләрдә кызыксыну уятачак.

Архитекторларыбыз ярдәме белән төрле эскәмияләр модельләрен татар милли стилен кулланып эшләү вариантларын 20 нче, 21 нче рәсемнәрдә күзәтеп була.

Хәтта «Имәнлек» паркында урнаштырылачак тимер-бетоннан ясалган хәрәкәт чикләгечләрендә дә (22 нче рәсем) татар орнаментын кулланырга мөмкин.

Әлеге максатка ирешү өчен, КДАТУда татар телендә белгечләр әзерләү – бик дөрес һәм кирәкле адым. Студентларны биредә татар телендә укытудан тыш, алар белән республикабызда милли мохит тудыру һәм гамәлгә ашыру буенча фәнни-эзләнү эшләре алып барыла. Төзүчеләр күзлегеннән куелган максатларны ничек үтәп була? Бу сорауга аларның үз фикерләре һәм тәкъдимнәре бар. Аларның һәрберсе уникаль, кызыклы һәм игътибарга лаек.

Татар мохитендә милли тәрбия алып, татарча укып үскән студентлар кулында халкыбызның, республикабызның, милли татар стиленең киләчәге. Аларга бу юнәлештә эшләргә ярдәм итәргә, идеяләрен, уй-фикерләрен, планнарын чынга ашырыр өчен мөмкинлекләр тудырырга кирәк. Шул вакытта бу мәсьәлә, һичшиксез, чишелү юлын табар, ә безнең – әби-бабаларыбыз, халкыбыз алдында бурычыбыз үтәлер иде.

Техник фәннәрне татар телендә укытуны беренчеләрдән булып яңартып җибәргән һәм хәзер дә эзлекле дәвам иткән Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университеты 2016 елда татар телендә югары белем бирүгә 25 ел тулу уңаеннан үткәрелгән Халыкара фәнни-



22 нче рәсем. «Имәнлек» паркында урнаштырылачак тимер-бетон хәрәкәт чикләгечен татар орнаментын кулланып эшләү варианты

гамәли конференциядә ясалган бер чыгышта: «Киләчәктә, телебезне дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрү өчен, татар-инглиз мәктәпләре ачылыр, югары уку йортларында татар телендә укучы студентларның саны артыр, аларга престижлы фирмаларда, чит илләрдә практика үтәргә мөмкинлекләр ачылыр, татар – рус телендә тәрҗемә итү системасы камилләшер, Abby рус-татар тәрҗемәсен Гугл (Google) дәрәҗәсенә күтәрелер иде, – дип әйтелгән иде [Камалова, 2017, б. 74]. Соңгы көннәрдә Татарстанның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев ТАССР Югары Советы сайлануның 80 еллыгына багышланган республика җәмәгатьчелеге җыенында ясаган чыгышында да шушы хакта әйтте. Ул Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның бу идеяне хуплавын белдерде. Минтимер Шәрипович фикеренчә, «Янарыш» фонды катнашында заманча өч телдә – татар, рус, инглиз телләрендә укыта торган мәктәп төзергә кирәк. Балалар бакчасы да аның составына кертелергә тиеш.

Димәк, татар теленең көченә һәм киләчәгенә ышаныч, аны саклау һәм үстерү, алдынгы телләр сафына кертү, татарча тәгълим һәм югары белем бирү, рухи, матди һәм фәнни эшчәнлек алып бару дәвам итә. Татар телендә техник белгечләр әзерләү дә тукталмый, КДАТУда татар телендә укуларын дәвам итүче студентлар саны артачак. Бүгенге көндә КДАТУда студентлар өчен өч телдә белем алырга бөтен мөмкинлекләр тудырылган.

## Әдәбият

*Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С.* Декоративное оформление сельского жилища в казанском Поволжье. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 127 с.

*Валеев Ф.Х.* Народное декоративное искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 188 с.

*Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 203 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарстана. Казань: Татар, кн. изд-во, 2002. 104 с.

*Вәлиев А.И., Камалова З.А.* Казан шәһәрендәге хәзерге архитектура-төзелеш шартларында төзү материалларын куллану // Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991 – 2016 елларда). Казан: КДАТУ, 2017. Б. 176 – 181.

*Дьячков И.В., Арютина В.П., Камалова З.А.* Физико-химические и технологические аспекты получения железооксидных пигментов различных цветов из местного сырья // Вестник Волжского регионального отделения Российской академии архитектуры и строительных наук. Н. Новгород, 2000. № 4. С. 7 – 100.

*Дьячков И.В, Камалова З.А.* Железоокисные пигменты Республики Татарстан // Разведка и охрана недр. 1996. № 2.

*Камалова З.А.* Югары уку йортларында татар телендә укыту – телне саклап калуның төп шарты һәм мөмкинлеге // Татар телендә югары техник

белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 елларда). Казан: КДАТУ, 2017. Б. 69–74.

*Камалова З.А., Бикбов А.Р.* Казан үзәге биналарын милли орнаментлар белән бизәп, татар мохитен тудыру (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строителъства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 391.

*Камалова З.А., Вәлиев А.И., Гыйльманов Б.Р.* Бизәкләрдә халкым киләчәге (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 391.

*Камалова З.А., Гатауллина И.И.* Борынгы бизәкләрне хәзерге заман орнаментлары белән берләштерү (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 390.

*Камалова З.А., Гатауллина И.И.* Эволюция роста татарской архитектуры и производства строительных материалов (тезис) // Программа 70-ой международной научной конференции по проблемам архитектуры и строительства. Казань: КГАСУ, 2018. С. 9.

*Камалова З.А., Рәхимов Р.З., Шакирҗанов Р.Ә.* Төзү материаллары: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Новое знание, 2012. 312 б.

*Халит Н.Х., Альменова-Халит Н.Н.* Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд- во, 2013. 351 с.

*Халит Н.Х., Альменова-Халит Н.Н.* Стили и формы татарской архитектуры Казани середины второй трети XVIII – начала XX в.: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 391 с.

***Камалова Заһирә Абдулла кызы,***
*техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт*
*архитектура-төзелеш университеты доценты*

УДК 81.2

***В.И. Рогачев,***
***Ф.С. Баязитова,***
***Р.Т. Сәфәров***

# ИДЕЛ БУЕНДАГЫ МОРДВА-ТАТАР ТЕЛ БАГЛАНЫШЛАРЫ ТУРЫНДА

В статье рассматриваются взаимоотношения мордовских народов (эрзян и мокшан) и татар Поволжья. Эти отношения широко проявляются на соответствующих языках (в общем словаре, в географических названиях, включая названия улиц, в официальных именах и прозвищах), а также в фольклоре и обычаях.

**Ключевые слова:** эрзянский язык, мокшанский язык, татарский язык, языковые контакты.

The article discusses the mutual relations of the Mordvin peoples (Erzyas and Mokshas) and the Tatars of the Volga region. Those relations are widely manifested in the respective languages (in the common vocabulary, in place names, incl. street names, in formal personal names and nicknames) as well as in the folklore and customs.

**Keywords:** Erzya language, Moksha language, Tatar language, language contact.

Фин-угор һәм төрки халыкларның Идел буенда бергә яши башлаулары йөзләрчә еллар белән исәпләнә. Бу тарих Идел буе Болгар дәүләтенең башлангыч чорларына барып тоташа: территориаль яктан аның составына мордва, мари, удмуртлар да керә. Әйтик, Болгар чоры эпитафик материаллары буенча, мордва кабиләләренең югары катлавы болгарлар белән туганлашкан, ике халык династияләре арасында никахлар теркәлгән, алар төрки аксөякләр белән хезмәттәшлек иткән.

XIII гасырда, Батыйның яулап алу походлары нәтиҗәсендә, Идел буена төрки күчмәннәрнең икенче дулкыны агыла. Алтын Урда дәүләте, олыс үзәкләре барлыкка килү – үзе бер зур тарих. Әмма ул эчке ызгыш-талашлар, кланнар арасындагы сугышлар, Куликово сугышында җиңелү, Алтын Урда дәүләтенең акрынлап көчсезләнүе белән тәмамлана. Басып алу яулары кими, татарларның бер өлеше йомышлылар катлавына күчеп, бик зур территорияләрдә үз гаиләләре белән төпләнеп яши башлый. Алар тыныч тормышта игенчелек, һөнәрчелек белән шөгыльләнә, ә патша хезмәтендәгеләр ил чикләрен саклый. Мордовия территориясенең Темников өязендәге мукшы җирләрендә йомышлы татар кенәзләре Еникиевлар, Мансыровлар, Колынчаковлар, Акчуриннар, Бибарсовлар, Енгалычевлар, Дәүләткилдиевлар, Бегишевлар, Ишиевлар, Кудашевларның һ. б. төпләнеп яшәүләре билгеле [к. Ишеев, Акчурин]. Төбәк үсешенә шактый зур йогынты ясаган йомышлы татарларның килеп чыгышы төрле. Кенәз Иван Васильевич тарафыннан 1539 елда кенәз Еникәй Тенишевка бирелгән грамотаны гына искә төшерик. Анда болай диелгән: «татар и тарханов, и башкирцов, и можарян, которые

живут в Темникове, судить и ведати их по старине, по том ж, как напеед того судил и ведал отец ево Тениш» [Два списка...].

Баштарак, Мәскәү кенәзләренең әмере белән, татар морзаларына хезмәтләре өчен мордва халкының бер өлеше генә ясак түләп торган. XVI гасырның икенче яртысыннан аларга, мәҗбүри хезмәт үтүне шарт итеп, ясак урынына крепостной крестьяннары (нигездә күчеп утырган руслар) белән бергә поместьелар бирелгән.

Борынгы мордва җирләрендә татарлар яшәгән башка эре торак пунктлар да булган. Мәсәлән, Нарручадь (хәзерге Наручат булса кирәк, Пенза өлкәсендә район үзәге). Төрле чыганакларда ул төрлечә атала – Мохши, Мухши (ягъни Мокша елгасы буендагы авыл) [Мокшин, с. 43]. Алда билгеләп үтелгәнчә, XV–XVI гасырларда – Алтын Урдадан соңгы чорда төрки халыкларны күчереп утырту аеруча интенсив төс ала. Бу вакытта Россия халыклары мәдәниятенә татарларның йогынтысы көчәя. Һәм бу телдә дә, анторпологиядә дә, йолаларда да сизелә. Рус телендә татар алынмаларының саны йөзләр белән исәпләнә.

Хәзерге Мордовия территориясендә татар халкы нигездә аның үзәк өлешендә (Ләмбрә һәм Ромодан районнары), шулай ук көнбатыш районнардагы (Инсар, Ельников, Торбеев, Темников) аерым авылларда таралып урнашкан. Җирле халык – мукшы һәм эрзялар мәдәниятенә татар йогынтысы бигрәк тә телдә, фольклорда һәм этнографиядә чагылыш тапкан. Мәсәлән, мордва телләрендә, лингвистлар фикеренчә, берничә йөз татар алынмасы бар. Моны күрү өчен хәтта белгеч булу да кирәк түгел. Кайбер алынмалар фонетик яктан шул дәрәҗәдә ассимиляцияләнгән һәм телгә ярашкан, хәтта мордваның үз сүзләре дип кабул ителә башлаган. Галимнәр фаразлавынча, аңа түбәндәге сүзләр дә керә: *эняльдомс* ‘инәлеп сорау’, *комоля* ‘колмак’, *кшумань* ‘керән’ (чувашизм булса кирәк), *кирмар(л)ав* ‘кырмавык’, миш. *кырмалау*, *юрт* ‘нигез; урын’, *сокор* ‘сукыр’, *ён* ‘як, юнь’, *ян* ‘сукмак’, *каршо* ‘каршы’, *пек* ‘бик’, *цёра* ‘угыл; ир-ат’, иск. татар. *чура*, *сумань* ‘чикмән, сыхман’ (чувашизм булса кирәк), *куяр* ‘кыяр’, *кендял* ‘кандала’, *куда* ‘кода’, *ярмак* ‘акча’, *эмеж* ‘яшелчә’, *ашо* ‘ак’, *адя* ‘әйдә’, миш. *адя*, *ава* ‘ана’ [Бутылов, с. 8].

Элеге лексик катлам белән янәшә эрзя телендә диалект характерындагы сүзләр дә бар. Алар – урам исемнәре, кушаматлар, топонимика. Мисал өчен, Мордовия Республикасының Большеберезниковск районы Косогоры авылында башка торак пунктларда билгеле булмаган төрки алынмаларны очратырга мөмкин. Бу – торак пунктның XVII гасыр башында – 1624 елга кадәр – күчеп утыручылар авылы буларак барлыкка килүе белән бәйле. Алатыр өязенең язу-теркәү кенәгәләрендә түбәндәге юллар бар: «Кергуды Новые по речке Семилее, Тапоснанского беляка, Верхосурского стана выставились из деревни из Старой Кергуды» [Гераклитов, с. 59]. Анда яшәүчеләр өлешчә татарлар тарафыннан үзләштерелгән җирләргә киләләр. Шулай итеп, безнең уйлавыбызча, эрзялар яңа урынга (хәзерге Ташто юрт (Иске урын) күчеп утырганда, аннан 5 км ераклыкта Ачакүл дигән татар авылы урнашкан була.

Халык саны ишәйгән саен, эрзя һәм татар авылларының аралары якынайганнан якыная барып, ике авыл бергә кушыла. Ачакүл үз атамасын саклап кала, әмма андагы татарлар, эрзя телендә үзләренең эзен калдырып, акрынлап ассимиляцияләнә. Бу очракта нигездә төрки чыгышлы топонимика татар авылының борынгылыгына ишарәли.

*Ачакүл атамасы үзе үк,* галимнәр фикеренчә, төрки телләргә барып тоташа: «Мөгаен, төрки *Ачык* ‘луг среди леса’ + *кул* ‘озеро’ сүзләреннән» [Цыганкин, с. 31]). Топоним башкача да аңлатыла: ике компонентлы сүз, беренче компоненты – *ача* татарча *ачы* ‘кислый, горький’ сүзеннән, икенчесе – татар һәм башкорт телләрендәге *күл* ‘озеро’ < гомумтөрки **köl* [ДТС, с. 313]. Шуңа охшаш исемле күлләрне Идел буенда, Уралда, Көнбатыш Себердә очратырга мөмкин. Мисал өчен, Башкортстанда – *Ачыкүл*, Чиләбе өлкәсендә – берничә *Ача-күл күле*, Томск өлкәсендә *Ачикүл* бар. Н.И. Шувалов, Ф.Г. Гарипова фикеренчә, күлләрнең атамасы төрки телләрдәге *ачы* ‘горький, соленый’ + *кул* ‘озеро’ сүзләренә барып тоташа [Шувалов, с. 24; Гарипова, с. 139].

Семилейка елгасының кушылдыгы булган *Авсад латко* инешенең исеме дә төрки-татар чыгышлы. *Авсад* – төрки тамырлы антропоним (*Әсәд* – төрки халыкларда киң таралган исем) [Цыганкин, с. 14]. *Эсаень чавома* (Эсай исемле кеше үтерелгән болын) топонимы да яңгырашы белән *Авсад* атамасына якын [Цыганкин, с. 416]. Моны раслап шуны әйтергә мөмкин: *Авсад, Эсай* топонимнары бер үк исемгә – *Әсәдкә барып тоташа,* татарларда ул күбрәк *Әсәдулла* формасында кулланылган һәм *Әсәдуллин, Әсәдуллаев* < гарәп. *ӑсӑд* + *Аллаһ* ‘Аллаһ арысланы’ фамилияләрендә сакланган. Көндәлек тормышта күп компонентлы исемнәр еш кына кыскартып әйтелгән: *Рамазан – Рамай, Салихҗан – Салай, Камалетдин – Камай* һ. б. Әйтик, *Әсәдулла Әсәй* формасында кулланылган, татар телендәге *Әсәев* фамилиясе шуннан килеп чыккан [Саттар-Мулилле, б. 317]. Косогорыда киң таралган *Осяев* фамилиясе татарлардагы *Әсәевкә асылда туры килә дип ышанып әйтергә мөмкин, һәм бер үк лексик рәттәге бу ике сүз* алда телгә алынган *Әсәйгә барып тоташа*.

*Аргашкэ вирь, Аргашкэ латко* (Ачакүл авылыннан көньяк-көнбатышка таба 3–3,5 км ераклыкта, Авсад инешенең югары агымында) топонимнарының табигате дә кызыклы. Бу топоним, мөгаен, түбәндәгечә барлыкка килгән: ф.-у. телләрендәге **ar, ara* ‘инеш; җыелган су, ермак’ + т *-га* һәм *-шка* топоформантлары яки *Аргашкин* (татар. *аргыш* ‘кәрван; юлдаш’) антропонимыннан [Цыганкин, с. 27). Санап үтелгән топонимика тулаем төрки, аерым алганда, татар теленә барып тоташа.

Төп Ачакүл (хәзер Косогоры авылының бер урамы) халкының этник килеп чыгышын билгеләгән башка фактлар да бар. XX гасырның 40–70 нче елларында авылда Татаркиннар гаиләсе вәкилләре яшәгән: *Татар Ваня,* аның бертуганнары *Татар Алеш, Татар Тюма,* аның балалары *Татар Алюк*, *Татар Коля*, шулай ук аларның туганы *Татар Оська* (ПМА, 1996). Бу авылда XX гасырның 50 нче елларына кадәр

әлеге гаиләнең башлыгы – *Бильмай кушаматлы кеше яшәгән* [ПМА, 2012]. Кушамат буларак, *бильмай* бәлки татар телендәге *белми,* диал. *белмәй* ‘не знает; не знающий человек’ сүзенә килеп тоташадыр. Мордовия мишәрләрендә *Бильмайның* түбәндәге тәрҗемәләре дә бар: *бил* ‘стан’, ‘кеше биле’, *маи* ‘яхшылап билен буган’, һәм шулай ук ‘өрәк маем’, ‘май ае’. Урам кушаматы буларак, *Бильмай* ‘белми торган кеше’ мәгънәсендә кулланылган булырга тиеш.

Косогоры авылының Ачакүл белән янәшә урнашкан югары очында Ефимкиннар яшәгән. Аларны урам исемнәре белән – *Бикаинь – Бикай Сидир, Бикай Ваня атя,* аның улларын һәм кызын *Бикай Ваня, Бикай Петра, Бикай Палю, Бикай Евдень,* туганнарын *Бикай Алюк дип атап йөрткәннәр* [ПМА, 2002]. Татар теленнннән русчага *бик* ‘очень’ дип тәрҗемә ителә. Әмма бу очракта без, мөгаен, башка сүз белән эш итәбездер. *Бикай* кушаматының яки урам исеменең килеп чыгышын ачыклау белән шөгыльләнгәндә, татар телендәге *би/бик/бәк* < төрки *beg* ‘бәк, кенәз, югары катлам вәкиле’ сүзенә мөрәҗәгать итәргә кирәк [ДТС, с. 91]. *Би/бик/бәк* вакытлар узу белән төрки хәрби аристократия терминнары буларак кулланыла башлаган, алар катнашында катлаулы кеше исемнәре барлыкка килгән [Саттар-Мулилле, б. 60]. *Бикай* дигән урам һәм нәсел-ыру исемен аңлатканда, кайбер этимологик нюансларны истән чыгарырга ярамый. Кеше исеме буларак *Бикай > би + кай: би* иске татар телендә катлау титулы булган, ә *-кай* – иркәләү төсмерле сүз ясагыч кушымча (суффикс). *Бийем* ‘каенана’, *биага* ‘каенага, иренең зур абыйсы’ һ. б. туганлык терминнары *би* сүзе кушылып ясалган [Баязитова, 2011, б. 243].

Әле тагын бик күп башка фактлар да әлеге авылда эрзя һәм татарлар арасындагы бәйләнешләр турында сөйли. 1970 елларда Косогорыда *Йалдаж исемле кеше яши. Кыяфәте белән чын-чынлап көньяк кешесе, кара тәнле, кап-кара чәчле.* Безнеңчә, әлеге урам исеме татарлардагы *Юлдаш* ‘спутник, попутчик’ дигән кеше исеменнән килеп чыккан [Саттар-Мулилле, б. 300]. *Юлдашев* фамилиясе татарлар арасында бүген дә киң таралган. Антропоним сыйфатында бу сүзне төрки телләрнең күбесендә очратырга мөмкин, чагыштыр татар, башкортта *Юлдаш,* төректә *Yoldaş,* казакъта *Жолдас* һ. б. Башка чыганакларда да *йалдаж* ‘попутчик’ шулай ук тәрҗемә ителә: Татарско-русский словарь (1966; 2007), Эрзянско-русский словарь (1949), Мокшанско-русский словарь (1949).

Әмма Косогорыда *йалдаж* сүзенең этимологиясен белмиләр. Югарыда телгә алынган *Йалдаж* шулай ук төрки тамырлы *Сарайкин* фамилиясен йөртә (татар *сарай* < төрки. *сарай* ‘дворец’) [ДТС, с. 488] (< фарс. *сарай* ‘дом, строение’ [Әхмәтьянов, б. 171]). Шунысын әйтергә кирәк, Сарайкин фамилиясе әлеге эрзя авылында шактый киң таралыш алган.

Косогорыда татарлардан кергән башка фамилияләр дә очрый. Шуларның берсе – *Сульдин.* Аны йөртүчеләрне *Масяйинь, Масяйинькань дигән нәсел-ыру урам исеме берләштерә. Сульдин* фамилиясенең

Сура елгасының югары агымы бассейнында очравын да ассызыклау зарур. Мордовиянең биш көнчыгыш районы, Ульяновск өлкәсе белән катнаш районнар, Пенза өлкәсенең ерак көнчыгышы да шунда карый. Биредә меңнән артык кеше шушы фамилияне йөртә. Аның аңлатмалары да күп. Әмма, безнең карашка, ул төрки-монгол телләрендәге *сульдэ* (төрки гаилә әләме) сүзенә барып тоташа, нәсел-ыру берләшмәсенең исеме, фамилия яисә урам исеме, кушамат буларак кулланыла ала. Кайбер чыганакларда *сульде, сульдэ* 'рух, яшәү көче' – монгол һәм төрки халыкларның мифологик күзаллауларында кешенең яшәү һәм рухи көче белән бәйләнгән җан мәгънәсендә йөри [Жуковская, с. 475]. Башка версияләр буенча, бу фамилия татар диалектларындагы *сулда* 'слева', *султыш* 'левша' сүзләреннән барлыкка килгән. Беренче тапкыр бу исем, әгәр ул *Сульдин* фамилиясенә мөнәсәбәтле икән, XVI гасырга карый: 1558 ел өчен «Түбән Новгород өязенең дозор китабы»нда Сулда Олексеев атлы мордва кешесе теркәлгән. Татар һәм мордваларның үзара мөнәсәбәтләрен исәпкә алып, *Сульдин* фамилиясенең татар теленә мөнәсәбәте бар дип раслый алабыз. Ә Косогорыда *Сульдиннарның борынгы ата-бабаларының татарлар булуы бик мөмкин. Эрзялар яшәгән башка регионнардан аермалы буларак, биредә традицион мордЭ телендәге лишме* сүзе урынына *айгыр* 'жеребец', *алаша* 'лошадь' кебек тюркизмнар ныклап тамыр җәйгән.

Мордовия Республикасында, аерым алганда Большеберезниковск районында, Ачакүл, Шөгер, Иске Найман, Рус Найманы кебек торак пунктларның булуы, Сура буендагы борынгы төбәктә халыклар төпләнеп утыру тарихының катлаулы характерда булуын һәм безнең позициянең дөреслеген беркадәр раслый.

Шунысын әйтергә кирәк, мәдәниятләрнең үзара йогынты ясашуы татар-мишәрләр телендә дә мордвалар лексикасының булуында күренә. Мәсәлән, мордва алынмалары көнбатыш (мишәр) сөйләшләрендә һәм урта диалектның мишәр диалекты йогынтысында барлыкка килгән сөйләшләрендә очрый. Татарлар һәм мордвалар арасындагы икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр бик күптән урнашкан. Билгеле булганча, татар-мишәрләр мордвалар төпләнеп утырган ареалда – Иделнең уң ярында аерым төркемнәр булып яшәгәннәр. Мордовиядә генә дә 80 нән артык мишәр авылы бар. Алар мордва һәм рус торак пунктлары чолганышында утыралар. Мордва телләрендәге төрки алынмалар арасында татар сүзләре беренче урынны били. Тикшеренүчеләр фикеренчә, алар мишәр диалекты үзенчәлекләренә ия. Ягъни мордва телләренә мишәрләр аша үтеп кергәннәр. Аларда ике йөздән артык төрки (мишәр) алынмасының кулланылышта булуы билгеле [Феоктистов, с. 334–337].

Алынмалар төрле. Косогорыда Ачакүл белән янәшә Кифтаевлар гаиләсе яши (*Кифтай Сема,* гаилә башлыгы, *Кифтай Анисия,* аның хатыны, аларның балалары *Кифтай Сергей, Кифтай Манька, Кифтай Вася, Кифтай Валя).* Шактый сирәк очрый торган *кифтай сүзенең табигате катлаулы.* Д.Б. Рамазанова фикеренчә, татар телендә

сөйләшкән мордва-каратайлар сөйләшендәге *кифтай сүзе мордва теленә барып тоташа*: мордМ *кефта, кифта;* мордЭ *кефта* ‘каенага, каене, иренең ир туганы’ [Рамазанова, с. 143].

Татар теленең мишәр диалектында диалектологлар мордва телләренннән кергән күпсанлы лексик берәмлекләрне теркәделәр [Махмутова, с. 152–159]: *мошко – киндер* ‘конопля’ (чагыштыр. мордМ *мушка* ‘волокно, тәрәшле сүс’, мордЭ *мушко* ‘волокно, киндер, тәрәшле сүс’; *мушко сэльге* ‘киндер сүсе’); *пәзи – киндер; киндер сүсе* ‘конопля, конопляное волокно, пакля’; *пәзи/пази/пизе пәҗи/пәзе/пәзи/пачы* ‘посконь’ (чагыштыр. мордМ *пазяй* ‘кудель, посконь’; мордЭ *пазе* шул ук); татар теленең пермь сөйләшендә *бәжи* (әдәби *баса)*, шул ук тамырга барып тоташа дип санала. Борынгы алынма буларак *пәҗи* сүзе *XIX – XX гасыр башы* татар шагыйрь һәм язучыларының әсәрләрендә дә очрый*: Киеп пәҗи кара күлмәк [-----] йөрерсең, и Җәмиләкәй (Г. Кандалый); Җирән бия камытының чөелдереге пәҗидән икән шул. Яңгыр сәбәпле бик бүртенгән дә, чишеп булмый* (Г. Ибраһимов). Чистай мишәрләре сөйләшендә *пәзи кәркеш* ‘киндер сүсеннән үрелгән чабата киндерәсе’ [БДСТ, 291].

Татар телендә мордва телләреннән кергән башка лексик алынмалар да кулланыла, мәсәлән, татар. *нәркәмәс – әрем* ‘полынь’, *кара нәркәмәс – кара әрем* ‘чернобыльник’, чагыштыр. морд. *нартемкс, нярьх- камаз* ‘кылган’ (чув. *нәркәмәш* ‘агу, мышьяк’); татар. *челги, цилге* ‘сыткы, бетчә’ < мордМ *цилге,* мордЭ *сильге* ‘бородавка’ [ТЗДС, б. 743]; *кәркеш* ‘чабата киндерәсе, бау’ < морд. *карькс* (< *карь* ‘чабата’), *-кс* – охшашлык яки алдан билгеләнүне белдерүче кушымча. Моннан: *карькс* ‘чабата киндерәсе’, соңрак ‘һәртөрле нечкә бау’. Татар әдәби телендә *киндерә* ‘оборы’, ә *бау* ‘бечевка’; *путмар* ‘йортның кухня өлешендә азык-төлек һәм савыт-саба саклау өчен киштәләре булган сәке; сәке яки ишек янындагы агач карават’ [ТЗДС, б. 544]. *Путмар* термины мордва телендә барлыкка килгән, *пут мар* / *путмар* татар теленең ләмбрә, кузнецск, хвалын, сергач сөйләшләрендә: *мич алды ягындагы сәке* ‘нары, устроенные напротив или наискосок от шестка печи, служащие кухонным столом для посуды’ [ТЗДС, б. 544].

Көнбатыш (мишәр) диалектындагы агач исемнәреннән *пизел* ‘миләш’ тә – алынма сүз. Ул темников, ләмбрә, кузнецск, карсун, сергач сөйләшләрендә теркәлгән, чистай сөйләшендә (Елховой авылы) өлкән яшьтәгеләр сөйләмендә очрый (2003 елгы экспедиция материаллары, Ф. Баязитова). Мари теленең төньяк-көнбатыш шивәсендә *пизли, пызли* – татар теленең мишәр диалектында *пизел* [Казанцев, с. 192].

Татар теленә мордва телләреннән кергән кайбер алынмаларның башкорт һәм чуваш телләрендә дә параллельләре бар: татар. *баса* – башк. *бада,* чув. *пуса* ‘киндер, баса’ < морд. *пазяй, пазе* ‘тәрәшле сүс, баса’; татар., башк. *кәркеш,* чув. *каркаш* ‘бау, чабата киндерәсе’ < морд. *карь, карькс* ‘чабата’; *тәтә* ‘ата’, башк. *тәтәй* ‘зур апа, чув. *тете* ‘зур абый’ морд. *тетя, тетей* ‘ата’ һ. б. [Насипов, с. 214].

Мордва алынмалары арасында исемнән ясалган фигыльләр дә очрый: *пыжу/пәзү – шиңү* 'вянуть, завянуть': *Телләр дә пыжый жарда.* Татар сөйләшләрендә түбәндәге вариантлар күзәтелә: *пыжу/пожу/пәжү/ пәзү/пыжҗу* 'вянуть, завянуть', чагыштыр. морд. *пужемс/пужомс* шул ук. Чистай сөйләшендә *пыжыгу – эсседән әлсерәү* 'преть, сильно потеть от жары': *Терлекләр абзарда пыжыгып йаталар* [ТЗДС, б. 546].

Хәзерге вакытта югарыда саналган мордва сүзләре нигездә өлкәннәр телендә кулланыла. Алар борынгы алынмалар санала һәм көнбатыш диалектның күпчелек сөйләшләре өчен уртак.

Большеберезниковск районында яшәүчеләрнең эрзя телендә бүгенгәчә татар теленнән кергән алынмалар актив кулланылышта: *энялдомс* < татар. *инәлү* 'просить'; *комоля* < татар диал. *комалак,* әдәби *колмак* 'хмель'; *кшумань* < татар диал. *кушман* 'редька'; *кирмар(л) ав* < татар диал. *кырмалау* 'репей'; *юрт* < татар. *йорт* 'дом'; *сумань* татар диал. *сукман,* әдәби *чикмән* 'зипун'; *куяр* < татар. *кыяр* 'огурец'; *кендял* < татар. *кандала* 'клоп'; *куда* < татар. *кода* 'сват'; *эмеж* < татар. *җимеш*'фрукт' [ТЗДС, б. 546; ТРС, б. 863]; *ташто юрт* < татар. *ташлы йорт* 'каменный дом'. Болар барысы да халыклар һәм телләрнең үзара тыгыз йогынты ясашуын дәлилли.

Гореф-гадәтләр дә мордва-татар бәйләнешләренең тыгыз булуын күрсәтә (чагыштыр шулай ук Баязитова, 2000). Әйтик, татар-мишәрләрдә *кашык-шаwа кагу* 'стучать ложками и блюдцами'дигән туй йоласы бар. Кияү ягыннан килгән егетләр, хуҗабикәгә күрсәтми генә, кәләш әнисенең кашыкларын һәм чынаяк тәлинкәләрен куенга яки итек эченә яшерергә тырышалар. Кәләшне алып киткәндә, туй олауларында кашык, савыт-саба шакылдатканнар, тимер ләгәннәргә сугып тавыш чыгарганнар. Билгеле булганча, туйда тавыш эффектыннан кәләшне бозудан, яман күзләрдән, җен-шайтаннардан саклау өчен файдаланганнар [Баязитова, 2011, б. 197]. Мордваларның туй йоласында «чүлмәкләр вату» гадәте бар. Ул туй беткәч уйнала. Хуҗалар кулларына төрле предметлар – таяклар, мич капкачлары, буш чиләкләр алып, тавыш чыгара һәм балчык савыт-саба вата башлыйлар. Мордваларда бу йола *кудань ливтема* 'выселение поезжан' дип атала, әмма күбрәк туй вакытында чит кешеләргә ияреп кергән җеннәрне йорттан куып чыгару өчен эшләнә [Евсевьев, с. 340].

Мордовия татар-мишәрләрендә *катлама келәве* 'моление лепешек' дигән туй йоласы да бар. Туйның икенче көнендә кызлар сыен аңлата ул. Мордваларның *сюкоронь ознома* 'моление лепешек' йоласы – гадәттә туйның өченче көнендә үткәрелә. Кәләш сандыгыннан сөлге һәм алдагы көнне туганнары алып килгән кабартмалар салынган савыт чыгара. Аны өстәлгә куя һәм инәлеп сорый башлый: *Кудонь кирди, сияка, Вана саинек од човаля, вечкик кудоват якицякс. Вана тенть казне* (шуның белән бергә сөлгене кадакка элеп куя), *кептест кедензэ штердеме, – чокшне позда мадезэ, валске рана стязо* 'Хранитель дома серебряный! Вот взяли мы молодушку – полюби ее, чтобы

она ходила по твоему дому. Вот тебе дары ее (указывает на скатерть и полотенце), чтобы руки ее тянулись к пряже, чтобы по вечерам поздно ложилась, по утрам рано вставала’. Ахырда кабартмаларны шундагы кешеләрнең барысына да бүлеп бирәләр [Евсевьев, с. 306].

Этнографиядә тыгыз этномәдәни тормышны һәм алынмаларны чагылдырган башка дәлилләр дә очрый. Кәләшне озату өчен татар-мишәрләр аерым көймәле арба *вәдәк, мәдәк, кибиткә* ясаганнар. Тышкы яктан аны кәләшнең чыбылдыгы – *кушәгә белән каплаганнар.* Этнографлар фикеренчә, мишәрләрнең *вәдәге* – туй торагының иске формасы ул. Билгеле булганча, күп кенә төрки халыкларда яңа кияүгә чыккан кызны иренең йортына көймәле туй арбасында алып кайтканнар. Шундый ук йола – *куме* – чувашларда да булган [Мухамедова, с. 168].

Мордваларда мишәрләрнең *вәдәгенә бик нык охшатып* эшләнгән көймәле арба *он-ава дип аталган.* Тыштан ул кәләшнең ... һәм төрле төстәге кушаклар яки төрле төстәге йон җепләрдән ясалган чуклар белән каймаланган ак җаймә белән капланган; арба эченә киез җәелә, мендәр куела. М.Е. Евсевьев мәгълүматларына караганда, мордва халкы аны төрки телле күршеләреннән – Идел буе татарларыннан үзләштергән [Евсевьев, 1966, с. 276].

Без өлешчә генә кагылган әлеге мәсьәлә тикшеренүчеләрен көтә. Биредә этномәдәни йогынты ясашуның кайбер очраклары гына билгеләнде. Этнографик һәм тел материалын анализлау шуны күрсәтә: татар-мишәрләр культурасында мордва компонентын кире кагып булмый.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан, 2001.

*Баязитова Ф.С.* Культурно-языковые параллели в традиционных обрядах мордвы и татар-мишарей // Материалы II Всероссийский научной конференции финно-угроведов «Финно-угристика на пороге III тысячелетия (филологические науки)». 2–5 февраля 2000 г. Саранск, 2000. С. 352–354.

*Баязитова Ф.С.* Туй йолалары лексикасы (җирле сөйләш һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казань, 2011.

*Бутылов Н.В.* Иноязычная лексика в мордовских языках (индоевропейские заимствования). Саранск, 2006.

*Гарипова Ф.Г.* Татарская гидронимия. Казань, 1998.

*Гераклитов А.А.* Алатырская мордва по переписям 1624–1721 гг. Саранск, 1936.

Два списка с жалованных грамот, выданных великим князем Василием Ивановичем князю Акчуру Адашеву и его детям, на земельные владения по реке Цне [начало XVI в.]. Государственный архив Саратовской области. http://saratov.rusarchives.ru/exhib/suak/imagepages/image11.htm.

ДТС – Древнетюркский словарь. Л., 1969.

*Евсевьев М. Е.* Избранные труды. 5 т. Саранск, 1966.

*Жуковская Н.Л.* Сульде // Мифы народов мира. Энциклопедия. Т. 2. М., 1994.

*Ишеев М., Акчурин М.,* Татарские князья и их княжества в Мещерском крае. http://mullanur_isheyev@mail.ru.

*Казанцев Д.Е.* К истории цоканья в диалектах марийского языка // Материалы и исследования по марийским диалектам. Йошкар-Ола, 1987. С. 177–197.

*Махмутова Л.Т.* Некоторые наблюдения над лексикой мишарских говоров (к мишарско-мордовским заимствованиям) // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань, 1976. С. 152–159.

*Мокшин Н. Ф.* Мордовский этнос. Саранск, 1989.

Мокшанско-русский словарь. М., 1949.

*Мухамедова Р.Г.* Татары-мишары. Историко-этнографическое исследование. Москва, 1972.

*Насипов И.С.* Об основных особенностях языковых контактов тюркских и финно-угорских народов на территории Урало-Поволжья // Сохранение и развитие разных языков в условиях многонационального государства. Проблемы и перспективы. Всероссийская научнопрактическая конференция (Казань, 19–21 октября 2012 г.). Труды и материалы. Казань, 2012. С. 211–216.

ПМА 1996 – Полевые материалы В.И. Рогачева: записано в июле 1996 г. от Н.А. Гибалкина, уроженца с. Косогоры Большеберезниковского района Республики Мордовия.

ПМА 2002 – Записано в августе 2002 г. от Н.А. Арташкиной, уроженки с. Косогоры *Большеберезниковского* района Республики Мордовия.

ПМА 2012 – Записано в ноябре 2012 г. от А.Н. Гибалкина, уроженца с. Косогоры Большеберезниковского района Республики Мордовия.

*Рамазанова Д.Б.* 1991, Термины родства и свойства в татарском языке, Казань.

*Саттар-Мулилле Г.* Татар исемнәре ни сөйли? Казан, 1998.

Татарско-русский словарь. М., 1966.

Татарско-русский словарь: в двух томах. Казань, 2007.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

*Феоктистов А.П.* К проблеме мордовско-тюркских заимствований // Этногенез мордовского народа. Саранск, 1965. С. 334–337.

*Цыганкин Д.В.* Память, запечатленная в слове: словарь географических названий Республики Мордовия. Саранск, 2005.

*Шувалов Н.И.* От Парижа до Берлина по карте Челябинской области: Топонимический словарь. Челябинск, 1989.

Эрзянско-русский словарь. М., 1949.

***Рогачев Владимир Ильич,***
*филология фәннәре докторы, М.Е. Евсевьев исемендәге Мордва дәүләт педагогика институтының әдәбият һәм әдәбият укыту методикасы кафедрасы профессоры*

***Баязитова Флера Сәет кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Сәфәрәв Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире*

УДК 821

***А.Т. Ибраева, Л.И. Минһаҗева***

# КАЗАКЪ ФОЛЬКЛОРЫ ҺӘМ ШӘРЫК ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАРЫ

В данной статье рассматривается историческое влияние восточной культуры и литературы на развитие и становление казахского фольклора. Анализируется художественность фольклорных и литературных ценностей тюркских родственных народов. Обоснована схожесть сюжетов восточного поэтического сказания и эпической поэмы, а также эпических сочинений с фольклорными образцами казахского народа.

**Ключевые слова:** казахская фольклористика, литературные связи, литература родственных народов, литературные памятники, восточная литература, фольклорные произведения, культурное наследие.

This article discusses the historical influence of Eastern culture and literature on the development and formation of Kazakh folklore. The artistry of folklore and literary values of Turkic related peoples is analyzed. The similarity of the plots of the Eastern poetic legend and epic poem, as well as epic works with folklore samples of the Kazakh people is substantiated.

**Keywords:** Kazakh folklore, literary connections, literature of related peoples, literary monument, eastern literature, folklore works, cultural heritage.

Бөтен төрки әдәбиятларның мәдәни тамырлары уртак. Төрки халыклар сүз сәнгатенең алга таба үсешенә һәм гөрләп чәчәк атуына нигез булган милли рухи мирас моны тулысынча раслый. Бу, барыннан да элек, угызларның «Китабы Дәдә Коркыт»ы, кыргыз героик эпосы «Манас», казакълар һәм татарлар арасында төрле вариантлары киң таралган «Идегәй», татар халкының атаклы «Чура батыр»ы һ. б. «Мең дә бер кичә», «Шаһнамә», «Кәлилә вә Димнә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Фәрһад-Ширин» яисә «Хөсрәү-Ширин» кебек әсәрләр казакъ әдәбияты үсешенә шактый зур йогынты ясады.

Урта гасырларда Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасындагы мәдәни багланышлар хакында галим П.А. Гринцер болай дип яза: «Күп кенә әкият сюжетлары Европага монголлар һәм гарәпләр белән (ә берникадәре алардан башка да) күчеп килде. Аларны тулаем Европа фольклорында да, немец шванкларында да, француз фабльоларында да һәм Сакс, Бокаччо, Чосер, Маргарита Наварская, Сервантес, Шекспир, Лесаж һ. б. ның әсәрләрендә дә табып була» [Гринцер, с. 23].

Шәркый-төрки мәдәният һәм сәнгатьнең Европа илләре халыклары әдәбиятына йогынтысы турында галим бик тә кыю һәм гадел фикер әйтә.

Шәркый-төрки мәдәният һәм сәнгать тарихы меңнәрчә елларны колачлый. Фәндә шунысы бәхәссез: әл-Фараби, әл-Бируни, әл-

Фиргани, Олугбәк кебек даһиларны биргән төрки халыкларда язу, фән һәм мәдәният Европадагыдан күпкә алдан барлыкка килгән һәм бөтен кешелек дөньясы тарихында тирән эз калдырган.

Милли әдәбиятларның үзара йогынты ясашуы мәсьәләсен традицион рәвештә чагыштырма әдәбият белеме өйрәнә. Аңа А.Н. Веселовский нигез салган. Төрки әдәбиятларның әдәби үзара багланышларына нисбәтән чагыштырма методны куллану әдәбиятара аралашуның характерын ачыклауны таләп итә. Ул, Д. Дюришин билгеләп үткәнчә, ике төргә аерыла: генетик-контактлы (туры һәм туры булмаган, тышкы һәм эчке, йогынты ясау һәм алынмалар) әдәби багланышларга һәм әдәби метод, жанр үзенчәлекләре һәм аерым бер милли мохит дәрәҗәсендә чагылыш тапкан типологик охшашлыкларга [Дюришин, с. 100]. Әдәбиятларны типологик тикшерү Ф.И. Урманчеев, Р.К. Ганиева, Х.Й. Миңнегулов, Ф.С.Сафиуллина, В.Р. Әминева, А.М. Галиева, Ф.Г. Галимуллин, А.Ф. Галимуллина, М.И. Ибраһимов, Р.Ф. Мөхәммәтшина, Л.И. Минһаҗева, Й.Г. Нигъмәтуллина, Л.Х. Мөхәммәтҗанова кебек Казандагы әдәбият, фольклор, тел галимнәренә һәм культурологларына тел өлкәсендәге һәм әдәби үзара бәйләнешләрне тел, әдәбият һәм сәнгатьне гуманитар һәм иҗтимагый фәннәрнең интеграцион тикшеренүләре, концептуалистика, методология һәм тикшеренү алымнарының үзара бәйләнеше кысаларында системалы-комплекслы өйрәнү контекстында карарга мөмкинлек бирде. Бу алым җәмгыять белеменең төрле юнәлешләре өчен хас.

М. Ауезов, А. Байтурсынов, А. Маргулан, Б. Кенжебаев, А. Коныратбаев, Е. Смайлов, К. Жумалиев, С. Аманжолов, Г. Айдаров, С. Кирабаев, Х. Суюншалиев, З. Кабдолов, З. Ахметов, Р. Бердибай, Р. Сыздыкова, К. Омиралиев, А. Курышжанов, М. Томанов, Р. Нургалиев, С. Каскабасов, М. Жолдасбеков, М. Магауин, Т. Какишев, О. Кумисбаев, М. Жармухамедулы, С. Даутов, С. Негимов, Н. Келимбетов, Б. Уакатов һ. б. кебек казакъ галимнәренең хезмәтләре аеруча игътибарга лаек.

Әлеге галимнәрнең хезмәтләрендә төрки халыклар әдәбиятларының стиль, поэтика һәм тел аспектларында борынгы төрки истәлекләргә барып тоташуы фәнни яктан дәлилләнә. Төрки халыклар мөстәкыйльлеккә ирешкәч, бу бигрәк тә ачык күренә. Чөнки соңгысы бөтен төрки дөньяның иҗтимагый һәм рухи тормышында үзгәрешләр китереп чыгара. Нәкъ менә шул вакытта төрки халыкларның берлеген һәм бердәмлеген характерлаган күпсанлы саллы фәнни хезмәтләр язылa. Ш. Ыбыраев, А. Егеубай, Ж. Дадебаев, Д. Ыскакулы, А. Кыраубаева, Б. Абылкасымов, З. Бисенгалиев, Б. Майтанов, Т. Журтбай, Б. Ыбырайым, Б. Абдигазиулы, Б. Сагындыков, А. Аманжолов, Б. Азибаева, Б. Омарулы, А. Исмакова, С. Корабай, Д. Камзабекулы тикшеренүләрендә яңа заманның фикер юнәлешләре күзәтелә. Исемнәре югарыда аталган галимнәрнең кайбер хезмәтләрендә поэтика, героик эпосларның периодик бөтенлеге карала, икенчеләрендә борынгы төрки хикәя һәм казакъ эпик поэмаларының универсаль билгеләре,

сәнгати традицияләрнең күчүчәнлеге өйрәнелә. Фәнни хезмәтләрнең бер өлеше поэтиканы, «Төрки мәдәниятнең алтын гасыры»н тәшкил иткән әсәрләрнең эстетик-сәнгати системасына, шулай ук Алтын Урда дәверендә иҗат ителгән әсәрләрнең поэтикасына, аларның идея-художество үзенчәлекләренә һәм традицияләрнең дәвамчанлыгына багышлана.

Шул рәвешле, Казакъстанның әдәбият белеме фәнендә борынгы һәм Урта гасырлар рухи мирасы үрнәкләре махсус өйрәнелә, аларның төрки халыклар әдәбиятларының нигезе, чишмә башы булуы дәлилләнә, әлеге әсәрләрнең тарихилыгы, поэтикасы, художество үзенчәлеге, традицион дәвамчанлыгы өйрәнелә. Төрки халыкларның уртак әдәби ядкярләре методологик позициядән мәдәни-тарихи процесслар нигезендә тикшерелә (А. Кыраубаева, Н. Келимбетов, Б. Сагындыков, А. Жаксылыков, А. Егеубаев, К. Сейтжанов хезмәтләре).

П.А. Гринцер фикерен дәвам итеп, күп кенә Шәрык әкиятләренең, легенда, эпик поэмаларның сюжетлары казакъ, татар, кыргыз, каракалпак, үзбәк, төрекмән фольклоры барлыкка килүгә нигез була. Көнчыгыш традициясендә уртак сюжетка корылган һәм борын-борыннан Шәрыктә яшәгән төрки халыкларның гомум мәдәни мирасын тәшкил иткән авыз әдәбиятының күпсанлы үрнәкләре сакланган. Төрки кабиләләрне бүлгәләү, аннан – берләштерү чорында, эре дәүләтләр төзелгәндә борынгы истәлекләр геройларның, бөтен халыкның рухын күтәргән. Теләсә-кайсы фольклор әсәрендә һәм әдәби ядкярләрдә халыкның патриотик рухы, аның кешелек сыйфатлары чагылыш таба. Шундый затлы сыйфатларга ия булган төркиләр Алтайдан алып Дунайга кадәр сузылган киңлекләрдә таралып яшәгән.

Тикшеренү объекты кысаларында төрки халыкларның рухи алмашу-аралашуы турындагы фикерне дәвам итеп, көнчыгыш-төрки халыкларның үзара якынаюына күршеләр булып яшәү генә булышлык итмәвен билгеләп үтәсе килә. Бу процесска социаль тормыш рәвеше һәм гореф-гадәт формалары, шулай ук универсаль мәдәни характеристикалар да зур йогынты ясый. Казакъ, татар, азәрбайҗан, башкорт, үзбәк, кыргыз, төрекмән халыкларының фольклор үрнәкләре һәм борынгы әдәби истәлекләре, тарихи мәгълүматлар, архив документлары төрки дөньяның бердәмлеген һәм тупланганлыгын раслый.

Хуҗа Насретдин, Җирән чичән, Алдар Көсе белән бәйле легендалар, хикәяләр, дастаннар, әкиятләр, «Алпамыш», «Кобланды», «Күруглы» героик поэмалары, «Кузы Көрпәч – Баян Сылу» лиро-эпик поэмасы һ. б. – халыкларның бөек әсәрләре. Алар төрки халыкларның элек-электән сәнгати фикерләү, үзләренең үткәнен һәм бүгенгесен нәфасәти үзләштерү тәҗрибәсенә ия булуын ачык күрсәтә. Казакъ халкы, бөек төрки дөньяның бер вәкиле буларак, үз тарихы турында гына рухи истәлекләр иҗат итеп калмады, ә бөтен төрки дөньяны колачлады, чөнки һәр халыкның үткән юлы башкаларныкына бик тә охшаган иде.

«Орхон-Енисей язмалары», «Котадгу белег», «Диване лөгатет-төрк», «Диване Хикмәт», «Кодекс куманикус» кебек бөтен төрки

дөньяның байлыгы булган мәдәни мирас үрнәкләре һ. б. әдәби ядкярләр безнең халыкларның якынлыгы һәм туганлыгы турында сөйли. В. Бартольд, В. Радлов, С. Малов, Ч. Вәлиханов, А. Диваев, Н. Баскаков, А. Кононов, А. Щербак, Х. Коруглы, Г. Араслы кебек күренекле галимнәрнең хезмәтләре дә моны раслый. Әйтик, галим-тюрколог Н.А. Баскаков төрки халыкларны тел ягыннан туганлык һәм аерымлыклары буенча классификацияли. В. Радлов, С. Малов, А. Щербак, В. Жирмунский, Х. Коруглы, Г. Араслы, А. Маргулан, Б. Уахатов кебек галимнәрнең тикшеренүләрендә төрки халыкларның тугандашлыгыннан, аларның тел, традицияләр охшашлыгыннан килеп чыккан тарихи-генетик туганлык типологик янәшәлекнең бер формасы итеп карала.

Бу контекстта фольклорчы галим Б. Уахатов түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Авыз иҗаты әсәрләренең кардәшлеге һәм уртаклыгы өске охшашлык белән генә билгеләнми; тәңгәллек закончалыгын ачу өчен, җитди һәм катлаулы принциплар кулланырга кирәк. Әлеге сәбәп һәм характеристикаларны истә тотып, фольклорда типологик охшашлыкның өч төре аерыла. Болар – тарихи-генетик, тарихи-мәдәни, тарихи-типологик аһәңдәшлек һәм охшашлыклар» [Уахатов, б. 186–195]. Галим төрки халыклар өчен уртак әдәби ядкярләрне һәм рухи мирасның борынгы үрнәкләрен нигез итеп ала.

Авыз иҗаты үрнәкләренең башлангычы дини карашларга барып тоташа. Чөнки алар кешелек тарихының борынгы чорында, мистик фикерләү системасы хакимлек иткән дәвердә пәйда булалар. Мөгаен шуңа күрә шәрык-төрки фольклоры үрнәкләре – экиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, шигъри хикәяләр («кыйссалар»), легендалар һәм риваятьләр Изге Коръәнгә һәм хәдисләргә нигезләнәләр. Дин белгече Т. Барласулы бу турыда болай ди: «Мөхәммәд пәйгамбәргә (сгв) кадәр яшәгән пәйгамбәрләрнең вәгазьләре (алар халыкны тәкъвалыкка өндәгәннәр) хикәяләргә, риваятьләргә, экиятләргә якын торганнар, аннан соң аларның дәвамын Коръәндә табып булган. Фани дөньяда бары тик рухи кыйммәтләр (экиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, шигъри хикәяләр, халык җырлары, кыйссалар һ. б.) генә мәңгелек була ала. Халыкның рухи мирасы аның Ходай тарафыннан иңдерелгән җаны нигезендә формалаша. Һәм ул буыннан буынга тапшырылган халык җырларында һәм кыйссаларда чагылыш таба» [Барласұлы, б. 112].

Фольклорның шундый жанрлары эчтәлеген тирәнтен һәм тулысынча аңлау өчен, без Коръән сүрәләренә һәм аятьләренә мөрәҗәгать итәбез. Шуның белән бергә, бөтен төрки дөньяның фольклор әсәрләре ата-бабаларның килеп чыгышы белән тарихи эзлеклелектә очраша.

Бу уңайдан фольклорчы галим С. Каскабасовның төрки халыкларның борынгы истәлекләре турындагы фикерен урынлы дип саныйбыз. «Алпамыш» героик эпосы казакъ, татар, үзбәк, башкорт, кыргызлар, шулай ук алтайлылар арасында барлыкка килгән һәм төрле исем астында, төрле күләм белән таралган. Коркыт белән бәйләнешле легендалар һәм риваятьләр казакълар, башкортлар, төрекмәннәр,

азәрбайҗаннар, төрекләр арасында бик популяр булган. «Кузы Күрпәч белән Баян Сылу» лиро-эпик поэмасының үрнәкләре казакъларда, башкортлар, татарлар, алтайлылар, уйгырларда сакланган. Бер үк хикәянең күпсанлы халыкларда барлыкка килүе һәм таралуы , әлбәттә, очраклы түгел. «Алпамыш», «Кузы Көрпәч белән Баян Сылу» кебек эпик әсәрләрнең, «Коркыт Дәдә китабы» эпик истәлегенең тәүге үрнәкләре төрки халыкларны берләштерү дәверендә кечкенә генә хикәяләр рәвешендә барлыкка килүен ассызыклап, галим болай ди: «Шулай итеп, Төрки каганлык, Урта гасырларның эре дәүләте, VI гасырда оешкан һәм ун гасыр чамасы хакимлек иткән. Димәк, төрек дәүләтенең ике мең ел элек барлыкка килүе бәхәссез» [Қасқабасов, б. 93].

Төрки халыкларның әдәби мирасы һәм авыз иҗаты гомумилек һәм аһәңдәшлек белән характерлана. Казакъ халык авыз иҗатының «Қырымнан қырық батыры» дигән эпик әсәре структурасы белән кыргызларның «Манас» эпосын хәтерләтә. Халыкларның күршеләр булып таралып утыруы, үзенчәлекле универсальлек аркасында авыз әдәбиятының башка жанрлары да аһәңдәш була. Мәсәлән, мәкальләр һәм әйтемнәр: «Һөнәрне өйрән, өйрән дә җирән» («Өнерді үйрен, үйрен де жирен»), «Ат чанада беленер, ир сәфәрдә беленер» («Ат арыса – тулақ, ер арыса – аруақ»), «Айрылған ел азар, қосылған ел озар». Аларның текстлары да охшаш, төп идеяләре дә уртак.

Казакъ халкының «Мең дә бер кичә», «Шаһнама», «Ләйлә-Мәҗнүн», «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөхрә», «Кәлилә вә Димнә, «Фәрһад-Ширин» яки «Хөсрәү-Ширин» һ. б. дастаннары, поэтик әсәрләре бөтен дөнья җәмәгатьчелеген хәйран калдыра. Сүз дә юк, халыкларның үзара мөнәсәбәтләрендә галимнәрнең һәм сүз осталарының роле гаять зур, чөнки халык белән халыкны бер-берсенә аларның бөек уллары һәм акыл ияләре якынайта.

Моңа нисбәтән Көнчыгышның бөтен дөньяга танылган Рудаки, Фирдәүси, Руми, Хафиз, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Җами, Мәрҗани, Абай кебек әдипләренең исемнәрен атарга кирәк. Мәсәлән, шәрыкче галим В.В. Бартольд фикеренчә, Фирдәүсинең хезмәте Көнчыгыш халыклары арасында VI–VII гасырларда киң таралган. «Шаһнамә»нең төп мотивы – фарсыларның каһарманлыгына дан җырлау. Әсәр төрки дөньяның гына түгел, ә бөтен дөнья җәмәгатьчелегенең милли чынбарлыкны аңлавына йогынты ясау үрнәге булып хезмәт итә. Рудаки, Руми, Сәгъди, Хәйям, Хафиз, Җами әсәрләренең немец, рус, инглиз, француз телләренә тәрҗемәләре, XIX гасырдан башлап, аларны бөтен дөньяга таныта. Тарихтан билгеле булганча, Көнчыгышның күп кенә шагыйрьләре үзләре исән вакытта ук дан һәм абруй казана. «Мәснәви»китабының авторы, шәех, суфи шагыйрь Җәләлетдин Руминың исеме шулкадәр киң билгеле була ки, хәтта аны соңгы юлга озатырга төрле илләрдән башка диннәр вәкилләре дә килә.

Көнчыгыш халыкларның рухи кыйммәтләр алмашуы бертөрле генә бармый. Социаль-тарихи вакыйгалар, төрки халыклар тормышының

авыр чорлары да моңа сәбәп була. Чыңгызхан, Тамерлан (Аксак Тимер) җитәкчелегендәге походлар, сугышлар рухи мирасның киң таралуына комачаулый, аннан соң зүүнгар-казакъ чуалышлары аркасында көнчыгыш-казакъ, төрки-казакъ әдәби бәйләнешләре йомшара төшә.

Төрки халыклар әдәбиятында кайбер типологик күренешләрнең охшашлыгы мәсьәләсе махсус өйрәнелмәде. Аларда еш чагылыш тапкан кардәшлек һәм үзара диалект алмашу процесслары традицион рәвештә, үсештә гамәлгә ашырыла. Шуны истә тоту зарур: авыз әдәбиятында үзара мөнәсәбәтләрнең ике төре (гомуми типология һәм үзара бәйләнешләр) диалектик бердәмлек хасил итәләр, ягъни элемтәләр әдәбият үсешенең гомуми закончалыкларына нигезләнәләр. Алар типологияне тулыландыралар, киңәйтәләр, гомум типологик рәттәге урыннары үзара бәйләнешләрне гадиләштерә.

Әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләр – киңкырлы тарихи-әдәби һәм сәнгати-нәфасати күренеш. Алар үзара алмашуның төрле фактларын үз эченә ала. Күп кенә әдәбиятлар арасында үзара бәйләнешләрнең дәвам иттерелүе аларның генетик кардәшлеге белән аңлатыла. Димәк, багланышлар да меңьеллыклар белән исәпләнә. Моңа нисбәтән казакъ һәм башка төрки әдәбиятларның тирән кардәшлек белән аңлатылган генетик бәйләнешләре турында да әйтергә кирәк.

Анализ күрсәткәнчә, төрки телле халыклар әдәбиятының борынгы һәм Урта гасырлар мирасы бар җирдә дә тигез таралмаган һәм төрле ысуллар белән сакланган. Хикәяләр, дастаннар, эпик поэмалар төрки халыкларның кайберләрендә бар, икенчеләрендә юк. Яисә бер үк үрнәкнең берничә варианты таралу очраклары да бар. Моңа һәр халыкның тарихи үсеш үзенчәлекләре, социаль шартлар, шуннан килеп чыккан ихтыяҗлар, чынбарлыкны кабул итү үзгәлекләре сәбәп була.

Тема, идея, сюжетны аңлату, образларны бирүдәге универсальлекләр, тюрколог галимнәр һәм тикшеренүчеләр фикеренчә, кардәш халыкларның уртак үзенчәлекләре белән аңлатыла.

Тарихи фактлар һәм мәгълүматлар төрки халыкларның этник генезисын, аларның көнкүрешен һәм дини ышануларын чагылдырган фольклор әсәрләре пәйда булуын раслый. Мәсәлән, «Алпамыш», «Кобланды», «Йиртөшлек», «Идегәй» героик эпосларын һәм башка эпик әсәрләрне төрки халыкларның күбесендә очратып була.

Әлеге универсаль характеристикаларның сәбәбен төрки нигездән һәм дини бердәмлектән эзләргә кирәк. Эпик әсәрләрдә бу күренешне вакыйгалар бәянында, аларны образлы тапшыру ысулларында очратырга мөмкин. Бу уңайдан академик Р. Бердибайның фикеренә аерым игътибар бирү сорала: «Казакъ һәм башкорт әдәбиятларында охшашлык һәм аналогияләрнең булуы бу халыкларның тугандашлыгы белән аңлатыла. Фәнни әйләнештә бу күренешләр тарихи-генетик билгеләр дип атала» [Бердібай, б. 58].

Димәк, барлык төрки халыклар әдәбиятларында диярлек урын алган типологик, генетик һәм территориаль әдәби багланыш төрләре бу халыкларның үзара мөнәсәбәтттә торуын күрсәтә. Мисал өчен, Р.

Бердибай казакъ халкы арасында киң таралган «Чура батыр, «Йиртөшлек», «Идегәй», «Ир Таргын» эпосларының башкортларга да билгеле булуына, «Кузы Күрпәч белән Баян Сылу» лиро-эпик поэмасының берничә үрнәге аларда да саклануына ишарәли [Бердібай, б. 40].

Әдәби багланышлар төрки телле халыкларның сәяси-икътисади һәм мәдәни тормышына зур йогынты ясый, аларны берләштерә. Мондый тенденция халык авыз иҗаты һәм борынгы әдәбият үрнәкләрендә дә күзәтелә.

Югарыда әйтелгәннәр төрки әдәбиятларның үзара йогынты ясашуының закончалыклы булуын дәлилли. Казакъ, үзбәк, кыргыз, каракалпак, азәрбайҗан халыкларының халык авыз иҗатында «Күруглы», «Алпамыш», «Кобланды» эпослары, Коркыт, Алдар Көсе, Хуҗа Насретдин турында хикәяләр һәм легендалар үрнәкләре, шулай ук Шәрык әкиятләренең төрле вариантлары очрый. Моны галимә С. Тойшыбаева түбәндәгечә нигезли: «Урта Азия халыклары әдәбиятындагы һәм гарәп, фарсы, төрек, һинд әкият һәм легендаларындагы сюжет охшашлыгына бу халыкларның сәүдә-икътисади, хуҗалык эшчәнлеге сәбәп була» [Тойшыбаева, б. 57]. Шул рәвешле, галим каракалпакларның «Шадьяр» поэтик хикәясе һәм казакъның «Кыз Жибек» эпик поэмасы, шулай ук «Идегәй», «Ир Косай», «Ир Шора» кебек эпик әсәрләре  сюжетларының халкыбызның фольклор үрнәкләренеке белән охшашлыгын исбатлый.

Шуның белән бергә, Ч. Вәлиханов, В. Радлов, В. Жирмунский, А. Маргулан, Р. Бердибай, Х. Захаров, И. Сәгыйтов, И. Ыбраев кебек тюрколог галимнәр карашынча, кардәш халыклар эпик әсәрләрендәге идея, образлар, мотив охшашлыгы генетик туганлык белән генә түгел, ә тулаем эпик әсәрләр типологиясе характеристикасы белән дә аңлатыла. Академик В. Жирмунский Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыкларының эпик әсәрләре үзләренә генә хас үзгә сыйфатлар белән характерлана, дип яза. Мәсәлән, геройның могҗизалы рәвештә тууы, бик тиз үсүе, кешеләр кебек сөйләшә белгән, җилдән дә житезрәк чапкан атны сайлавы, ниндидер албасты-убырлар һәм серле затлар белән очрашуы, көндәшләрен җиңүе, кәләш эзләве, дошманының кызына өйләнүе һ. б. Әлеге мотивлар, үзенчәлекләр көнчыгыш-төрки эпосларга хас. Мондый аналогияләр казакъ, каракалпак, кыргыз, башкорт халыклары эпик әсәрләренең үзенчәлекле билгеләрен тәшкил итә.

Бу эпосларның һәрберсендә халыкның милли-специфик билгеләре, үзенчәлеге, гореф-гадәт, йола һәм традицияләре, мәнфәгатьләре һәм өмет-хыяллары чагылыш таба. Фольклор үрнәкләренең кардәш халыклар арасында киң таралуы аларның этник һәм территориаль якынлыгын, уртак тарихи язмышка ия булуларын күрсәтә, ул гына да түгел, алар арасында тыгыз мәдәни бәйләнешләр урнашуын раслый.

Кайбер төрки халыклар, аерым алганда, казакъ һәм башкорт, казакъ һәм төрекмән, казакъ һәм азәрбайҗан, казакъ һәм уйгырлар

арасындагы әдәби-иҗади бәйләнешләр мәсьәләсе комплекслы өйрәнүне таләп итә. Совет власте чорындагы тоталитар система әлеге элемтәләрне ачарга ирек бирмәде, бүген исә әлеге мәсьәләне өйрәнү киң колач ала. Галим Р. Бердибай сүзләренә караганда, тюркологиядә фәнни тикшеренү эшләренең методологик нигезен тәшкил иткән яңа концепцияләр «төрки бердәмлек»не ныгытып кына калмыйлар, ә яшь буынның аңын модернизацияләр, милли рухны көчәйтәләр.

Моңа нисбәтән төрки халыкларның тарихи-мәдәни бердәмлеген гәүдәләндергән борынгы язма истәлекләрне атап китү зарур. Барыннан да элек, рун язулы «Орхон-Енисей язмалары»н әйтергә кирәк. Алга таба, «Котадгу белег», «Диване лөгатет-төрк», «Диване Хикмәт», «Һибәтел хакаик» (Ә. Йүгнәки), «Мәхәббәтнамә» (Харәзми), «Кыйссаи Йосыф», «Кыйссасел әнбия» (Рабгузи), «Фәрһад-Ширин» яки «Хөсрәү-Ширин» һ. б.

«Китабы Дәдә Коркыт»ка кергән хикәя-кыйссаларда төрки халыкларның этник характеристикалары бирелгән: угыз баһадирларының чит ил басып алучыларына каршы, кабиләләр арасындагы ызгыш-талашка чик куеп, бердәм хакимият урнаштыру өчен көрәше бәян ителә. Галим А. Егеубай болай дип билгеләп үтә: «Төрки дөнья төрле территорияләргә, милләтләргә һәм халыкларга таркалуга карамастан, төрки телле халыкларга хас тел, сәнгать, танып-белү процесслары дәвамчанлыгын саклый. Бу әлеге халыкларның әдәби-мәдәни бәйләнешләрендә күзәтелә. Әдәби процессның нигезе – мәдәни мирасның асылында» [Егеубай, б. 18]. Поэтиканы, борынгы төрки әдәби мирасның нәфасәти-сәнгати системасын өйрәнү белән шөгыльләнүче галим борынгы төрки цивилизациянең нигезен тәшкил иткән әсәрләр – «Котадгу белег», «Диване лөгатет-төрк», «Диване Хикмәт», «Һибәтел хакаик» (Ә. Йүгнәки) – синхроник һәм диахроник дәрәҗәләрдә үзара тыгыз йогынты ясашуны күрсәтә, дип саный. «Без гадел сүз, халык акылы, мәкальләр һәм әйтемнәр, канатлы сүзләр һәм гыйбарәләр турында сөйләгәндә, барыннан да элек, казакъ, кыргыз, үзбәк, уйгыр, татар, нугай халыкларының бай рухи мирасы белән очрашабыз. Халыкларның бердәй үзенчәлекләргә ия булуы, табигать закончалыкларының универсальлеге, шул нигездә барлыкка килгән йолалар һәм традицияләр, холык һәм үз-үзеңне тоту рәвеше, кешеләр арасындагы туганлык югарыда аталган кыйсса-хикәяләрдә һәм сүзлекләрдә урын ала» [Егеубай, б. 24].

Урын-җир атамалары, төрки халыклар әдәби мирасында урын алган образлы гыйбарәләр аларның дөньяга карашларындагы, тарихи язмышларындагы уртаклыклар турында сөйли. Борынгы төрки истәлекләр – әлеге фикерне тагын бер кат дәлилли.

Россия империясе һәм Совет власте елларында бөтен төрки дөнья казанышы саналган әдәби мирас аерым бер халыкның гына рухи кыйммәте буларак каралды.

Әйтик, азәрбайҗаннар һәм үзбәкләр «Китабы Дәдә Коркыт»ны үзләренең генә милли байлыгы дип санадылар, галимнәр, казакъ,

башкорт, татар зыялылары вәкилләре аны үз телләре призмасы аша өйрәнергә омтылдылар. «Диване лөгатет-төрк», «Котадгу белег», «Кодекс куманикус» турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Мондый мөнәсәбәт әлеге әдәби ядкярләрне аерым бер халык теле кысаларында тирәнтен өйрәнергә мөмкинлек бирә бирүен, әмма борынгы истәлекләрнең тарихилыгын һәм поэтикасын, нәфасәти-сәнгати формасын тулысынча ачарга ярдәм итми. Ягъни тикшерү объекты бер халык үзенчәлекләре кысаларында гына карала, бөтен төрки дөньяның милли-специфик характеристикалары исәпкә алынмый. Димәк, әсәр тарихи дөреслек яссылыгыннан өйрәнелми. Бу исә мәдәни-әдәби мирасны тулаем һәм комплекслы өйрәнергә комачаулый.

Без академик Р. Нургалинең түбәдәге фикерен тулысынча хуплыйбыз: «Казакъ әдәбиятының борынгы төрки һәм Урта гасырлар әдәбиятлары белән тугандашлык бәйләнешләрен билгеләү өчен, бу тарихи-мәдәни һәйкәлләрне бөтен яклап өйрәнергә кирәк. Димәк, безнең тюркологларга Енисейның югарыгы агымында урнашкан җирләргә дә, Орхон елгасы үзәнлекләренә дә барып, таш диварлардагы һәм плитәләрдәге язуларны үз күзләре белән күрергә, китап фондын һәм архив мәгълүматларын өйрәнергә, язмаларның күчермәләрен алырга кирәк. Бары тик шул вакытта гына бу әсәрләрнең поэтик стилен һәм әдәби юнәлешен өйрәнергә мөмкинлек туа» [Нұрғали, б. 12].

Шулай итеп, милли аерымлыклары булуга карамастан, төрки халыкларны уртак әдәби тамырлар, максат һәм мәнфәгатьләр, әхлакый, рухи һәм мәдәни кыйммәтләр, этика нормалары, төрки мәдәнияткә хас традицияләрне саклау һәм үстерү омтылышы берләштерә. Шуның белән бергә алар барыбыз өчен дә уртак проблеманы хәл итәләр: бер яктан, халыкның теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә хас үзенчәлекләрне саклыйлар, икенче яктан, гомум глобальләштерү шартларында әдәби поликультур киңлекнең бердәмлеген тәэмин итәләр.

**Әдәбият**

*Amineva V.R., Ibragimov M.I., Nagumanova E.F., Khabibullina A.Z..* G. Tukay's poetry: the aspects of national identity / V.R. Amineva, M.I. Ibragimov, E.F. Nagumanova, A.Z. Khabibullina // XLinguae European Scientific Language Journal. Volume 8. Issue 1, January 2015, ISSN 1337–8384. C. 79–87.

*Dautov Gumar F., Mingazova Liailia I., Sayfulina Flera S., Kayumova Gelyusya F.* // Written heritage of the Golden Horde Opción, Año 34, Especial 2018. No. 14. S. 895–911.

*Galimullin Foat G., Galimullina Alfiya F., Mingazova Liailia I.* Common roots, common spirituality: literary relationships of the tatar and azerbaijani literature in the context of the dialogue of cultures// The Social Sciences. Year: 2016. Volume: 11. Issue: 16 | Page No.: 3940–3945.

*Gimadieva Guluza Ilyasovna, Mingazova Liailia Ihsanovna, Sayilov Galib Amiruglu, Sayfulina Fleura Sagitivovna.* General Roots, General Spirituality: Literary Interrelations of Literatures in the Aspect of Cultural Dialogue // Journal of History Culture and Art Research. Vol. 6, No. 4, September 2017. 497–504.

*Mingazova L.I., Galimullin F.G., Galimullina A.F.* Folk heroes in the poetry of the people of the Volga and Ural regions // Journal of Language and Literature (Baky, Azerbaijan). 2014. № 5 (4). С. 252–555.

*Барласұлы Т.* Сөз атасы – ертегі. Құранна сөз шертеді // «Қазақ әдебиеті» газеті. 06.10.2012. № 40.

*Бердібай Р.* Эпос – ел қазынасы. Алматы: Рауан, 1992. 148 б.

*Гринцер П.А.* Эпохи взаимодействия литератур Востока и Запада. М.: Рос. гос.гум.университет, 1997. 151 с.

*Дюришин Д.* Теория сравнительного изучения литературы. М.: Прогресс, 1979. 320 с.

*Егеубай А.* Құлабыз. – Алматы: Ана тілі, 2002. 193 б.

*Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. и др.

*Қасқабасов С.* Түгел түркі толғаған толағай жыр // «Қазақ әдебиеті» газеті. 21.06.2013. № 25.

*Нұрғали Р.* Сырлы сөз. Әдеби сын, зерттеу. 1 том. Алматы: Жазушы, 2000. 400 б.

*Тойшыбаева С.* Қазаққарақалпақ әдебиеттерінің байланысы. Алматы: Ғылым, 1977.88 б.

*Уахатов Б.* Өрнекті ойлар. «Кереку» баспасы. 2018. 294 б.

*Урманче Ф.И.* Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002.

*Урманче Ф.И.* По следам Белого волка. Ранние этнокультурные взаимосвязи тюрко-татарских племен. – Казань: ИЯЛИ, 1994.

***Ибраева Айгерим Тарбин кызы,***
*педагогика фәннәре магистры, С. Торайгыров исемендәге Павлодар дәүләт университеты докторанты (Павлодар, Казакъстан)*

***Минһаҗева Ләйлә Ихсан кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

УДК 929

*А.М. Ахунов*

# ТАТАР МАТБАГАЧЫЛЫК ТАРИХЫНДА И.Н. ХАРИТОНОВ
## *(тууына 160 ел тулу уңаеннан)*

Иван Николаевич Харитонов (1859–1927), русский типограф и издатель, внес неоценимый вклад в дело становления и развития татарской печати в кон. XIX – нач. XX в. В его типографии размещали свои заказы видные татарские писатели, издатели газет и журналов, с которыми он поддерживал личные, дружеские отношения, в т. ч. благодаря хорошему знанию татарского языка. Татарская пресса называла его доброжелательно «Харитон бабай», тем самым отдавая дань почтения русскому издателю. И.Н. Харитонов постоянно повышал качество своих изданий, применял новейшие европейские достижения в области типографии, разрабатывал новые макеты и шрифты, вкладывая в развитие личные средства.

**Ключевые слова**: Харитонов И.Н. (1859–1927), типографское дело в Казанской губернии, история татарской книги, мусульманская печать, история татарской культуры.

Ivan Nikolaevich Kharitonov (1859–1927), a Russian typographer and publisher, made an invaluable contribution to the establishment and development of the Tatar press in the in the late 19th and early 20th century. Prominent Tatar writers, publishers of newspapers and magazines with whom he maintained personal, friendly relations, also thanks to a good knowledge of the Tatar language, placed their orders in his printing house. The Tatar press called him benevolently «Khariton Babai», thus paying homage to the Russian publisher. I.N. Kharitonov constantly improved the quality of his publications, applied the newest European achievements in the field of typography, developed new layouts and fonts, investing personal funds in the development.

**Keywords:** Kharitonov I.N. (1859–1927), typography in Kazan province, history of the Tatar book, Muslim press, history of the Tatar culture.

Танылган рус типографы, басмаханә хуҗасы Иван Николаевич Харитонов XX гасыр башында Казан татарлары өчен мәшһүр кеше булган. Татарлар аны зурлап, якын итеп Харитон бабай дип атаганнар. Ул – татар телендә күпсанлы китаплар, журналлар нәшер иткән кеше. Шунысы мөһим – Харитон бабай хәзерге байлар кебек керем артыннан гына кумаган, ә басылып чыккан китапларның сыйфатлы, зәвыклы булуын кайгыртткан, яңа макетлар, шрифтлар уйлап тапкан. 1908 елда «Шура» журналы да аның бу эшчәнлегенә зур бәя бирә.

«Безнең галимнәр һәм мөхәррирләр Харитоновны җитәрлек кимәлдә бәялиләрме соң», – дип яза журнал, һәм аның басма хәрефләрне яхшыртудагы тырышлыкларын санап китә. Хәреф җыючыларның, башка хезмәткәрләрнең эшен җиңеләйтү юнәлешендәге тырышлыклары да телгә алына. «Мөселманнар өчен мондый көч куй-

ган кеше татарлар арасында да бармак белән генә санарлык», – дип нәтиҗә ясый «Шура».

Һәм бу бәяләмәдә һичнинди арттыру юк. Иван Харитонов империячел кибарлыктан азат чын рус зыялысы була. Ул «инородец»ларны хөрмәт итә, аларның телен һәм гореф-гадәтләрен яхшы белә. Шул сыйфатлары белән татарларның ихлас мәхәббәтен яулый. Бу кеше татар мәдәнияте һәм мәгарифе үсешенә үз өлешен кертү белән бергә, татар халкы турында телдә йөргән төрле ялган мифларның юкка чыгуына да сәбәпче була.

Дөрес, татар китаплары аңа кадәр дә нәшер ителгән. Ләкин нәкъ менә ул әлеге эшне беренче тапкыр һөнәри нигезгә куя, даими рәвештә китап басу ысулларын камилләштерә, яңадан-яңа шрифтларны гамәлгә кертә. Аның басмаханәсендә нәшер ителгән китап озак саклanырга тиеш! – Харитон бабайның төп максаты шушы була. 1909 елда, Харитоновның матбагачылык эшчәнлегенә 40 ел тулуны билгеләп үткәндә, матбугатта аны «татар Гутенбергы» дип олылыйлар. Ул вакытта аңа мәдхия яудырмаган бер генә татар газета-журналы калды микән? Татарның мәшһүр кешеләре аңа котлау телеграммалары юллый. Харитонов газеталарда басылып чыгасы рәсемнәренә түбәтәй киеп төшә...

Казанның гап-гади һөнәрче малае үзенең шундый уңышларга ирешәсен, бай һәм мәшһүр буласын күз алдына китерә алдымы икән? Әтисе байларга гомере буе экипажлар, кареталар ясаса да, башы нужадан чыкмый. Малай, ун яше тулуга, К.А. Тилле басмаханәсенә хәреф җыючы ярдәмчесе булып эшкә урнаша. Бер айдан Казан университеты типографиясенә күчә. Ни өчен нәкъ менә шушы һөнәрне сайлый ул? Абыйсы губерна идарәсе типографиясендә эшләгәнгә, Иван да әлеге һөнәр белән кызыксынып китә. Әтисе вафат булгач, Харитоновлар гаиләсе матди яктан бик авыр хәлдә кала. Иван исә гаять тырыш, максатчан үсмер була, укырга да өлгерә – Михайлов приход (мәхәллә) училищесын тәмамлый.

Басмаханәдә аның беренче остазы Ибраһим Кавалиев сөенеп туя алмый – сүзеңне ярты ымнан аңлап алган шәкерткә кем сөенмәс! Өч айдан ул инде Харитоновка тулы хезмәт хакы билгели. Бераздан яшь егет үзе яңа килгән эшчеләрне өйрәтә башлый һәм аның хезмәт хакы 15 сумнан 30 сумга күтәрелә.

Университет басмаханәсендә Иван Харитонов төрле телләрдә, хәтта монгол һәм яһүд телләрендә дә текст җыярга өйрәнә. Бу вакытта инде ул татар телен камил белә.

Егерме ике яшендә Харитоновны Казан губерна идарәсе басмаханәсенә өлкән хәреф җыючы итеп чакыралар. Бераздан яшь белгеч турында гел мактау сүзләре генә ишеткән типограф Г. Вечеслав аны үз басмаханәсенә мөдир итеп билгели [Кәримуллин, 1979, б. 63]. Иванга биредә үзенең сәләтен күрсәтергә бөтен мөмкинлекләр дә ачыла. Ул басмаханәне яңабаштан үзгәртеп кора: литография белән гальванопластиканы гамәлгә кертә, тиз баса торган машиналар сатып ала, реклама эшен җайга сала. Нәтиҗәдә басмаханәдә нәшер ителгән

китапларның саны өч тапкыр арта. Харитонов үзен кызганмый: аның өчен ял көннәре дә, бәйрәмнәр дә булмый, ул тәүлегенә унике сәгать эшли. Яшь мөдир бер генә вак-төяк нәрсәне дә күз уңыннан ычкындырмый, һәр эшне уз кулы белән башкарып карарга тырыша. Югары кимәлдәге полиграфия культурасы, фәнни-сәнәгать күргәзмәләрендәге бүләкләр аркасында басмаханә татар нәширләре һәм укучылар арасында шөһрәт казана. Кайбер елларда ул татар китапларын басу буенча Казан университеты басмаханәсен дә артта калдыра. Г. Вечеслав басмаханәсе 1882–1894 еллар арасында 225 исемдә татар китаплары бастыра. Аларның гомуми тиражы миллион ярым нөсхәгә җитә. Татарча гына түгел, монда гарәп, фарсы, азәрбайҗан телләрендә китаплар чыга.

Басмаханә хуҗасы яшь мөдирнең эшчәнлегеннән бик канәгать була, билгеле. 1893 елда ул аны, басмаханәләр эшен өйрәнү максатында Европа илләренә җибәрә. Ләкин бераздан, аңардан башка көймәнең комга терәлүеннән куркып, кире чакырып ала. Шулай да яшь белгеч Мәскәү һәм Санкт-Петербургның атаклы басмаханәләрендә булып, алардагы яңа җиһазлар, яңа эш ысуллары белән танышырга өлгерә.

Ә бер елдан цензура эзәрлекләвеннән гарык булган Г. Вечеслав басмаханәсен Б. Домбровскийга сатып җибәрә. Нәтиҗәле хезмәте өчен рәхмәт йөзеннән ул Харитоновка басмаханәдә нәшер ителгән татар китапларын бирә. Дүрт мең сумга бәяләнгән әлеге китапларны Иван тагын да кыйммәтрәк бәягә сата. Шуннан кергән акчага Пассажда үз басмаханәсен ачып җибәрә. 1898 елда Харитонов литография һәм китап төпләү бүлекләрен оештыра. Аңа кадәр бары тик ике татар шрифты булса, Харитонов аларны унсигезгә җиткерә. 1902 елда ул, басма һәм полиграфия эшендәге казанышлар белән танышыр өчен, кабат Европага бара – Вена, Дрезден, Лейпциг, Берлин басмаханәләрендә була [Кәримуллин, 1979, б. 63].

Татар нәширләреннән иң беренче булып аның белән язучы Г. Камал хезмәттәшлек итә башлый. Хезмәттәшлек чын дуслыкка әверелә. Г. Камал (ул бик шәп каллиграфист була) һәм гравер рәссам Ибраһим Юзеев белән Иван Харитонов гарәп-татар шрифтының яңа үрнәкләрен эшли [Габдельганеева, 2017, с. 201].

1904 елда Пассажда зур бер фатир бушагач, Харитонов, биш ел файдалану шарты белән, анда үз басмаханәсен урнаштыра. Бу вакытта инде аның кул астында алтмыш кеше эшли. Биредә китап бастырырга теләүче нәширләр арта һәм 1906 елда эшчеләр саны йөзгә җитә. Инде Харитон бабайга Пассаждагы фатир гына тар тоела. 1907 елда ул Воскресенская һәм Кече Казан урамнары кисешкән чатта (хәзерге Миславский ур., 4 йорт) өч катлы бина сатып ала. Бу тарихи йорт турында төрле риваятьләр сөйлиләр. Имеш, анда Сөембикә үзе яшәгән, имеш, Казанны яулаганнан соң Явыз Иван анда кунып чыккан. Харитонов аны яңадан сипли, җиһазлый. 1908 елның августыннан басмаханә шушы йортта үзенең эшен дәвам итә. Аның эшен

ун электр моторы тәэмин итә. Басу һәм хәреф җыю станокларыннан тыш биредә өч зур кәгазь кисү машинасы да була. Басмаханәдә сигез бүлек (басма, хәреф җыю, литография, татар газеталары, китап төпләү һ. б.) булып, алар һәркайсы аерым бүлмәләргә урнаша, бина пар белән җылытыла, электр белән яктыртыла. Барлык машиналар да диярлек электр моторы белән хәрәкәткә китерелә. Җылы, якты бүлмәләрдә хезмәт куйган эшчеләренә Харитон бабай лаек хезмәт хакы түли һәм аны елдан-ел арттыра.

XX гасыр башында Казанда күпсанлы газета-журналлар нәшер ителә башлый. Аларның байтагы Харитонов матбагасында басыла. Харитонов хәтта революцион эчтәлекле китапчыкларны бастырудан да курыкмый. Татарлар аны шундый кыюлыгы өчен дә яраталар.

«Яшен» журналы язганча, Харитоновның эшчәнлеге аркасында соңгы ун елда мөселман матбугаты бүтән алдынгы милләтләрнең матбугаты белән бер кимәлгә менә [Иван Николаевич Харитонов, 1909, б. 2–6].

«Чүкеч» журналы да Харитон бабайның таләпчән зәвыгына соклана [Словолитня И.Н. Харитонова в Казани, 1909, б. с.]. «Йолдыз» газетасы Иван Харитоновның эшчәнлегенә 40 ел тулу тантанасын татарларга да билгеләп үтәргә кирәк, дигән тәкъдим ясый. Без, дип яза «Йолдыз», урыс мөхәррирләренең, матбагачыларның игелекле эш белән әлеге юбилейны билгеләргә җыенуын ишеттек. Безгә дә бу эшкә кушылырга кирәк. Чөнки «Гутенберг варисы» – могтәбәр Харитонов әфәнде татар матбугаты өчен урысларныкына караганда да күбрәк көч куйган кеше. Үзенең Харитон бабайга булган мәдхиясендә «Йолдыз» купшы сүзләрне кызганмый, әгәр дә, ди, Харитонов булмаса, без мондый матур хәрефле татар матбугатына ирешә алмаган булыр идек. Ул эшне бер генә мөселман да башкара алмады, чөнки бер генә мөселман да ул кадәр акчаны моңа сарыф итмәс иде. Без бу юнәлештә ниндидер эш башлаган булсак та, бер җәмгыять төзүдән ары уза алмас идек. Харитонов аркасында без бүген алдынгы милләтләр сафына басуыбыз белән горурлана алабыз.

«Йолдыз» Казанның сәнгать мәктәбендә берәр мөселман баласы өчен Харитонов исемендәге стипендия булдырырга тәкъдим итә. Харитоновны шәрәфләгән берәр шундый игелекле эш өчен газета 50 сум күләмендә акча бирәчәген белдерә [Әхмәдһади, 1909].

Әмма мәхәббәт белән нәфрәт арасында бер генә карыш, дип дөрес әйтәләр шул. Харитон бабайга татарларның мәхәббәтен генә түгел, нәфрәтен дә татырга туры килә. Коръән китабы хаталар белән басылып чыккач, бөтен татар матбугаты кичә генә күкләргә чөелгән каһарманга ташлана. Кайберәүләр аны хәтта хөкем итәргә чакыра.

Мәгълүм ки, XX гасыр башына кадәр патша хөкүмәте татарларга үз басмаханәләрен ачарга рөхсәт бирми. Шуңа күрә татар нәширләре китапларны урыс басмаханәләрендә нәшер итәргә мәҗбүр була. Болар арасында Харитонов басмаханәсе аерылып тора. Ләкин

1913 елда Коръән китабы хаталар белән нәшер ителгәч, аңа мөнәсәбәт үзгәрә. Сүз уңаеннан әйтик: Харитон бабай, беренчеләрдән булып, Изге китапны коленкор тыш белән чыгара, бәясен дә арттырмый.

Ә кайбер мөселманнар фикеренчә, Коръәнне хаталы итеп бастыру – җинаять. Югыйсә матбугат эшендә хатадан хали булу мөмкин түгел.

Коръәнне хата белән басу очраклары элек тә булган. 1856 елда, мәсәлән, Кукубин басмаханәсендә ул 356 хата белән нәшер ителә. Әмма бу вакытта татарларның әле көндәлек матбугаты булмаган һәм алар ризасызлыкларын бөтен дөньяга белдерә алмаганнар.

Харитоновны матбугатта беренчеләрдән булып Фатыйх Әмирхан «фаш итеп» язып чыга («Кояш», № 24, 14.11.1913). Матбагачы шунда ук «бозылган» Коръән нөсхәләрен яңа басмалар белән алмаштырачагын белдерә, һәм «алда мондый хаталар ясамаячакмын», дип сүз бирә. Ләкин татар матбугатында һөҗүм көчәя генә. Харитонов бу хаталарны очраклы рәвештә ясаганмы, әллә махсус шулай хаталы чыгарганмы? Шунысын да истә тотарга кирәк, бу вакытта инде Харитон бабайга көндәш татар матбагачылары пәйда була. Харитонов хаталарның басмаханә хезмәткәрләре Ризван Шәрипов белән Зиннәт Гыйсмәтуллинның башбаштаклыгы аркасында китүен дә аңлатып карый. Ләкин хаталы китапларда текстның Диния нәзарәте вәкиле Сафиулла Габдуллин тарафыннан тикшерелүе һәм хуплануы турында искәрмә ясалган була. Ә Габдуллин корректураны кулына бөтенләй тотып та карамаган! Алдагы басмаларда исеме күрсәтелгәч, матбагачы монысында да әлеге искәрмәне шул килеш калдыра. Мөгаен, Коръән-Кәримгә ихтыяҗ зур булганга (Россия буйлап аның елына уртача 200 мең нөсхәсе тарала), матбагачының дин белгеченнән изге китапны яңадан укытып вакыт әрәм итәсе килмәгәндер. Үз хезмәткәрләренә артык ышану бәласе. Билгеле, Сафиулла хәзрәт хаталы китапта үз исеме торганга гаять гарьләнеп, Диния нәзарәтенә бу эштә катнашы булмавы турында аңлатма яза. Аны Харитон бабайны мәхкәмәгә бирергә дә котырталар, ләкин хәзрәт бу адымга бармый [Казанско-татарские.., 1913, с. 401–409].

Вакыт узу белән әлеге шау-шу тына, әмма ул Харитон бабайның күңелендә үз эзен калдыра, билгеле. Ни генә булмасын, эшмәкәр 1916 елда басмаханәсен сата һәм матбугат эшеннән читләшә. Бу гамәлнең, әлбәттә, бүтән сәбәпләре булу ихтималы да бар. Беренче бөтендөнья сугышы вакытындагы икътисади кыенлыклар аркасында кайберәүләр бөлеп, ә кайберәүләр, киресенчә, баеп китә.

Тәҗрибәле матбагачы басмаханәсе ябылгач та кул кушырып утырмый. Хезмәттәшләре аның киңәшләреннән теләп файдаланганнар. НЭП заманында ул хосусый басмаханә ачарга талпынып карый. Әмма аңа рөхсәт бирмиләр. Заман инде Харитон бабайныкы булмый.

«Гутенберг варисы»ның бу чордагы тормышы безгә мәгълүм түгел диярлек. Таушалган шинель киеп йөрүе турында гына кемнеңдер

өзек-төтек истәлеге бар. Күрәсең, бөлгенлектә яшәгәндер. 1927 елда Харитон бабай вафат була.

Татар матбугаты тарихында тирән эз калдырган бу чын урыс зыялысын без бүген дә хөрмәт белән искә алырга бурычлы.

**Әдәбият**


Юкаруда тәгъриф итдемекебез ... // Шура. 1908. № 24. Б. 776.

*Кәримуллин Ә.* Китап дөньясына сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 208 б.

*Габдельганеева Г.Г.* Харитонов И.Н. // Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. А.М. Мазгаров, ответ. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2014. Т. 6: У–Я. С. 201.

Иван Николаевич Харитонов (1869–1909) // Яшен. 1909. № 10. Б. 2–6.

Словолитня И.Н. Харитонова в Казани. Образцы мусульманских шрифтов. Казань: Тип. И.Н. Харитонова, 1909. Б. с. Правила внутреннего распорядка в литотипографии.

*Әхмәдһади.* И.Н. Харитонов // Йолдыз. 1909. 16 апрель. № 387.

Казанско-татарские газеты за ноябрь месяц 1913 г. // Инородческое обозрение (приложение к журналу «Православный собеседник»), 1914. Кн. 6-я. С. 401–409.



***Ахунов Азат Марс улы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирасы үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Г. Газиз*

# МИЛЛӘТНЕ НИЧЕК ТӘГЪРИФ КЫЛЫРГА?

В 1913 году в журнале «Аң» была опубликована анкета «Как вы определяете понятие “национальность”?». Среди вопросов, включенных в состоящую из 15 пунктов анкету, были следующие: 1. Каково научное определение, научный смысл понятия «национальность»?; 2. Что составляет основу национальности?; 3. Как национальность связана с религией и родиной?; 4. Какое значение имели и имеют понятия «нация» и «национальное чувство» в прошлом и настоящем нашего народа и др.

В последующих номерах журнала (за 1913 и 1914 гг.) один за другим печатаются развернутые ответы на поставленные вопросы, авторы которых – представители татарской интеллигенции (Г. Губайдуллин, С. Вильданов, Г. Шараф, З. Кадири и др.) рассуждают о концептах «нация» и «национальность», о положении наций в современном мире, о национальной идентичности татар.

Многообразие точек зрения на поставленные вопросы у респондентов свидетельствует об их значимости и дискуссионности в татарской интеллектуальной культуре указанного периода.

**Ключевые слова:** Г. Газиз, нация, национальность, национальная идентичность, татарская литература, культура, история.

In 1913 a questionnaire «How do you understand the nation?» was published in the magazine «Ang». Among the questions included in the 15-point questionnaire were the following: 1. What is the scientific definition, the scientific meaning of the concept «nationality» ?; 2. What is the basis of nationality ?; 3. How is nationality related to religion and homeland ?; 4. How important are the concepts of «nation» and «national feeling» in the past and present of our people, etc.

In subsequent issues of the journal (for 1913 and 1914), one after another detailed answers to the questions posed was published. The authors of them, representatives of the Tatar intelligentsia (G. Gubaidullin, S. Vildanov, G. Sharaf, Z. Kadiri, etc.) talk about concepts of «nation» and «nationality», the position of nations in the modern world, the national identity of the Tatars.

The diversity of points of view on the questions posed by the respondents testifies to their importance and debatability in the Tatar intellectual culture of the specified period.

**Keywords:** G. Gaziz, nation, nationality, national identity, Tatar literature, culture, history.

Милли әдәбиятыбызның гареблекенә охшап тууы соңында әдәбиятымызда «милләт, миллият» сүзләре күп истигъмаль ителә *(кулланыла)* башлады. Бу истигъмаль бездә ике төрле: беренчесе миллиятне, кәлимәнең мәгънәви мәгънәсе белән алданып, дин мәгънәсендә истигъмаль булып, икенчесе исә яурупалыларның «национ, нация» сүзләре урынында истигъмаледер.

Ләкин чын милләтче [динче түгел] әдипләремез ничек дә соңгы мәгънәсе белә истигъмаль итәләр. «Нация-милләт» үзләре нәрсә,

боны гареб галиме ничек аңлый мәсьәләләренең чын нәзари кыйсме әдәбиятымызда бу сүзләр чыккач, аңлау өчен бик кирәк булганга, бу кыска гына мәкаләдә дә бу тугрыда бераз язмак булам.

Милләт нәрсә соң?

Милләтнең иң гамь тәгърифе «инсанларның җыеныдыр». Ләкин бит бу тәгърифкә җамигъ[1], дәүләт[2], сыйныф вә башка кешеләр җәмгыятьләре кергәнгә күрә, «милләт» мәфһүменең (*эчтәлегенең*) «хасса»сы (*үзенчәлеге, хасияте)*, ягъни шунда гына булып да башка мәфһүмләрдә булмый торган бер нокта табарга кирәк була.

Шактый гына милләтләрнең бер динле, бер дингә ышанганларын күрергә тугры килә, шуңар күрә дә милләтнең хассасы «дин» түгелме мәсьәләсе хәтергә килә. Ләкин немесләр [алманлар] кеби нык бер милләтнең яртысы протестант, яртысы католик булганларын күрәмез. Әле генә туып килә торган албан милләтенең өч дингә мәнсүб булганлыкларын күрә дә – менә шушы нәрсәләр бу ихтималны йибәрәләр; дин, милләтнең тәгърифенең хассасындан түгел икән дияргә мәҗбүр буламыз. Ләкин башка милләтләр белә күрешкәндә «дин»нең әһәмияте юк дия алмыймыз. Чөнки халкына, аның мәдәниятенең дәрәҗәсенә күрә дин шактый гына милләтләрнең куәтләнүенә, башка милләтләр белә көрәшүләрендә ярдәм итә. Вакыйган, без татар-төрк милләтенең Волга буендагыларның милләтләрен саклауда исламның зур гына файдасы [3] булганлыгын күрәмез.

Хәзер тере булган, хәзер аның белә сөйләшә торган телнең дә милләтнең хассасындан диеп булмыйдыр. Чөнки факт шуны күрсәтәдер: яһүдиләрнең Испаниядәгесе испаниячә сөйләшәләр, Русия вә Германиядәгеләре нимсә вә яһүдчәдән катышкан махсус бер тел белә сөйләшәләр, Фәләстыйндәгеләре исә гарәбчә сөйләшәләр. Кем инде яһүдиләрне милләт димәс? Бездәге татарлар да, төркчә белмәгәнләренә карап, үз милләтемездән димәмезме? Шуның шикелле үк бер тел белә сөйләшә торган халыкларда да аерым, хәтта күб вакытда дошман милләтләр очрата аламыз: Шимали (*төньяк*) Америка һәм инглизләрнең телләре бер – әмма шактый гына дошман милләтләр. Җәнүби (*көньяк*) Америка белә Испаниянең телләре бер, әмма аерым милләтләр. Серблар белә каратаглыларның телләре бер-берсенә бик якын, әмма үзләре – аерым милләтләр. Бу – мәсьәләнең нәзари җәһәте. Әмма политикада милләтләргә тел бик зур файда итә. Мәсәлән, венгрларның немесләр белән тартышлары император Йосыф II заманында тел мәсьәләсендә чыкды, милли көрәшләрнең иң зур «мәүзуг-темасы» тел мәсьәләсендә була. Албанлар төрекләр белән

---

[1] Мин бу сүз белән бер дингә иман иткән кешеләрнең җыенын [совокупность] *(кирилл хәрефләре белән*) аңлыйм, әмма теге мәсҗед – җамигъ түгел (*Г. Газиз искәрмәсе*).

[2] Бу мәгънә белән мин: государство (*кирилл хәрефләре белән*)ны аңлыйм, хөкүмәт русча правительство (*кирилл хәрефләре белән*)га мәсави буладыр, шуңар күрә бу сүзне истигъмаль итмим (*Г. Газиз искәрмәсе)*

[3] Бу тугрыдагы тәфсиллерәк фикерне «Аң»ның мәүлүд номерында «Ахырзаман пәйгамбәре тугды»да табарга мөмкин (*Г. Газиз искәрмәсе*).

милли тел, милли язу өчен низаг башладылар, боның кеби мисалларны тарихдан һәм хәзерге тормышдан күб табарга мөмкин.

Ләкин безнең мәсьәләмез нәзари мәсьәлә булганга, әле куеп торыйк.

Соң алай булгач, дәүләт милләтнең тәгърифенә махсус нокта булыр? Боңар да без «юк» җавабын бирергә мәҗбүр буламыз. Дөрест, Франция ихтиляләндән (*фетнәсеннән*) соң Яурупада миллият-дәүләт икесе бер нәрсә булырга кирәк; дәүләт бер милләтдән генә мөрәккәб (*оешкан*) булырга кирәк, дигән нәзарияләр бар иде. Кыйсмән, шул нәзарияләрнең куәте белән Италияне вә башка хөкүмәтләрне башкалар кулындан котылдырдылар. Ләкин Италиянең егерме биш, утыз ел үтмичә Сомали кыйтгасы өчен Хәбәш (*Эфиопия*) белә сугышуы, Шимали Американың Филиппин атауларын алуы бу нәзариянең юк нәрсә икәнен күрсәтде: чөнки, табган (*табигый*), дәүләт һәм милләт икесе ике нәрсә иде. Дөрест, бәгъзе милләтләр бер дәүләт генә тәшкил иткәнләре бар (Бельгия, Голландия), ләкин Англия, Русия, Австрия шикелле дәүләтләр, күп милләтләрдән мөрәккәб булганына карамыйча, яхшы тәрәккый итәләр.

Димәк, алай булса, милләт инде бер гыйркдан (*ырудан*) килгән халыкларның җыены була?

Гыйрк үзе – милләт шикелле үк, бик низаглы бер мәсьәләдер. Аны бер галим бер төрле тәгъриф итсә, башкалары башкача тәгъриф итәләр. Бәгъзеләр адәмләрнең җәсәдләре бер төсле булуын игътибарга алсалар, башкалар, җәсәди бертөрлелек хәзер бик сирәк халыкларда табылганга, гыйркны тәгърифдә телне игътибарга алалар. Ләкин гыйркны ничек генә аңламыйк, бар да бер гыйркдан булган халыклар әллә никадәр милләт тәртиб итәләр (Кушма Америка һәм Англия, руслар һәм поляклар.). Шуның шикелле үк аерым гыйрклардан булган кешеләр дә бер миллият тәшкил итәләр (Франсадәге французлар һәм кельтлар, Шимали Америкадагы англосакслар һәм зәнҗиләр вә башкалар.)

Португалия һәм Испаниянең телләре бер, гыйрклары бер була торып да, икесе ике милләт ясыйлар.

Мадам ки (*чынлыкта*) бер тел белән сөйләшә генә торган кешеләрне яисә бер дин белә генә мөшәррәф кешеләрне, я бер-бер гыйркдан килгән кешеләрне генә без бер миллият дип әйтә алмыймыз, мадам ки, дин, гыйрк, тел, дәүләт милләтнең махсус ноктасындан түгел, безгә, миллиятне тәгъриф итү өчен, башка бер махсус нокта эзләргә кирәк була.

Эрнест Ренан кеби галимләр боңар бер юл тапмакчы булдылар: анлар тарихи ганганә (*традиция*) – миллиятнең махсус нокталарындан берсе, диделәр. Вакыйган, бу мәсьәләгә игътибарга алырга ярый. Бер дә шиксез, миллият – тарихның сәмәрәседер (*җимеше*): тарих миллиятне миллият ясый; бер галим әйткәнчә, бер милләтгә мәнсүб (*караган*) кешеләр арасында, иске берлекләрне искә төшереп, бер «симпатия-ярату» ясала. Тарихи ганганәләр күб вакытда көрәш, мил-

лият өчен башка милләтләр белә мадди я мәгънәви тартышдан хасил була. Менә шушы тартышда бер милләт балалары эчендә «интерес» (бер-береңә кирәклек берлеге) ясый. Бу исә милләтнең тормышына иң кирәкле нәрсәдер.

Мәшһүр Эдвард Майер милләт рухы бер җәмгыять булып, «ихтыяр»га бинаән кылынган (*нигезләнгән*), ди. Ягъни бер-бер халык үзенең миллият булуы өчен, әлбәттә, хәрәкәт лязем, ди. Бу нокта бер милләтнең тормышында шактый мөһим булса да, «ихтыяр»ны миллиятнең хассасындан дип әйтеп булмый [1], чөнки бәгъзе хезмәт сәнәгый союзларында да ихтыяр-хәрәкәт булырга мөмкин, әмма алай да миллият булмыйдыр бит. Шуңар күрә дә бу ноктаны чын нәзари тәгърифкә кертергә мәгъкуль түгел.

Соң ничек тәгъриф кылырга?

Алда әйтелгәнчә, миллият кешеләрдән мөрәккәб була, шуңар күрә кешеләр җыены димез.

Милләтнең асыл тарихы ганганәләргә, хатирәләргә терәлгән була: кешеләр бер-берсенең якынлыгын хис итәләр, һәркайсының бабасының бабалары вә нәселләре бер дошманга – дошман, бер дуства – дуст, бер йирдә торганга яисә бергә күчеп йөргәнне халык тарихи җырлары кыяфәтендә күңелдә саклыйлар. Шулай итеп, без миллияткә хәзер рухи бер тәгъриф бирәмез: миллият – тарихи ганганәләргә бер булып, берлек хис иткән адәмләрнең җыеныдыр.

Икенче мәкаләмездә миллиятнең зоһурындан бәхәс итәчәкмез. Хәзергә шунда туктыймыз.

*Мәкалә 1913 елда «Аң» журналының*
*8 нче санында (10 апрельдә)*
*басылып чыккан*

## МИЛЛӘТНЕ НИЧЕК АҢЛЫЙСЫЗ? МӨКАДДӘМӘ *(КЕРЕШ СҮЗ)*

Мажар милләтенең хокуклары өчен немесләр белән көрәшкән мәшһүр Кошут мондан илле ел элек менә ни нәрсә бар иде:

«Милләтләрнең тормышлары әле моңар кадәрле бары трактатларга гына бинаән кылынган иде, әмма хәзер исә милләтләрнең хокукларының үсүен күрергә тугры килә, анларны әле тәгъриф кылырга өлгермәделәр, бу миллият әсаслары бик яңа булып, кичә генә дөньяга килсәләр дә, бөтен галәмне селкетәләр. Бу яңа әсаслар шул кадәр аңларны мәсхәр кылдылар ки, алар белә хәзер бик ныклап хисаплашырга тугры килә; ул әсаслар хәзер падишаһларны һәм халыкларны хәрәкәткә китерә ки, аңар каршы йөри торган шактый гына кешеләр дә киләчәк көн миллият әсаслары өстенә корылачак дигән

[1] Ихтыяр русча воляга (*кирилл хәрефләре белән*) тугры килсә дә, мин бу сүз белә бу урында активностьны аңладым. Чөнки татарча сүз таба алмадым (*Г. Газиз искәрмәсе*).

сизенү бар». Бу мөхтәрәм картның сүзе дөрест, бәгъзеләр өчен ачы, әмма безнең өчен тәмле бер хакыйкать! Ничек итеп бу фикергә ышанмаска? Бу миллият әсаслары бөек Наполеонны, аның хәдсез-хисапсыз батыр гаскәрләрен җиңмәделәрме? Миллиятләр бөек Төркия императорлыгының аяк вә кулларын кисмәделәрме? Ниһаять, бөек инглиз милләтен күз алдымызда Ирландия халкына милли-тарихи хокукларын бирергә мәҗбүр итмәделәрме?

Нигә яңа милләтләр, яңа дәлилләр һәммәсе дә күз алдымызда! XIX гасырның бөтен тарихы миллият көрәшендән туган түгелме? Бу гасырның тарихын ач, укы, һәр битендә бер миллиятнең башкасы белән үзенең мөкаддәс хокуклары өчен низаглашканын күрәсең! Бу миллият дулкыны безгә дә килеп бәрелде. Әле сиксәненче елларда гына миллият мәсьәләсенең мөтәхассыйсларындан *(белгечләреннән)* Райновский (?) безне чирмешләр рәтенә куеп, безнең хакда итальян Манчининың сүзен алып: «Аларга әле тереклек рухы өрелмәгән, әмма торырга мөстәгыйд (*сәләтле*) маддәләр», – дип яза иде, шундан ярты гасыр үтмәде, Бобровников күк татарларны белә торган кеше безнең хакда, безне миллият санап, безгә XIX гасырның миллият рухы кергәнен үзенең яңа бер әсәрендә икърар итде *(таныды)*!

Дөрест, без – хәзер чын миллият, безгә хәзер мәдәниятнең җанлы уты керә башлады, үземезнең мәдәниятемез дә уянды. Без моны икърар итәмез.

Яңарган «Аң»да миллият мәсьәләсенә анкета сурәтендә чын нәзари әһәмият бирә башлау да – шактый гына сөенечле бер мәсьәләдер. Чынлап да, мадам ки (*чөнки*) без мәдәни бер милләт булып, бөек ватанымыз Русия гражданы буласымыз килә, ничөн безгә үземез теләгән нәрсә «миллият»нең мәгънәсен чынлап аңларга керешмәскә?

I

Милләтне ничек тәгъриф кылалар, ул нәрсә? Миллият – гыйрк (*ыру*), дин вә башка шундый мәфһүмләр (*төшенчәләр*) күк, һәммә милләтләр өчен гомуми бер нәрсәдер, француз да – бер милләт һәм аны милләт дип атый, нимес дә шулай ук, шуңар күрә иң әүвәле без бу мәсьәләгә даир язылган әдәбиятдагы төрле тәгърифләрне җыеп, шуларга бер карыйк.

Миллияткә Яурупа галимләре тарафыннан бирелгән йөзгә якын тәгъриф бар[1].

Кыскача гына әйткәндә, тәгърифләрне шулай бүләргә мөмкин: тәгърифдә бер генә хасса (*үзенчәлек*) була яисә тәгъриф берничә хассадан мөрәккәб була (*оеша*), тәгърифдә вөҗдани-рухи хасиятләргә генә әһәмият бирелә (яисә мадди хасиятләргә генә), ниһаять тәгъриф ике төрле хасиятләрдән дә мөрәккәб була.

Башлыйк картрак, элегрәк бу мәсьәлә белә шөгыльләнгән галимләрнең тәгърифләрендән:

---

[1] Системы политического равновесия и легитимизма и начало национальности. С. 270

Вустин үзенең «Ихтиляллар кануны» исемле әсәрендә «милләт тарихы – фатализмга[1] бирелгән бер төркем кешеләрнең җыеныдыр», – ди.

Буше (?) («Яурупалылар») миллиятне шулай тәгърифкыла: «Миллият – бер факт яисә хис. Анлар – бер максадның сәмәрәсе һәм гасырларча бер төрле максадны тәгъкыйб итүнең (*күздә тоту*) нәтиҗәседер».

Стюарт Мил: «Миллият дип, йир якынлык хисе белә дә берләшкән кешеләргә әйтәләр ки, ул тойгы ике ят милләт кешеләре арасында булмыйдыр», – ди.

Ричард: «Үзе генә адәмне хасил итә торган ганасыйрны (*өлешен*) канәгатьләндерә алырлык гүзәл вөҗдан кануны ясау өчен, кешеләрнең иҗтимагый уларак берләшүләре», – ди.

Паскаль-Фиоре: «Миллият – кешеләрнең мохтар (*ирекле*) ирадә тәэсире белән булган җыены, чын милләт бары үзен шул милләтдән дип хисаплавы һәм ирекле булуы шарты белә генә чын милләт була ала», – ди.

Рус галимләрендән Данилевский шулай тәгъриф кыла: «Мәгълүм бер йирдә дә бер нәселдән, бер телдән, кыйсмән, бер гадәт һәм җолалы, үзләрендә берлек тоя торган, үзләренең иҗтимагый тормышларында бер максад тәгъкыйб кыла (*күздә тотыла*) торган кешеләрнең табигый берләшүедер».

Хәзердә заманның тәгърифенә килик. Ул бик кызык һәм шактый гына әһәмият бирерлек бер тәгъриф бирә. Ул «миллият – рух, рухи бер принцип», дип, «рухи» хасиятләргә әһәмият бирә. Шуңар күрә дә ул «кеше үзенең гыйркының, теленең дә, диненең дә, елгаларының агымының да, таулар силсиләсенең дә кайу тарафка китүенең дә колы түгел. Кешеләрнең зур төркеме таза рух, йөрәкнең кызуы – менә шулар вөҗдани бер аң ясыйлар ки, шуны милләт диләр», – ди.

Мәшһүр хокукшинас Георг Еллинек да алда әйтелгән төслерәк тәгъриф биреп, «күп гомуми мәдәни гонсырлар һәм гомуми тарихлары да бер булу белә оешкан, башка кешеләрдән аерыла торган кешеләр төркеменә милләт ди.

Рус галимләрендән Лавров милләтдә менә шушы хассалар күрә: бергә охшый торган рухи хасиятләр, гадәтләр, җолалар, башка милләтләр белә тормыш өчен көрәш, нәселдән нәселгә күчә торган идеяләр. Аның фикеренчә, милләт – тарих вә мәдәниятнең бер булуның сәмәрәсе.

Австрия социологларындан Людвик Һумплович милләтне (nationalitat) шулай тәгъриф кыла:

«Үткәнләре, телләре бер булып, төрле гыйркдан (яисә катыш гыйркдан) мөрәккәб булган бер җәмгыять. Ул исә – тарих вә мәдәният һәм падишаһлыкның тәрәккыенең сәмәрәсе». Нимес мөаррихләрендән (*тарихчыларыннан*) Эдвард Мейер миллиятнең хассаларын «их-

[1] Richard Etude sur ies Nationalites. Алдагы өч тәгъриф янә шушы әсәрдән алынган (*Г. Газиз искәрмәсе*).

тыяр, идея»ләрдә күрә. Аныңча, берләшергә, берлек ясарга теләгән кешеләрнең төркеме миллиятне тәртип итәләр. Миллиятләр үзләрен бер максадка таба хәрәкәтдә күрсәтәләр.

Хәзергә Яурупа әдәбиятында бәгъзе мөһим тәгърифләрне күрдек. Болардан кайсы дөрест, кайсы ялгыш? Табигый, үз нокталарындан һәммәсенең тәгърифе дөрест. Ләкин мин төрле сүзләр беләң ифадә кылынган *(аңлатылган)* ул күп тәгърифләрдән сыгылып чыкган һәм гамәлият дөньясының барышына муафыйк булган шул тәгърифне тәкъдим идәм:

– Милләт – тарихи ганганәләре бер булып, үз араларында берлек хис кылган, бер юл тоткан – бергә хәрәкәт иткән һәм бер даирәдәрәк яшәгән яисә тарихда күп вакыт бергә торган, асыл телләре бер булган ифрад *(ялгыз)* адәмнең җәмгыятедер.

Икенче сөаль ошбу рәвешдә куелган:

Миллиятнең тарихда вә хәзерге хәятдә тоткан урыны? Үткәннең караңгылыгы арасында бер төркем кешене падишаһлык тәртип кылган халәтләрендә тотып аламыз: бу халык бер йиргә утырган яисә бер мәгълүм йиргә күчеп йөри яисә әүвәлге ватаныннан яңа йир яки су, яңа бәхет эзләр өчен күчеп йөри. Бу халык бер төрле югарыгы куәткә буйсынган. Бу халык бергә тора, бергә күчә, бергә зәхмәт чигә, бер-берсен бик яхшы белә.

Бу халык үзенең гадәтләре, җолалары белә тора, бер дошман белә сугыша, бөтен мәшәкатьне бер төркем кеше бергә чигәләр. Менә боларда бер төсле уй ясала: чөнки болар күп мөһим эшләр тугрысында бергә уйларга мәҗбүрләр. Боларда бер төсле җырлар туа, бер төсле көйләр чыга – чөнки болар бер төрле тойгылар беләң, бер төрле хозур табу беләң бер-берсенә бәйләнгәнләр. Болар бер төсле дә сөйләшәләр.

Менә шулай торган вакытда бу төркем үзенә бер идея ясый, бер фикер тәртип итә.

Дөнья бит бер төсле генә тормый: бу төркем икенче беләң очраша, аның беләң бер нәрсә өчен сугыша, ул сугышдан бу төркем яисә җиңеп чыга да, җиңелгәнләрне үтерә яисә аларны үзләре төсле уйламаганга – анларны вәхши дип карый, аларны үзләренә Алла тарафыннан кол булырга яратылган дип атый...

Яисә бу төркем үзе җиңелә: башка төркемгә әсир була. Ләкин анда теге тойгылар, теге үзләренә махсус ничә замандан бирле «берлекдән» килгән уйлар, «идеяләр» бетми, алар һәрвакытда үзләренең мөкаддәс нәрсәләре өчен үләләр, тегеләр аларны бер дә кызганмый үтерәләр...

Менә сиңа хаким милләтләрнең зоһуры (*килеп чыгуы*), менә мәхкүм *(ирексез)* милләтләрнең килеп чыгуы!

Берсендә хөкүмәт белән миллият җыела, икенчесендә мәгълүб (*аста калган, җиңелгән*) төркем теге галиб кешеләрнең ясаган хөкүмәтенә керсә дә, һаман да миллият идеясе бетми. Мәхкүм милләт бәгъзән (*кайвакыт*) тәрәккыйнең югарыгы баскычларына хөкүмәт белә миллият бер нәрсә түгел икәнен аңлап котылу, үзләренә я «милли

хөкүмәт ясау фикерендән ваз кичә, ләкин анда гомеренә бөтен хәяте буенча миллиятне «мәдәни» мәгънәсе белә аңлау бетми. Мәхкүм милләт, бара торгач, үзенең мәхкүмлегене оныта, хөкүмәт берлегенә каршы килми, хаким милләтләр белә бергүк үзләренең йирләрен гомуми «дәүләт» дошманындан саклый, канун куя. Ләкин һаман да мәдәни уларак тартышуны: үзенең милли теле, милли дине, милли җоласы, милли мәдәнияте өчен көрәшүне бетерми. Хаким милләт боларның берсенә дә тими икән, ул аның белә кул кулга тотышып, гомуми падишаһлык файдалары өчен бергә тырыша. Бергә канын, бергә малын куя: аның белән бәгъзән (*кайвакыт*) кардәшләшеп китә. Гомумән, уйлаганда дөньяның мәдәният выставкасына милләтләр яңа мәдәниятләрен куялар, бәгъзеләре исә бөтен инсаниятне котылдыра торган фикерләр, идеяләр чыгара, шулай итеп, кайчакда мәдәниятне алып баручы бер «орган» булып китә. Мондый халәтне без күп яхшылыкларга Яурупаның күп тәрәккыятенә сәбәп булган XVIII гасыр Франсә вә фәлсәфә әдәбиятында күрәмез. Ләкин яхшы миллият һичбер вакытда бер фикер, бер идея, бер гомуммәдәният тудыру белән калмый, алар аны яңартып тора, яхшыларын чит мәмләкәтләрдән ала; моның гакәсе (*киресе*) хәлендә миллият искелек тәдәнни (*артта калу*) органы булып китә дә, миллиятләрен югалта. Бу табигый уларак туган мәдәният, фикерләр, бара торгач, мөстәгыйд (*сәләтле*) миллиятләрдә яңартылып, сәнгый уларак шуны шагыйрьләр язып салып, сөйләп, шул фикерләрне галияләшдерә, галимләр гакылга нәселдән нәселгә калдырыла: шул миллиятнең әгъзаларына өйрәтәләр.

Бәгъзе вакытда тәрәккыйгә мөстәгыйд, мәңгелек миллиятләр үзләренең махсус идея-мәдәниятләренә яңа нәрсәләр кушалар, менә без моны XIX гасыр яһүдиләрендә күрәмез, аларның социализм күк бәйнәлмиләл бер фикергә хезмәт иткән йөзләрчә яһүди галимләре, публицистларының әсәрләрендә күрәмез, чөнки бу аларга файдалы иде: җирсез-сусыз, урынсыз яһүдиләргә гомуми инсаният әсарәтдән (*коллык*) котылса гына? Котылу бар икәнен анлар сизәләр иде. Хәзер аерылган һәр якга читләр эченә җәелгән төрле төрлек кавемләре эчендән дә яңа бер фикер туганын күрергә мөмкин...

Бәгъзе вакытда миллиятләр адәмләр күк картаеп китәләр, ләкин алар аерым кешеләр күк табигый үлем белә үлмиләр: чөнки миллият – күбрәк, табигать баласы булудан бигрәк, мәдәният тарихының баласыдыр! Бәгъзән тарихның җылы җиле исеп китә: миллият шул чакда яңадан мәңге суы эчкән Хозыр пәйгамбәр күк яшәреп китә. Яңадан тарих мәйданына атыла: инсаниятнең тәрәккыенә зур хезмәтләр ясап ташлый. Менә моның мисалын яңа уянган кытай милләтендә күрәмез.

Миллиятләрнең тарихда әһәмияте хакында сөйләгәндә, шуны да әйтеп китәргә кирәк ки, бәгъзән мөаррихләр бөтен тарихе гомумиянең миллиятләр көрәшендән, аларның тәрәккыендән гыйбарәт идекене, шуңа күрә тарих фәненең баш мәүзугы шул идекене дәгъва итәләр вә шул юлда тарихи әсәрләр язалар.

Фикеремчә, мондый әсәрләр тарихи-гыйльми әһәмияте белә бергә, бер дә шиксез, милли зур әһәмиятне хаиз (*ия*) булалар: әдәбиятымызда да чыгуы бик теләнәдер.

Алда без хаким милләтләр, мәхкүм миллиятләр дигән идек, моның кайсысы соң чын миллият?

Фикеремчә, мәхкүм миллият – чын миллиятдер, чөнки хаким милләтдә күп вакытда, миллият булуыннан бигрәк, «дәүләт» булуы хис ителәдер. Хис генә түгел, хәтта факт – вакыйгалар шуны күрсәтәләр: караңыз сез итальянларны, әле бит анларның Австрия кулындан котылганларына күп дә үтмәде, хәзер итальян халкы, бер милләт булудан бигрәк, «дәвале могаззәмә»дән (*бөек дәүләтләрдән*) берсе булырга азаплана. Үзе, котылыр-котылмас, Хәбәш белән Кызыл диңгез кырыен алу өчен сугышды. Бары немесләрдән генә котылырга теләгән милләт (итальянлар) хәзер үзләре гарәбләрне җиңделәр. Әлхасыйль, дәүләтләрнең табигый нәрсәсе аннексиягә таба барудыр; әмма миллият ноктаи-нәзарыннан бу бер кабәхәт эш: чөнки икенче бер милләтне кол ясау димәкдер. Моңар мисал бик күп, әле 30–40 еллар гына Балкан дәүләтләре – милләтләре хәзер үзләре милләт хакимәнеңдә иң каһәрлесе булып китделәр.

Миллиятләрнең тарихда әһәмиятләре тугрысында алда әйтелгән бәгъзе мәсьәләләрне сөйләү белә генә иктифа итәм (*канәгатьләнәм*). Чөнки бөтен тарих сәхифәсен актарып, әһәмияте тугрысында сөйли башласак, алда сөйләгән «миллият ноктаи-нәзарыннан тарихе гомуми» чыгачакдыр.

Миллиятнең хәзерге әһәмияте хакында мин сөйләп дә тормыйм: чөнки гасырымыз – миллият һәм сыйнфый көрәш гасырыдыр. Ләкин соңгы көрәш «милли хискә» һәрвакыт урын биреп бара...

*Мәкалә 1913 елда «Аң» журналының 22 нче санында (17 ноябрьдә) басылып чыккан*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре* ***Гарипова Ләйлә Шамил кызы*** *һәм* ***Әхмәтова Айгөл Илфак кызы*** *әзерләде*

УДК 82-95

***А. Фәтхи***

# ҮТКӘН ГАСЫРЛАРНЫҢ ШИГЪРИ СӘХИФӘЛӘРЕ

Читателю предлагается первая архивная публикация статьи татарского археографа Альберта Фатхи (1937–1992) об анонимной татарской поэзии XVIII–XIX вв. В статье приводятся тексты отдельных стихов, извлеченных из рукописей, а также подробные историко-филологические комментарии к ним. Эти стихотворные фрагменты представляют большой интерес для изучения народной книжности и бытования литературных текстов в широкой среде мусульман Российской империи.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, анонимная поэзия, *китга,* татарские рукописи.

The reader is offered the first archival publication of an article by Tatar archeographer Albert Fathi (1937–1992) about anonymous Tatar poetry of the $18^{th}$–$19^{th}$ centuries. The article contains the texts of individual poems, extracted from manuscripts, as well as detailed historical and philological comments on them. These fragments of poems are of great interest for the study of folk literacy and the existence of literary texts in a wide circle of Muslims of the Russian Empire.

**Keywords:** Tatar poetry, anonymous poetry, qit‘a, Tatar manuscripts.

## Кереш сүз[1]

Билгеле булганча, фән ул тар милли кысаларга гына сыеша алмый, үз асылында ук халыкара рухлы хезмәт булып кала. Шулай да дөньяда төрле милләтләрнең үз фәнни традицияләре бар. Татар халкының да гуманитар өлкәдәге традицияләре – бигрәк тә тел, әдәбият һәм тарихны өйрәнүдә – ифрат дәрәҗәдә бай һәм көчле. Милли фәнни традицияләрне хөрмәт итү, өйрәнү, төрле сәбәпләр аркасында дөнья күрми калган хезмәтләрне бастыру, булган бай мирасыбызга таянып, яңа фәнни казанышларга омтылу – фән белән шөгыльләнүче һәр яңа буынның төп бурычы. Шулай эшләсәк, сәләфләребез никадәр зур өлеш керткәнен һәм үзебез никадәр аз эшләгәнне күрә һәм икесенә дә дөрес бәя бирә алырбыз.

Шушы максатларны истә тотып, соңгы берничә ел дәвамында без татар кулъязмаларын өйрәнгән шәхесләребезнең архив чыганакларын интернет һәм басма журналлар аша системалы рәвештә дөньяга чыгарырга тырышабыз. Аерым вебсайт битләрендә без укучыга берничә күләмле кулъязма тасвирламалары тәкъдим иттек. Алар үз вакытында атаклы галимнәребез Сәет Вахиди

[1] This research is supported by the ERC Starting Grant «MIND: The Muslim Individual in Imperial and Soviet Russia».

(1887–1937)[1], Гали Рәхим (1892–1943), Альберт Фәтхи (1937–1992)[2] һәм Мәсгуд Идиятуллин (1928–1993/94)[3] тарафыннан әзерләнеп, киң катлам укучыга бөтенләй тәкъдим ителмичә, Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенең Көнчыгыш кульязмалары секторында сакланып калганнар. Кульязма мирасыбызны тирәнтән белгән һәм шул кульязмалар аша әдәбият тарихын барлаган уникаль галимәбез Зәйнәп Максудова шәхси китапханәсенең тулы *фихристен* (тасвирламасын) басмага әзерләп куйдык[4]. Күптән түгел мәртәбәле мөфти Габделбари Исаевның (1907–1982) кульязмалар белән бәйле кайбер язма истәлекләре беренче мәртәбә дөнья күрде[5]. Ошбу әсәрләр татар археографиясе традицияләре белән кызыксынучыларга файдалы чыганак булып торыр дип өметләнәбез.

Шушы сәләфләр сафына баскан, үз гомерен университет китапханәсендә татар язма чыганакларын өйрәнүгә багышлаган Альберт Фәтхинең язмалары безнең өчен аеруча әһәмиятле. Ни өчен дисәң, бу галимнең кулы аша меңләгән китап һәм документлар узган һәм ул аларның һәрберсе турында диярлек я кыскача, я тәфсилләп үз фикерләрен язып калдырган. Альберт Фәтхидән калган чиксез диңгез кебек язмаларны тасвирлаганда[6], без аның архив системасын һәм тематик тәртипне сакларга тырыштык. Шулай да, Альберт Фәтхинең интеллектуаль өслүбләре һәм шәхсият үзенчәлекләре белән танышмый торып, бу системаны аңлавы авыррак. Дистәләрчә еллар буе университет китапханәсендә эшләп, Альберт Фәтхи яраткан китапларыннан аерылгысыз бер затка һәм уникаль белемгә ия галимгә әйләнә. Кешеләр белән аралашуга караганда, ул китап укуны өстен күрә һәм үзенең хисләрен, уйларын, моң-зарларын, көндәлек рәвешендә, кәгазь битләренә төшереп бара. Димәк, Альберт Фәтхи архивы ул әле бер милләтнең, аның китап мәдәниятенең һәм аерым шәхеснең фаҗигасен дә үз эченә алган. Галим калдырган әсәрләргә шушы күзлектән

---

[1] Вахидов С.Г. Описание восточных рукописей и документов пожертвованных С.Г. Вахидовым в 1925 году в Центральный Музей Т.Р. через Академический Центр Татнаркомпроса в Отдел Восточных Рукописей Центр. Музея Т.Р. https://eu.spb.ru/islamology/islamic-literature-in-russia/kollektsii/19379-katalog-rukopisej-s-g-vakhidi (соңгы тапкыр каралды 30.03.2019).

[2] Каталог тюркских рукописей КФУ https://eu.spb.ru/islamology/islamic-literature-in-russia/kollektsii/19376-katalog-tyurkskikh-rukopisej-kfu (соңгы тапкыр каралды 30.03.2019).

[3] *Идиятуллин М.Н.* Введение к каталогу арабских рукописей КГУ https://eu.spb.ru/islamology/islamic-literature-in-russia/kollektsii/19377-masgud-idiyatullin-vvedenie-k-katalogu-arabskikh-rukopisej-kfu; Идиятуллин М.Н. Каталог арабских рукописей КГУ https://eu.spb.ru/islamology/islamic-literature-in-russia/kollektsii/19378-masgud-idiyatullin-katalog-arabskikh-rukopisej-biblioteki-kfu (соңгы тапкыр каралды 30.03.2019).

[4] Зәйнәп Максудова китапханәсе / төз. Ә.К. Бостанов. Казан (басмада). 400 б.

[5] *Габделбари хәзрәт Исаев.* Дини әсәрләр / төз. Ә.К. Бостанов. Казан, 2019. Б. 90–100, 148–151. Китап ачык доступта бар: https://dare.uva.nl/personal/search?identifier=054695c0-7003-42d6-bfcd-91e91bbd51ba (соңгы тапкыр каралды).

[6] *Бустанов Ә.К.* Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы // Фәнни Татарстан. 2015. № 1. Б. 112–126.

карасак, татар кулъязмаларын өйрәнү процессы кешенең эчке дөньясын яктырта торган бер хезмәт икәнлеген ачык күрербез.

Татар халкы язма мирасының зур өлеше шигърияттән гыйбарәт. Аны дөрес аңлап эш итү һәм (көйләп) башкару, еш кына өстәмә хәзерлек таләп итә. Чөнки монда шигърият кагыйдәләрен, стильләрен һәм төрләрен белү, тоемлау сәләте дә кирәк. Альберт Фәтхи дә шигъриятне өйрәнүдән баш тартмый, киресенчә, күп кенә әсәрләрне тирәнтен өйрәнә,[1] яңадан күчерә һәм хәтта тәнкыйди текстлар да әзерләп калдыра[2]. Шулай да, бик күп гамәли тәҗрибәгә ия булса да, Альберт Фәтхи үз каләмдәшләреннән ярдәм-киңәш сорарга оялмаган: архив кәгазьләреннән күренгәнчә, бер мәкаләне әзерләгәндә, ул күренекле татар филологы, шигърият белгече Хатип Госман (1908–1992) хезмәтеннән файдаланган. Машинкада басылган һәм «Үткән гасырларның шигъри сәхифәләре (XVIII гасыр азаклары – XIX гасыр башларында яшәгән, исемнәре билгесез калган татар шагыйрьләренең шигырьләре)» дип исемләнгән әлеге мәкалә Альберт Фәтхинең эш кәгазьләре арасында табылды[3]. Ни аяныч, күпсанлы чыганакларга таянып язылган бу хезмәт нindидер сәбәпләр аркасында басылмый калган. 1987 елның апрелендә Хатип Госман, мәкаләне тикшереп, үз төзәтмәләрен керткәннән соң, Альберт Фәтхи бүтән бу текстка әйләнеп кайтмаган ахрысы; һәрхәлдә архивта ул мәкаләнең башка нөсхәләре әлегә кадәр очрамады.

Альберт Фәтхинең укучыларга тәкъдим ителгән мәкаләсе формасы белән дә, эчтәлеге белән дә үзенә җәлеп итә. Беренчедән, бу мәкалә татар кулъязмаларында очрый торган аерым кыска шигъри текстларны фәнни әйләнешкә кертү максаты белән язылган, шуңа күрә галимнең үз фикерләре һәм фәнни күзәтүләре тулаем астөшермәләрдә урнаштырылган. Бу, мөгаен, чыганакка хөрмәт күрсәтү һәм әһәмият бирү нияте белән шулай эшләнгәндер. Икенчедән, эчтәлегенә күз салсак, галимнең татар кулъязмасын барлауда шактый тәҗрибәсе сизелеп тора: ул китапханәдә саклаган әсәрләрне (кыска язуларга кадәр!) биш бармагыдай белә һәм, басма чыганаклар белән чагыштырып, профессиональ анализ ясый. Һичшиксез, түбәндәге мәкаләдә китерелгән мәгълүмат татар шигъриятен һәм, гомумән, татар әдәбиятын өйрәнүдә файдалы булыр.

***Бостанов Әлфрид Кашаф улы,***
*Ph.D. (Hist.), Амстердам университеты ассистент-профессоры*

[1] Мәсәлән: Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Р. Мәрданов. Казан, 2007. Б. 24–42, 51–59; *Альберт Фәтхи.* Габделҗәббар Кандалый шигырьләре җыентыгы [төз. Ә. Бостанов] // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. Б. 149–170. https://www.academia.edu/36765285/Альберт_Фәтхи._Габделҗәббар_Кандалый_шигырьләре_җыентыгы_Фәнни_Татарстан._2018_1_149-170. [Мөрәҗәгать итү датасы]: 30.03.19.

[2] Мәсәлән, Мөхәммәдьярнең «Төхфәи мәрдан» тексты: Казан федераль университеты Фәнни китапханәсе, Көнчыгыш кулъязмалар секторы, 6 фонд (Альберт Фәтхи), 48 сакл. бер., 56 кгз. (1909т кулъязмасы буенча).

[3] Казан федераль университеты Фәнни китапханәсе, Көнчыгыш кулъязмалар секторы, 6 фонд (Альберт Фәтхи), 174 сакл. бер., 33 кгз.

## XVIII – XIX гасыр башларында яшәгән, исемнәре билгесез калган татар шагыйрьләренең шигырьләре

### *Гаҗәп хикмәт бу дөньяда*

Гаҗәп хикмәт, гаҗәп халәт,
Нәзар кыйлсаң[1] бу дөньяйа[2].
Фәкыйрә игътибар юктыр,
Кыйлалар гыйззәти[3] байа[4].

### *Тарих хәрабәләрен карап йөргәндә*

Шәһре Болгар манарасы[5],
Сиксән баскыч һәм арасы[6],

---

[1] Нәзар кыйлмак – карау, күз салу. [Бу урыннан башлап барлык шәрехләүләр Альберт Фәтхигә карый. – *Ә.Б.*].

[2] Дөньяйа – дөньяга. Элекке татар әдәби телендә юнәлеш килеш еш кына -йа, -йә, -а, -ә формасында кулланыла: фәкыйрә – фәкыйрьгә, байа – байга.

[3] Гыйззәт кыйлмак – олылау, ихтирам итү, санга санау. Кыйлалар гыйззәти байа – байга (гына) түбәнчелек белдерәләр.

[4] КДУның Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе, көнчыгыш кульязмалары секторы, кульязма № 300 т. (2780), 22 бит. Кечкенә кулдагы 24 битле (12 кәгазьле) бу дәфтәр XIX гасыр башларында язылган. Дәфтәрдә дөньяви эчтәлекле һәм вәгазь-нәсыйхәт рухындагы берничә шигырь (мөнәҗәт) күчерелгән. Бу шигырь урнаштырылган битнең башына «Ошбу китап Гафифәбануның торыр» дип куелган. Бу шигырьдән соң түбәндәге бер строфалы икенче бер шигырь килә:

Йөреп сорсам табиблардыйн,
«Бу дәрдәмгә дәва бармы?»
Табиб әйтер: «Ки, и надан,
Бу дәрдең би-дәва дирләр».

Мәхәббәтнең көчен сурәтли торган бу шигырь элек татар укучылары арасында бик киң таралган булган, шуңа күрә ул бик күп кульязмалар эчендә очрый. Безнең тарафтан монда «Гаҗәп хикмәт бу дөньяда» дип исемләнгән бу шигырь XIX гасырның III чирегендә күчерелгән 1973 номерлы кульязма эчендә дә очрый (31б кәгазь). Күчерүче – Мөхәммәтнәҗип Түнтәри-Болгари. Бу күчермәдә соңгы юл «Идәрләр гыйззәти байа» рәвешендә килә.

[5] Шәһре Болгар – татар халкының борынгы бабайлары – болгар дәүләтендәге башкала. X–XIV гасырларда бу шәһәр Көнчыгыш Европаның иң эре сәүдә үзәкләреннән берсе булган. Бу шәһәр Татарстандагы хәзерге Куйбышев шәһәреннән 2 км көнчыгыштарак урынлашкан булган. Көнчыгыштан килгән монгол басып алучылары шәһәрне җимергәннән соң, халкы башка җирләргә күчеп утырган. Бу шәһәр урынында берничә таш бина (Ак пулат, Кара пулат, Кызыл пулат, Кече манара, Хан төрбәсе һ. б.) әле хәзерге көндә дә бөтен килеш тора. Татарлар бу хәрабәләрне, бабайларының харап булган мираслары итеп карап, хөрмәт иткәннәр, «мөкатдәс» итеп исәпләгәннәр. Кешеләр ерак авыллардан да хәрабәләргә баш иярг
ә килгәннәр, манарасына менеп йөргәннәр, хәтта кайберәүләр истәлек өчен таш стенага уеп үзләренең исемнәрен, сүзләрен дә калдыра торган булганнар (Татарларның ничек Болгарга килеп йөрүләре, «зиярәт кыйлулары» тарихчы Гайнетдин Әхмәревнең «Болгар тарихы» китабында (Казан, 1909, «Бәянелхак» идарәсе нәшере, 19 – 26 б.) бик тәфсилләп тасвирланган). Монда китерелгән бу шигырьдә нәкъ менә шул факт чагылыш тапкан.

[6] Ара – монда «биеклек» мәгънәсендә кулланыла булса кирәк. Хәзерге әдәби телдә бу сүз җир яссылыгына карата «ераклык» мәгънәсендә яки вакыт аралыгына карата гына кулланыла.

Анда меңгән ирәнләрнең[1]
Сил тик[2] агар күздин яше.

Гаҗәп ирмеш Болгар юлы,
Даим[3] исә хуш йилләре.
Ул Болгарга килгәннәрнең
Сил тик агар күздин яше[4].

---

[1] Ирәнләр – ирләр, кешеләр.

[2] Сил тик – ташкындай, ташкын булып, монда: мөлдереп.

[3] Даим – бертуктаусыз.

[4] XVIII азакларында күчерелгән № 2560 кулъязма дәфтәрнең 19 кәгазеннән. Шуның ук икенче күчермәсе – № 239 т. (2708), 5–6 б.

Беренчесендә шигырь 6 строфалы, башына «Шәһре Болгари» дип куелган. Шигырь, халык бәетләрендәге шикелле, укучыга (дөресрәге, тыңлаучыга, чөнки ул заманда шигырьләр дә бәетләр шикелле көйләп укылган) мөрәҗәгать формасында язылган. Ул болай башланып китә:

Кичә – көндез фикер идеңләр,
Алла адыни зикер идеңләр,
Алла адыни зикер идүбән,
Шәһре Болгара кидеңләр.

Дыңлаңызлар бездин боны,
Зикер идеңнәр көне-төне,
Мал-мөлкәти җандин кичеп,
Сәйр идеңләр Болгар юлы.

(Адыни зикер идеңләр – исемен телдән төшермәгез. Мал-мөлкәти җандин кичеп – мал-мөлкәтне корбан итеп (?). Сәйр идеңләр Болгар юлы – йөрегез Болгарга илтә торган юл буйлап). Монда шушы шигырьнең реалистик детальләре белән аерылып торган өченче һәм бишенче строфалары гына алынды. Калган строфаларда шушы тарихи хәрабәләрне «изгеләштерү» һәм аларга бәйләп ислам хорафатларын вәгазьләү сизелеп китә, ә бу үзе исә дөньяга карашның чикләнгәнлегеннән, җәмгыятькә мөнәсәбәттә гаҗизлектән килә. Җәмгыятьнең тарихи барышы закончалыкларына төшенмәү борынгының материаль хатирәләренә мөнәсәбәттә дә «илаһи рух» йогынтысына сыгынуга китерә. Монда китерелгән ике строфа сурәтләренең контрастлы, мәгънәле булуы белән аерыла. Беренче строфаның 1–2 юлында – мәһабәт манара (сиксән баскыч һәм арасы!) сурәте. Бу манара биектән торып җир белән хозурлана торган урын булырга тиеш иде, ләкин, 3 нче, 4 нче юлдан аңлашылганча, ул күздән яшь китерә торган, кайчандыр тормыш гөрләп торган шәһәрнең юкка чыгуы, берән-сәрән хәрабәләре генә калуы хакында авыр тойгылар кузгата торган җир.

Икенче строфада да шулай ук: Болгарга килә торган юлда бертуктаусыз рәхәт җилләр исеп тора (Идел, Чулман елгалары якын булганлыктан ул!), күңелле, ләкин 3 нче, 4 нче юлдан аңлашылганча, шушы очындырып алып килгән юлның очы – Шәһре Болгар хәрабәләре үзе күңелсез икән. Юл буйлап килгәндәге тойгылар югала. Кеше авыр тойгылар, җавап таба алмаслык газаплы фикерләр белән үзенең җиренә кайтып китә. Күңелдәге ниндидер татлы өметләрнең, уйларның, рәхәт тойгыларның аяусыз, күздән яшь китергеч, әрнеткеч чынбарлык белән бәрелешеп чәлпәрәмә килүен бу шигырь искиткеч оста, төгәл гәүдәләндерә. Икенче күчермәдә «сил тик» гыйбарәсе «су тик» рәвешендә килә.

***Гомер дә чәчәккә тиң***

Чәчәк бер вакыт атадыр,
Коела, җирә ятадыр,
Кибәдер, корып, катадыр,
Көзенә керсә языннан.

Гомер дәхи шулай бетәр,
Йөзенең рәүнәкый[1] китәр,
Чәчәк вакты үтеп бетәр,
Карына керсә башыннан[2].

***Бәнем инде бу йирдә һиммәтем юк***
*(шәһәргә китүче егетнең ата-анасына мөрәҗәгате)*

Сәлам яздым сәңа, и әткәем,
Сәңа яздым дәхи, и әңкәем.
Сәламемне, и әткәй, кабул ит,
Безне дәхи сәламәт дип [мәгълүм ит].
Сәламдин соң бәнем [гамем бу] улыр,
Бәнем әйтер сүзем сезгә күп улыр.
… Бәнем имди бу йирдә һиммәтем[3] юк,
Халаеклар[4] арасында кыйммәтем юк.
Ирадымыз[5] китәргә мондыйн ары,
Өмидемез Ходаның лотфы сары[6].
Ирадымыз китәргәдер шәһәргә,
Дәхи анда гыйлем тәхсыйл итәргә[7]
Тәвәккәл әйләеп чыксам сәфәргә,
Хода, шаять, төшермәгәй хәтәргә.

---

[1] Рәүнәкъ – якты, нур, күркәмлек.

[2] Бу шигырь бер гарәпчә кульязма китапның № 2349 г. (3651) арттагы тышлык катыргысының эчке ягына язылган. Бу шигырь янында тагын берничә шигырь һәм 1830 елларга караган татарча хроник истәлек килә. Димәк, шигырьнең язылуы да якынча шул елларга карый, ә иҗат ителүе исә элегрәк булырга да мөмкин. Икенче строфаның юл азагындагы сүзләре кыенрак таныла, «бетәр», «китәр» сүзләренең кушымчаларына беленер-беленмәс кенә итеп «д» хәрефе куелган, ләкин аның белән укыганда («бетәдер», «китәдер») иҗек саны бозылыр һәм өченче юл белән рифмалашуга да зыян килер иде.

Без монда беленер-беленмәс «д» хәрефенә игътибар итмичә, әмма, иҗек санын бозмас өчен, «йөз» һәм «вакыт» сүзләренә III зат тартым кушымчасы ялгап укыдык (ягъни: гомернең йөзенең, гомернең чәчәк вакты).

Соңгы юлдагы соңгы сүздә беренче хәреф ачык танылмый: Башыннан яки Йашыннан (ягъни: яшеннән – яшьләй, яшьтән үк мәгънәсендә?) булуы мөмкин.

[3] Һиммәт юк – эшләрем бетте, көчем бетте.

[4] Халаеклар – кешеләр.

[5] Ирад – теләк, ният.

[6] Ходаның лотфы сары – Тәңренең игелекле (рәхимлерәк) якларына таба.

[7] Тәхсыйл итәргә – гыйлем эстәргә.

«Бала» диеп бәңа кайгу йимәңез[1],
Исән улып кайчан кайтыр димәңез[2].

***Озак еллар туган иленнән еракта йөргән кешенең зары***

И хода, я, мин гарибне[3] ни өчен кыйлдың гариб,
Бу гариблектә йөрермен ике чәһрәм[4] саргаеп.

Бу гариблектә дәрд булды[5], «аһ» эчемгә сыймады,
Бу гариблек дәрдене мин кемгә әйтәен[6] барып?

Бу гариблек госсасын[7] мин ничә ел чиктем модам[8],
Яхшы-яман үтте гомрем барча халка[9] ялбарып.

Бу фәләкнең[10] җәһәдидин[11] егълап йөрермен зары-зар,
Я әҗәл тартты мине мәнзәлгә[12], я ризык насыйб.

Ахыр ошбу әҗәл тигергүчи гүргә рәван[13],
Нә сәгадәттер миңа барсам иманымны алып[14].

Мин анамны[ң] кадрени наданлыгымдин белмәдем,
Тапмадым баскан эзен, бән тутыя кыйлсам барып.

[Мин,] Сөләймандин, үтептер бу гариблек гыйззәте,
[«Аһ»] орып даим йөрермен зәгъфран тик саргаеп[15].

---

[1] Кайгу йимәңез – кайгырмагыз.

[2] Бу соңгы юл «минем өчен көймәгез» дигән мәгънәдәрәк килә булса кирәк… Шигырь XVIII гасыр азагында күчерелгән, «Мелла Гыйрфан җыентыгы» дип йөртелә торган шигъри җыентык эчендә килә (№ 297т. (2777), 21б–22а кгз.). Шигырьнең уртадагы 4 строфасы төшерелеп, кыскартып алынды.

[3] Гариб – читтә йөрүче, туган иленнән аерылган кеше.

[4] Чәһрә – йөз, монда: ике чәһрәм – ике битем.

[5] Дәрд булды – кайгыга, хәсрәткә юлыктым.

[6] Әйтәен – әйтим.

[7] Госса – кайгы, сагыш.

[8] Модам – бертуктаусыз.

[9] Халка – кешеләргә.

[10] Фәләк – язмыш.

[11] Җәһәд – тырышлык, көч кую.

[12] Мәнзәл – туктар урын.

[13] Тигергүчи гүргә рәван – туп-туры гүргә илтеп кертер.

[14] Иман – ышаныч. Элек кешенең гомерендә ышанган нәрсәгә тугрылыклы булып үлүе мактаулы саналган.

[15] Бу шигырь XVIII гасыр азагында «Вилдан мулла җыентыгы» дип йөртелә торган шигъри җыентык эчендә күчерелгән (№296 т. (2776), 13а–13б кгз.).

***Бер сүзеңнән дөнья куана***

Сән гөлестан[1] эчрә гөлсән, би-гөман,[2]
Былбылым, гыйшкында җиһан – канда[3] сән?
Сүзләр ирсәң гончә дик[4] ачып диһан,[5]
Кем сүзеңнән фәрах[6], шад улыр җиһан[7].

***Назлы ярга ялварып[8]***

Һәб[9] гүзәлләр кәлде-кәчде – күрмәдем [бән] ярыми,
Күл талында былбыл аглар[10] бәнем аһ-зарыми.
Хакыйкатьтә[11] күңле вардыр, һич онытмам ярыми,
Теле – былбыл, сачы – сөнбел, назлы ярым, ал бәни.
Дөнгәчә яр капуында, ястыгым бер таш иде,
Дүшәкем галәф (?)[12] тик, кәнә[13] күңлем хуш иде.

[1] Гөлестан – гөлбакча.

[2] Би-гөмән – һикшиксез.

[3] Канда – кайда.

[4] Гончә дик – ганҗәдәй, чәчкә атарга торган бөре кебек.

[5] Диһан – иреннәр, авыз.

[6] Фәрах улыр – куаныр, сөенер, шат булыр.

[7] XVIII гасыр азагында (1793 елда) күчерелгән №469 т. (3093) шигъри җыентык эчендә килә (6б кгз.).

[8] Бу шигырь уч төбенә сыярлык кечкенә кулдагы кульязма дәфтәр эчендә күчерелгән (№ 498т. (3135), 5б кгз.). Дәфтәр мәхәббәт темасына караган 4 шигырьдән тора. Ул шигырь – дәфтәрдә иң соңгы шигырь. Шигырьнең баштагы 5 юлы 6а кәгазьдә икенче мәртәбә күчерелгән. Һәр шигырьнең башына, шул исәптән монда китерелгәненекенә дә «Илаһи бәет» диеп куелган. Бу шигырьләрнең беренчесендә (1а кгз.) һәм өченчесендә (3а һәм 3б кгз.) шигырьләрнең Габдулла исемле кеше тарафыннан иҗат ителүе телгә алынып китә. Дәфтәрдәге бер шигырьдә «Дусты Габдулла өчен диде Искәндәр» дигән юллар да бар (1а кгз.). Ә икенче шигырьнең азагында (2а кгз.): «Ул бәетлек (?) мелла Бикбауның торыр. Һич тиң (?) ирмәз мәхәббәтемгә яздым» дигән искәрмә бирелгән. Димәк, бу җыентык XVIII гасыр азагындагы татар поэзиясен күзаллау өчен кызыклы гына материал була ала. Шигырьләрнең теле, мотивлары бу дәвернең яки аннан бераз гына соңрак чорның моңарчы билгеле шигырьләреннән әллә ни аерылмый.Бу шигырь икенче бер җыентыкта да бар. Монысында беренче строфа: «Көзләр килде яхшы, күрмәдем бән ярыми…» дип башланып китә. Өченче строфа:

«Төнгәчә яр кайгысында ястыгым (бер) таш иде,
Дүшәмем (?) галәф (?) дик… (?) күңлем бик хуш иде»

рәвешендә килә. Бу строфаның соңгы юлы беренче күчермәдә дә бигүк танылып бетми.

[9] Һәб – бөтен, барча, күп.

[10] Аглар – елый, монда: «сайрый» мәгънәсендә.

[11] Хакыйкатьтә – чынлап та.

[12] Галәф – үлән.

[13] Кәнә – янә, шулай ук, һәм.

Хак белер: ялгыз да гөлем кәшвәри[1] шаһлар кеби,
Инүбән алчакланыр саплы ботаклар кеби[2].

### *Сине куеп мең Зөләйха һич кирәкмәстер бәңа*

Йә илаһи, сән белерсәң ош[3] бәнем бу хәлеми,
Сәндин үзгә кемсә белмәс бәнем аһ-зарыми.
Бер никәрең[4] гыйшкы илә бән мисле Мәҗнүн улурум,[5]
Шул никәри арзу әйләп,[6] сәңа зарый кыйлырым.[7]
Шул никәрең йөзи бәңа раушан[8] улды ай кеби,
Бәгъремезә дәрдени[9] салды, җәннәт эчрә хур кеби.
Бәдахшанның ләгъле[10] ирер сән никәрең ләбләре[11],
Гадне-җәннәт[12] йинҗүсидер[13] сән никәрең дешләре[14].
Сән зыйфаның ләбләре һәм багъда бетегән[15] алмадыр,
Сәни күргән кемсә бәңа гандәлибнең мислидер[16].
Сән никәрең саутындин[17] улдым имди бикарар[18].

---

[1] Кәшвәри – буйсындыручы, яулап алучы, үзенә каратучы. Шаһ – император, патша.

[2] Инүбән алчакланыр саплы ботаклар кеби – иелгән-бөгелгән (яки игән) саен, чатлы ботаклар шикелле юашлана, тыйнаклана бара. Бу юл авыр аңлашыла.

Татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә «алчак» сүзенең мәгънәсе төрлечә бирелә. К. Насыйри «Ләһҗәи татари» китабында (1 т. Казан, 1895, 29 б.) «Алчаклык – тәвазыйглык (тәкәбберлек зады)», ягъни хәзерге телгә күчергәндә – «буйсынучанлык, юашлык, бирелүчәнлек, тыйнаклык (тәкәбберлек киресе)» дип аңлата. Ә «алчакланмак» сүзенә «мөтәвәззыйг булмак, һавасыз булмак, тәрилкә тотмак» дигән аңлатма бирә. Җамал Вәлиди «Татар теленең тулы сүзлеге»ндә (1 т., Казан, 1927, 109 б.) «алчак»ның «бигрәк тә Тау ягында кулланыла, хәзерге татар күпчелегендә юк» дигән искәрмә белән «ачык йөзле, кече күңелле» мәгънәсендә кулланылуын ача һәм борынгы татар телендә «түбәнчелекле, гади, инсафлы, юаш» мәгънәсендә йөрүен әйтә. Хәзерге азәрбайҗан һәм төрек телендә бу сүз «усал, әшәке» мәгънәсендә килә. Беренче юлдагы «кәшвәри шаһлар кеби» тәгъбирен дә искә алганда, монда «ачаклану» сүзен «усаллану» яки «назлану» мәгънәсендә аңларга да мөмкинлек бар. «Саплы» сүзе дә монда без китергән мәгънәсендә сүзлекләрдә очрамый.

[3] Ош – шушы.

[4] Никәр – чибәр, гүзәл.

[5] Мисле Мәҗнүн улурум – Ләйләгә гыйшкыннан акылдан шашкан Мәҗнүн кебек булам.

[6] Арзу әйләп – теләп (үземнеке итәргә).

[7] Зарый кыйлырым – зарымны белдерәм.

[8] Раушан – якты.

[9] Дәрд – кайгы, сагыш.

[10] Ләгъл – рубин таш.

[11] Ләбләр – иреннәр.

[12] Гадн-җәннәт – оҗмах.

[13] Йинҗү – энҗе.

[14] Деш – теш.

[15] Багъда бетегән – бакчада үсеп утырган.

[16] Гандәлибнең мисле – сандугач шикелле.

[17] Саут – тавыш.

[18] Бикарар – бикарар улдым – коелып төштем.

Кәрам кыйлсаң[1] йөзеңне бән күрмәкдә бән интизар[2].
Бән, кәминә[3], кавышмасам, сән никәрә йәк[4] заман,
Гамь[5] эчендә гарык улып[6] дорырым бән, бигөман[7].
Хак мияссәр әйләюбән[8] васыйл улсам[9] бән сәңа,
Сәни куеп бәң Зөләйха һич кирәкмәздер бәңа.
Мәгъшукамызи гәр сорсаңыз исмени белмәк өчен
Әүвәл «би», өсте, «кәф», ахры – «нун» янә сөкүн[10].
Бу шигырьне инша кыйлды Габдулла ирер атым,
Шул никәрең гыйшкыйдин, бел, калмады һич тәкатем[11].

***Инде фикергә салдың***

Әя мәхбүб[12], хәлеңне әйлә бәян,
Кәйфе, кәйфе, кәйфе кә-ән[13],

---

[1] Кәрам кыйлсаң – яхшылык итсәң.

[2] Күрмәкдә бән интизар – бер күрергә зар булып торам.

[3] Кәминә – кечелекле, түбәнчелекле.

[4] Йәк – бер.

[5] Гамь – кайгы, сагыш.

[6] Гарык улып – чумып.

[7] Бигөман – һичшиксез.

[8] Хак әйләюбән – Тәңре ирештереп.

[9] Васыйл улсам – кавышсам.

[10] «Би», « кяф», « нүн» – иске татар әлифбасындагы хәреф исемнәре (бе, ке, не); өст – сузык аваз куеп уку өчен кулланыла торган фонетик билге («ә»); сөкүн – иҗекнең бетүен белдерә торган билге-хәрәкә. Монда егетнең кызының исеме әйтелгән булырга тиеш.

[11] Алдагы шигырь белән бер җыентыкта – «Мелла Бикбау бәетлеге»ндә килә (№ 498 (3135), 3а кгз.). Бу шигырь хисләрнең сабыйларча ихлас күңелдән, самими, хәтта беркатлы ачылуы белән кызыклы.

Монда гашыйк кеше, күңелен бөтереп алган хис тәэсирендә, «дөньясын онытып», бер талпынуда бөтен серне, бөтен теләген ачып сала, ягъни мондый гыйшкый шигырьләрдә ярның күркәм сыйфатларын бөртекләп-бөртекләп санаудан башлап, шунда ук (!) бөтенләйгә кавышырга, алырга теләү белән бетереп, бөтенесе әйтелә. Поэмага лаеклы нәрсә 8–10 строфалы бер шигырьдә ачылып беткән була!

Гыйшыкны, мәхәббәтне бу рәвешле уртаклашу, аңлату татар яшьләре арасында XIX гасырның азакларына – XX гасыр башларына кадәр яшәп килә. Бу, әлбәттә, татар җәмгыятендәге егет һәм кызларның хәле белән, мөнәсәбәтләрдә иркенлек, даими якынлык булмау белән бәйләнгән. Ашыгыч (!) күрешү тәэсирендә уянган хисләрне уртаклашу, күп очракта, астыртын юллар белән кулга төшкән кәгазь кисәге, аңа язылган гыйшык хаты, гыйшык шигыре аша барган. Мондый поэзиянең үзенә күрә стандарты булган. Сурәтләү чаралары белән дә бу поэзия бөтен Якын Көнчыгыш халыклары поэзиясенә, шул исәптән борынгы татар поэзиясенә дә бик якын тора. Татарлар арасында гаять популяр булган мондый шигырьләр циклын «Мәгъшукнамә» дип йөртү дөрес булыр иде. Бу циклның язма хатирәләре Көнчыгыш кулъязмалары фондында шактый күп тупланган.

[12] Мәхбүб – сөеклем.

[13] Кәйфе, кәйфе, кәйфе кә-ән – кәефле (күңелле) булыр кебек.

Мәхәббәтең гәрчә улырса нишан[1],
Биниһан итмә[2] биниһан, кыйл гаян[3].
Мәхәббәтең эстәдем бик күп заман,
Үтте дәүран[4], үтте дәүран, юк фәган[5].
Гыйшкың сәнең йөрәгемне кыйлды кан,
Кәбир улдың[6], кәбир улдың би-гөман.
Мөттасил[7] өч ел сәнеңчөн бән дәвам.
«Кани нишан[8], кани нишан» дип һаман.
Имди фикрә салдың бигөман,
Нидамәтдер[9], нидамәтдер һәм фәган.
Бер көн безә ярдәм бирер мөстәган[10],
Горрәдер[11] һәм горрәдер бу җиһан.
Санма гомреңне улыр дип җаудан[12],
Гафыйл улма[13], гафыйл улма, сакла җан.
Кыйммәтең, кадре[н] сәнең вакты җауан[14],
Кани кыйммәт, кани чөн[15] җауан.
Гайярым[16] улсаң ула һич[17] сәңа сән,
Әйләерсән, әйләерсән күп фәган[18].
Яшьлекеңә кайтмакың улмас асан[19],
Мөмтәныйгдыр[20], мөмтәныйгдыр би-гөман[21].

[1] Нишан улырса (улыр исә) – беленсә.
[2] Биниһан итмә – яшермә. Биниһан – яшерен, астыртын.
[3] Гаян кыйл – ачып сал.
[4] Дәүран – дәверләр.
[5] Фәган – аһ-зар чигү, уфылдау.
[6] Кәбир улдың – эре кыландың, тәкәбберләндең.
[7] Мөттасил – бертуктаусыз.
[8] Нишан – билге.
[9] Нидамәт – үкенечле.
[10] Мөстәган – ярдәм кулын сузучы, Тәңре.
[11] Горрә – вакытлы.
[12] Җаудан – мәңгелек.
[13] Гафыйл улма – ваемсыз булма.
[14] Вакты җауан – яшь чак.
[15] Чөн – чын.
[16] Гайяр – тиң, яр.
[17] Һич – ич.
[18] Фәган әйләерсән – аһ-зар чигәрсең, уфылдарсың.
[19] Асан (улмас) – җиңел (түгел).
[20] Мөмтәныйг – тыелган.

[21] Бу шигырь XIX гасыр азакларында төзелгән гыйшкый шигырьләр һәм халык җырлары дәфтәре эчендә килә (№ 1619 т. (5581), 7а кгз.). Бу дәфтәрне чын мәгънәсе белән «Мәгъшукнамә» дип исемләргә мөмкин. Бүтән гыйшык дәфтәрләрендәге шикелле, Габделҗәббар Кандалый тарафыннан иҗат ителгән шигырьләр дә очрый. Монда бу шигырьнең баштагы өлеше генә кертелде.

***Күрдекем сәгать җиһанда***
***Китте золмәт – улды нур…***

Бәдре ламигъ[1] дилбәрнең[2]
Гыйшкын дотубән би-нәва.[3]
Нәзым[4] кыйлдым бән ула дип
Дәрде дил үзрә[5] дәва.

Эче – былбыл, сүзе – ширин[6],
Шәмсе талигъдыр[7] йөзе,
Нәзар улсаң[8] көн-кояш тик,
Талдырыр ике күзи.

Үзе – шәйдә[9], күзе – нәргис,
Йөзедер шәмсе җәмал.[10]
Җисменә исмени муафикъ[11]
Кыйлды Алла – зөлҗәлал[12].

Деләә[13] кәлмәз, күңлә кәчмәз,
Хөсненең[14] меңдин бере.
Галәм эчрә хуш сәнгатьләр[15]
Анда мәүҗүд[16] һәрбере.

Бу җиһан мәхбубләрендә
Улмая һич биңзәше[17]
Илда булыр җәннәт эчрә
Хури аның тиңдәше.

Йөрер ирдем бер вакыт хуш,
Күземә шул улды туш[18],
Күрдекем дәм[19] гыйшилә бән
Би-гакыл[20] улдым, би-хуш[21].

---

[1] Бәдр – тулган ай. Ламигъ – балкый, нур сибә торган.
[2] Дилбәр – ягымлы кыз.
[3] Би-нәва – бичара.
[4] Нәзым (кыйлдым) – шигырь (яздым).
[5] Дәрде дил үзрә – күңел сызлаганга.
[6] Ширин – татлы.
[7] Шәмсе талигъ – иркәли торган кояш (шикелле).
[8] Нәзар улсаң – күз салсаң.
[9] Шәйдә – кояш.
[10] Шәмсе җәмал – кояш шикелле күркәм.
[11] Муафикъ – килешле.
[12] Зөлҗәлал – олы, бөек (Тәңре).
[13] Деләә – телгә.
[14] Хөсне – чибәрлек, күркәмлек.
[15] Хуш сәнгатьләр – гүзәл (килешле) итеп яралтылганнар.
[16] Мәүҗүд – бар, булып тора.
[17] Улмая һич биңзәши – һич тиңе, охшашы булмас (юк).
[18] Күземә туш улды – күземә төш килде, чалынды, туры килде.
[19] Дәм – мәл, мизгел.
[20] Би-гакыл – акылсыз.
[21] Би-һуш – һушсыз.

Кәндемә[1] дидем гаҗәпләп:
«Бу фиданың сәнгате.
Нә кыйлаем нәфес билә,
Көтмәк нәбиләр сөннәте[2]».

Бу гыйшыклык хәддин ашып,
Китте һәм бәгърем ташып.
Мисле Мәҗнүн улдым имди,
Шөйлә кем гаклым шашып.

Йимәк-эчмәк җөмлә аның,
Гыйшкы өчен һәм көймәкем[3]
Ошбу гафләт галәмендә[4]
Йөрмәкем, сүз димәкем.

Катыйг тузы[5] шул тарафтан,
Йай[6] илә керсә күзә.
Шул никәрең[7] шәкле[8] филхәл[9]
Нәкышдер калебем үзә[10].

Гыйшкы җамыни[11] нуш идүбән[12],
Мәсте лаякыл…[13]
Йөрер ирдем кәндү белмәй,
Дивана[14] һәр замани.

Һәр табибә[15] уградымса[16]
Дәрдем айды бер тәмар[17].
Кыйлды бәни ибтидадин[18]
Ул газдә[19] бәлки би-мәр[20].

---

[1] Кәндем – үзем.

[2] Нәбиләр сөннәте – пәйгамбәрләрдән калган йола.

[3] Көймәкем – көюем. Бу сүз «кимәкем» рәвешендә генә язылган. Кием «кию» турында дип аңлап булмыймы икән.

[4] Гафләт галәмендә – ваемсыз дөньяда.

[5] Туз – тузан.

[6] Йай – җәя.

[7] Никәр – сылу.

[8] Шәкел – сурәт.

[9] Филхәл – шунда ук.

[10] Калебем үзә нәкышдер – күңелемдә бизәк.

[11] Җам – тустаган, җам-аяк.

[12] Нуш идүбән – авыз итеп, эчеп.

[13] Мәсте лаякыл – исерек.

[14] Дивана – акылдан шашкан, тиле, юләр.

[15] Табиб – доктор.

[16] Уградымса – туры килсәм дә, очрасам да.

[17] Дәрдем айды бер тәмар – чиремне бер авыруга сабышу гына дип әйттеләр.

[18] Ибтидадин – баштан ук.

[19] Газдә – ?

[20] Би-мәр – исәпсез.

Бу җиһан золмәтә дүнде[1]
Нә шәмсе ва, нә сираҗ[2].
Йөрер ирдем золмәт эчрә
Дәрдемә эстәп гыйлаҗ[3].

Мөст[4] һәр нә шул никарән
Сәкасендин[5] бән гариб[6],
Гизәр иркән кемсә белмәй
Әҗнәбиме[7] я кариб[8].

Гыйшкыдин гаклым китүбән,
Бәхре әфкяра[9] батып
Бәгъремә санчып уятты
Керпек укилә[10] атып.

Күземә ачдыкда[11] күрдем,
Дидем: «И шәмсе җәмал,
Шәфкать ит, үлдермә бәни,
Ошбу хәл куеныңа ал».

Күрдекем[12] сәгать җиһанда
Китте золмәт – улды нур.
Сән кояшсын яки айсын,
Яки җәннәт эчрә хур.

Бән сәни әүвәл күргән соң
Көн-бәкөн бәгърем кәбаб[13].
Әйлә дәрман дәрдемә[14] сән,
Кыйлмагыл бәни хәрап.

Белмәделәр һич әтабыйн[15]
Бу фәкыйрнең гыйлләтен[16],
Кыйл гыйлаҗи[17] сән Ходачөн
Кыйлма аслан ниятин[18].

---

[1] Золмәтә дүнде – караңгылыкка чумды.
[2] Сираҗ – йолдыз(лар)
[3] Гыйлаҗ – дәва, дару.
[4] Мөст – ?
[5] Сәкә – ?
[6] Гариб – читтә йөргән кеше.
[7] Әҗнәби – чит кеше.
[8] Кариб – үз кеше, якын кеше.
[9] Бәхре әфкяр – уй (сагыш) диңгезе.
[10] Укилә – угы белән.
[11] Ачдыкда – ачканда, ачкач.
[12] Күрдекем – күргәч.
[13] Бәгърем кәбаб – йөрәгем куырыла, яна.
[14] Дәрдемә дәрман әйлә – чиремә дәва тап.
[15] Әтабыйн – табиблар, докторлар.
[16] Гыйлләт – чир.
[17] Гыйлаҗи кыйл – дәвала.
[18] Кыйлма аслан ниятин – һич тә бүтәнчә ният итәсе булма.

Бән бу хәлә җан вирерсәм
Сәңа улыр чук[1] гөнаһ.
Нәфгый кыйлмаз[2] тәүбә, зарый,
Йөз-бәң идеп «аһ» вә «аһ».

Адәм үлтермәк гөнаһы
Барчалардиндыр олугъ,
Назмы Коръән һәм китаплар
Бу мәган[3] илә тулуг[4].

Гөлгә гашый кош кеби бән
Гөл йөзеңә гашыйкым.
Юк тәмәннәм гайре сәндин
Бер Ходадин, гашыйкым.

Ай кеби йөзең илә
Йай[5] тик кашың күстәр бәңа,
Бу җиһан һәм ул җиһанда
Рәхәтем тәхкыйк[6] сәна.

Бал кеби татлы телеңдин
Вирче зәррәсен[7] безә,
Дилникәрем[8], һәр заманда
Ихтыяҗым чук сезә.

Халкый галәм хәсәд улды[9]
Безләре яхшы – яман.
Дәкаикъ[10] күп көллисендин[11]
Безләрне кыйлды аман[12]…[13]

---

[1] Чук – күп.
[2] Нәфгый кыйлмаз – файдасы тимәс.
[3] Мәган – мәгънәләр.
[4] Тулуг – тулы.
[5] Яй – җәя.
[6] Тәхкыйк – чынлап.
[7] Зәррә – кисәкчә.
[8] Дилникәр – чибәр, ягымлы кыз.
[9] Хәсәд улды – көнләштеләр.
[10] Дәкаикъ – минутлар.
[11] Көллисе – барчасы.
[12] Аман кыйлды – имин итте, саклады.
[13] Бу шигырь күчерелгән бер бит кәгазь фарсыча кульязма китапның (№ 530ф. (5659)) эченә 3 бит итеп ябыштырылган. Кәгазь бик нык каралган, китап арасына кергәнче дүрткә бөкләнгән булганлыктан, бөгем өлешләрендәге язулар кырпылган. Күчермә XVIII гасыр азакларында эшләнгән булса кирәк. Хиснең үсешен («тарихын»!) тәфсилле һәм төгәл, оста тасвирлавы белән бу шигырь гыйшкый шигырьләр арасында үзенә аерым бер урын тота.

## Кыйтгалар

### *Белеме барның күрке бар*

Мәгърифәтне белгән адәм
Һәм гөлдер һәм дә чәчәк.
Мәгърифәт белмәгән адәм
Һәм сыгырдыр[1] һәм дә ишәк[2].

### *Тән җәзасы белән бер*

Һәр кеше кем билге өчен
Китабым читен бөгәр.
Шөйлә бел кем – ул кеше
Башым кисеп, каны түгәр.

Бу парча элекке татар тормышында китапка ничек ихтирам белән карауны ачып бирә. Әхлак мәсьәләләренә багышланган татарча бер кульязма китапның баштагы буш кәгазенә Г. Кандалыйның «Аерма» шигыре һәм 1866 елга караган хроник истәлекләр белән беррәттән язылган.

### *Сулгач-сулгач икәүләп*

Сәрви каде[3] саясендин[4]
Сулды гөл – нитмәк кирәк?
Сәрвидин табут кыйлып,
Гөлдин кәфен итмәк кирәк[5].

---

[1] Сыгыр – сыер.

[2] Бу шигырь төрле шигырьләр тупланган кечкенә кулдагы 36 битле дәфтәр эчендә килә (№ 240т. (2709), 33 б.). Дәфтәр XIX гасыр урталарында язылган. Бу шигырьдән өстә төрек һәм азәрбайҗан әдәбиятлары классигы Мөхәммәд Фөзулиның элек татарлар арасында бик популяр булган бер строфа шигыре килә:

Ераклык бер бәладер кем,
Грифтар улмаян белмәз.
Җәфаны чикмәян гашыйк,
Сафаның кадрени белмәз.

Мондагы «ераклык» сүзе урынында М. Фөзулиның үзендә «мәхәббәт» сүзе килә, димәк, татар укучылары билгеле шагыйрьләрнең дә шигырьләрен шартына-хәленә, кайсы вакытта кирәк булуына карап үз җайларына бора торган булганнар.

[3] Кадь – кәүсә. Сәрви – кипарис агачы, монда безнең җирдә үсә торган «сәрви агачы» – акация мәгънәсендә түгелме икән.

[4] Сая – күләгә, саясендин – күләгәсеннән.

[5] Бу парча XIX гасыр урталарында күчерелгән, төрле гыйшкый һәм фәлсәфи шигырьләр язылган, теркәлгән кәгазьләр эчендә килә (№ 1032 т. (4546), 4б кгз.).

### *Нәфесен тыйган кеше солтан булыр*

Чи тирене иләсәң – олтан улыр,
Нәфесене тыйган кеше – солтан[1] улыр[2].

### *Сер саклауда дус була алмый*

И газизем, димә[3] сереӊ дустыӊа,
Чөнки дустыӊ дусты булыр –
Ул да сөйләр дустына[4].

### *Чамалап кылансаң фәрештәгә тиң булырсың*

Аз йимәк,[5] аз оемак,[6] аз сөйләшмәк,
Кемдә кем җәмгъ улды,[7] бел аны – мәләк[8]!

* * *

Ышанма икән ата-ана байлыгына,
Таянма икән йөзләрнеӊ айлыгына.

* * *

Йир астында су улмаса,
Йир өстенә чыгармиде.
Фираклык[9] каты булмаса,
Бәнем биӊезем[10] суралмиде.

* * *

Бер кәфәстә[11] карга илән тутый кош,
Бу икәнеӊ хәле булды мөшкел эш.

---

[1] Солтан – император.

[2] Бу парча XIX гасыр урталарында күчерелгән. №2839 т. (4826) гарәпчә кулъязма китапның алдына ябыштырылган кәгазьгә язып куелган.

[3] Димә – әйтмә.

[4] Бу парча №1032 т. (4546) кулъязманың 3б кәгазендә килә. XIX гасыр урталарында күчерелгән. Шул ук парча № 1973 кулъязманың 1б кәгазендә дә язылган.

[5] Йимәк – ашау, ризык җыю.

[6] Оемак – йоклау, ою.

[7] Җәмгъ улды – тупланды, бөтенесенә ия булды.

[8] Мәләк – фәрештә.

[9] Фираклык – аерылышу.

[10] Биӊез – йөз, чырай.

[11] Кәфәс – читлек.

* * *

«Каләм, куй инде, язмагыл күп,
Бәнем җанымны хафа кыйлмагыл күп».
Диде каләм: «Дәхи азрак язасы,
Укып китсен туганларның мәзасы[1]».

* * *

Моны ник яздың дип кыйлма мәламәт[2],
Ки калсын без фәкыйрьдин бер галәмәт[3].

[1] Мәзасы китсен – һәвәсләнеп, кызыксынып китсеннәр.

[2] Мәламәт кыйлма – гаеп ташлама, үпкәләмә.

[3] Галәмәт – билге.

Бу парчалар XIX гасырның 70 нче елларында Казан артындагы Түнтәр авылында язылган шигъри җыентык эчендә килә (№ 1973). I парча – 145б кгз., II – 2а кгз., III – 164а кгз., IV – 162а кгз., V – 36б кгз., VI – 2а кгз.

УДК 930

***Н.Г. Гариф***

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫНА КАРАГАН ЭПИГРАФИК ТАШЛАРНЫ БАРЛАУ, ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ АЛАРГА СТАТИСТИК АНАЛИЗ

Статья посвящена исследованию эпиграфических памятников Казанского ханства.

Нами анализированы все до сих пор известные, обнаруженные или вновь найденные надгробные памятники. Для их комплексного изучения необходимо привлечение и других категорий источников – письменных, фольклорных, этнографических, топонимических.

Полученные материалы могут быть использованы при изучении проблемы этногенеза и происхождения народов, а также для уточнения границ Казанского ханства. Материалы и результаты работ планируется представить к обсуждению на конференциях, опубликовать в научной и популярной литературе.

**Ключевые слова:** надгробные памятники, феодально-вассальные отношения, города, населенные пункты.

The article is devoted to the study of the epigraphic monuments of the Kazan Khanate.

We have analyzed all the still known, discovered or newly found tombstones. For their comprehensive study, it is necessary to attract other categories of sources – written, folklore, ethnographic, toponymic.

The materials obtained can be used to study the problem of ethnogenesis and the origin of peoples, as well as to clarify the boundaries of the Kazan Khanate. Materials and results of the work are planned to be presented for discussion at conferences, published in scientific and popular literature.

**Keywords:** tombstones, feudal-vassal relations, cities, towns.

Казан ханлыгы чорына караган документлар күп сакланмаган. Шул сәбәпле ханлыкның тарихи, мәдәни һәм матди культурасын ачыклау, икътисади һәм хуҗалык тормышын өйрәнү, төбәкнең тарихи географиясен барлауда археология, эпиграфика һәм нумизматика материаллары кыйммәтле чыганак булып тора.

Идел буеның атаклы археологы А.П. Смирнов: *«Кабер өсте язулары Алтын Урданың барлык өлкәләреннән бары тик Болгар җирендә генә таралган»,* – дип яза. Галимнәр бу эпитафияләрнең нәкъ менә болгарларда таралуын ислам дине, мәдәнияте һәм мәгарифе үтеп керү белән аңлаталар. Әлеге үзенчәлек Болгарда, Алтын Урданың дәвамчысы булган Казан ханлыгында да таралыш алган. Шул сәбәпле ташъязма чыганакларны өйрәнү ханлык чорын ачыклауда мөһим роль уйный.

XIX гасырда, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары тарихын ачыклау максатыннан, археологик тикшеренү эшләре

башланып китә. 1877 елда Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (ОАИЭ) төзелә. Җәмгыять эшчәнлегендә И.А. Износков, С.М. Шпилевский, К.И. Невоструев, Н.А. Толмачев кебек тарихчылар актив катнаша. Алар Казан ханлыгының төрле төбәкләрендә урнашкан тарихи урыннарны, әлеге җирлектәге эпиграфик һәйкәлләрне барлау һәм өйрәнүгә күп хезмәт куялар.

Әлеге җәмгыять эшчәнлегенә, туып килүче милли тарих мәктәбенә фәнни юнәлеш бирүчеләр буларак саналырга хаклы, татар тарихчылары Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Г. Әхмәрев, Р. Фәхретдин һ. б. кушылып китә.

Татар халкы үткәнен өйрәнүче тарихчылар өчен совет чорының башлангычы булган – 1920–1930 еллар аралыгында яңа мөмкинчелекләр туа. М.Г. Худяков, Һ.М. Атласи, Г.А. Гобәйдуллин һ. б. тарихчылар Казан ханлыгының үткәнен өйрәнүне, аның дәүләт төзелешен, иҗтимагый-сәяси һәм икътисади тарихын ачыклауны үзмаксат итеп куялар. Әлеге эшчәнлеккә ханлык чорыннан ук сакланып калган кабер ташларындагы язулар да ачыклык кертү сәбәпле, аларны өйрәнү эшчәнлегенә дә ихтыяҗ туа.

Әмма яңарыш дәвере озак дәвам итми. Сталинизм чорында – 1930 еллардан алып 1950 елларның уртасына чаклы – Казан ханлыгы тарихын өйрәнү, партия күзлегеннән чыгып, мәгълүм бер кысаларга куып кертелә. Шуңа да карамастан, шушы чор тарихчылары Н.И. Воробьев, Н.Ф. Калинин, Х.Г. Гыймади, Ф.Ш. Мөхәммәдьяров, текстолог Г.М. Рәхим, эпиграфист Һ.В. Йосыпов һ. б. тарафыннан Казан ханлыгы чорына караган күп кенә археологик, эпиграфик һәм башка язма мәгълүматлар туплана һәм фәнни әйләнешкә кертелә.

Совет чорында эпиграфик чыганакларны барлау, өйрәнү дәвам итә. Болгар, Алтын Урда, ханлык чорларына караган зират-каберлекләрнең каберташ язмалары А.Х. Халиков, Р.Г. Фәхретдинов, Ф.С. Хәкимҗанов, Җ.Г. Мөхәммәтшин, М.И. Әхмәтҗанов, һ. б. тарихчылар, текстологлар тарафыннан өйрәнелгән.

Соңгы елларда кабер ташларын өйрәнү эшенә Н.И. Исмәгыйлев (Нәккаш), Р.Ф. Мәрдәнов, И.Г. Һадиев, И. Мөстәкыймов кебек мәгълүм тарихчылар өлеш кертте.

Шуңа да карамастан Казан ханлыгы дәверенә караган кабер ташлары әле һаман да табыла һәм өйрәнелә тора. Мәсәлән, 1957 елда XVI гасырның беренче яртысына караган 150 эпиграфик һәйкәл билгеле булган. Әлеге һәйкәлләр 50 дән артык торак урыннары янында урнашкан [Юсупов, 1960]. Бүгенге көндә XVI гасырның беренче яртысына караган һәйкәлләрнең саны (туксанга якын торак урыны тирәсендә) 260 ка җитә *(Татарстан җирлегендә урнашканнары гына исәпкә алынды)*. Бу очракта ханлык җирләренең бер өлеше *(Татарстан Республикасыннан тыш)* булган урыннарда эпиграфик һәйкәлләрнең соңгы елларда актив рәвештә өйрәнелмәвен дә билгеләп узарга кирәк. Мәсәлән, 1955 елларда Чуваш Республикасы җирлегендә урнашкан 22 торак урынында мөселман кабер ташлары

билгеле булган. Аларның таралыш чиге Сура елгасына чаклы җиткән [Воробьев, 1956].

Казан ханлыгының татар халкы күпләп яшәгән үзәк җирләрендә бүгенге көнгә 290 кабер ташы билгеле *(тулаем алганда 296 таш. Фәнни яктан өйрәнелгәннәре генә исәпкә алынды).* Әлеге язулы кабер ташлары 93 авыл биләмәсендә урнашкан *(Биектау районының 21 авылында 77 таш; Арча, 16–60; Әтнә, 8–52; Яшел Үзән, 13–26; Питрәч, 8–17; Саба, 7–10; Балык бистәсе, 4–8; Теләче, 4–9; Кайбыч, 2–6; Балтач, 2–3; Югары Ослан, 2–3; Тәтеш 2–2; Апас, 1–1; Лаеш, 1–1; Мамадыш, 1–1; Алексеевск, 1–1;* Казан шәһәре биләмәсендә – 11 *(бер таш 1996 елда Благовещение соборында, бишесе 2004 елда Кремль биләмәсендә, берсе Кремль урамының Дәүләт музее (метро) биләмәсендә, ике кабер ташының кисәкләре ханнар зираты урынын археологик тикшерү вакытында)* кабер ташы табылды.

Эпиграфик һәйкәлләр Казан шәһәре тирәсендәге 16 район биләмәсендә урнашкан.

Кабер ташларының урнашу географиясе дә игътибарга лаек. Мәсәлән: ханлык чорына һәм аның үзәктәге җирләренә караган ике кабер ташы Казаннан төньякка таба 120 чакрым ераклыкта урнашкан *(Балтач районы, Смәил авылы).* Казаннан иң көнчыгыш тарафка таба урнашкан таш – 115 *(Мамадыш районы, Бөрсет Сукачы авылы)*, иң көньяк тарафтагысы 130 чакрым ераклыкта табылган *(Тәтеш районы, Мантово авылы).* Иң көнбатыштагы ханлык чорына караган кабер ташы, Казаннан 160 чакрым ераклыкта, Чуваш Республикасының Ядрин районы, Чебак авылында урнашкан.

Язма чыганаклар буенча, Казан ханлыгының үзәк җирләрендә генә дә 700 торак урыны булуы мәгълүм *(бу исемлеккә юкка чыгарылган, язу-теркәү кенәгәләрендә «пустошь» дип билгеләнгән һәм археологик һәйкәл буларак искә алынган авыллар керми).* Казан шәһәреннән 25–30 чакрым ераклыкта урнашкан бүгенге татар авылларының күбесе ханлык чорындагы авыллар белән тәңгәл килә. Шул сәбәпле, эпиграфик һәйкәлләрнең әлеге татар авыллары белән янәшә табылуы да игътибарга лаек.

Мисал өчен, бүгенге Лаеш районы җирлегендә ханлык чорында 93 татар авылы булган *(1992 елда район биләмәсендә урнашкан 70 авылның бары 8 генә татар авылы)* [Галлямов, 1997]. Шул ук вакытта Лаеш районында бары бер язулы кабер ташы табылуы билгеле *(элекке Япанчы авылы биләмәсе).* Билгеле ки, аның сәбәбе – Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар халкының бу төбәктән тулаем куылуы һәм бушап калган җирләргә урыс халкын һәм яңа чукындырылган башка халыкларны күчереп утыртуда. Килгән халык тарафыннан кабер ташлары юкка чыгарылган һәм хуҗалык эшчәнлегендә кулланылган.

Югарыда билгеләп узылганча, татар халкы шәһәрләр тирәсеннән – 30, зур елгалардан 15–20 чакрым ераклыкка куылган, ә аларның торак урыннары юкка чыгарылган яисә яулап алучылар тарафыннан

үзләштерелгән *(урыс колонизациясе ханлыкның үзәк җирләрендә урнашкан 206 авылны һәм 60 лап бушап калган авылларны үз эченә алган)* [Измайлов, 2003]. Әлеге очрак эпиграфик һәйкәлләрнең таралышына һәм сакланышына да йогынты ясаган. Мәсәлән: Биектау районы биләмәсендәге кабер ташлары Казан шәһәреннән 15–25, Яшел Үзәндәгеләре – 30, Питрәч районындагылары – 45, Лаеш районындагысы – 50 чакрым ераклыкта гына сакланып калган.

Казан шәһәрендә зур күләмдә археологик тикшерү эшләре башланганчы, 1814 елда төзелеш эшләре вакытында табылган бер кабер ташының сакланып калганлыгы гына билгеле иде *(хәзерге Кремль урамы, Дәүләт музее биләмәсендә табыла)* [Мәрҗани, 1989; Фукс, 1817]. 1530 ел белән билгеләнгән әлеге кабер ташы татарлар, губернатордан рөхсәт алып, Мәрҗани мәчете стенасына урнаштыру аркасында гына бүгенге көнгәчә яхшы сакланган.

Графиктан күренгәнчә (1 нче рәсем), Мәскәүнең колониаль сәясәте нәтиҗәсендә татарларның Казан шәһәре тирәсеннән куылуы эпиграфик һәйкәлләрнең саклануш дәрәҗәсендә дә билгеләнә. Килгән халык һәм шәһәр тирәсендә урнашкан чиркәү-монастырь җир биләмәләре хуҗалары ислам динен чагылдырган кабер ташларына тискәре караштa булган. Риваятьләр, язма истәлекләр буенча, кабер ташлары чиркәүләр, таш биналар төзелешендә һәм башка төр хуҗалык эшләрендә кулланыла *(мәсәлән, 1996 елда Благовещение соборы стенасында мөселман кабер ташы табыла)* [Нәккаш-Исмәгыйль, 1997].

Эпиграфик һәйкәлләрне өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләре белән хронологик тәртиптә танышканда, XX гасырда да кабер ташларының саны кимү, бер өлешенең эзсез юкка чыгуы күзәтелә. Тарихи һәй-




1 нче рәсем. Һәйкәлләрнең Казаннан читтә урнашуы һәм хисабы.
***А*** *– Казан;* ***Б*** *– Шаһгали авылы;* ***С*** *– Алат;* ***Д*** *– Хан гаскәре урнашкан төбәк;* ***Е*** *– Арча;* ***F*** *– Мишә-Тамак шәһәрлеге (Эзмә җирлеге);* ***G*** *– Чаллы шәһәрлеге;* ***H*** *– Казан ханлыгы үзәк җирләренең төньяк чиге.*

кәлләр табигать тарафыннан да, җирле халыкның тырышлыгы белән дә юкка чыгарылган. Элекке чорларда халыкның төрле хорафатларга бирелүе, дингә бәйле рәвештә гарәп язулы ташларга ихтирам белән каравы кабер ташларының сакланышын гасырлар буена тәэмин иткән. Узган гасырдагы үзгәрешләр – дингә каршы көрәш, җирне уртак милек итү, көчләп күмәкләштерү – борынгы зиратларга һәм алардагы кабер ташларының сакланышына тискәре йогынты ясаган *(1999 елда Балык бистәсе районы, Чураш авылы янындагы кырдан табылган ташларның берсе 1530 елга карый. Борынгы зират революциягә чаклы халык тарафыннан сакланган)* [Гариф, 2006].

Казан ханлыгы чоры эпиграфик һәйкәлләре үзәктән читтәге төбәкләрдә дә сакланган. Казаннан 330 чакрым ераклыкта, төньяк тарафта урнашкан төбәк бүгенге көндә Киров өлкәсе Слободск районы Нократ (Кариле-Карино) авылы буларак билгеле. Бу авылда югары катлау ияләренә куелган 3 кабер ташы бик яхшы сакланган.

Ханлык чорына караган эпиграфик һәйкәлләр бүгенге Чуваш Республикасы биләмәсендә дә саклана. Гарәп язулы ташлар урнашкан борынгы зиратлар *(сирәк кенә рун язулы ташлар да очрый)* Чебоксар районының Яуш, Моргауш районының Ирхкасы, Цивиль районының Тойсин авыллары зиратларында урнашкан. Әмма язулы ташларның төп өлеше Чуваш иленең көнчыгыш, һәм көньяк тарафтагы биләмәләрендә сакланып калган. *(Козлов, Урмар, Янтык Ялчык, Батыр районнарында)* [Иванов, 2000]. Санап үтелгән районнардагы ташларның зур өлеше безнең тикшеренүләргә керми калдылар.

296 кабер ташының туксаннан артыгында ташның куелу вакыты, таш куелган шәхеснең исеме, дәрәҗәсе, ташны куючы һәм башка төр мәгълүмат сакланып калган. 18 ташта җирләнүченең «кяфер кулындин», «Мәскәү», яисә «урыс явы килгәндә» шәһит китүләре турында искә алынган. Сакланып калган эпиграфик һәйкәлләрнең санында һәм эшләнеш дәрәҗәсендә дәүләтнең тыныч яшәеш чорындагы икътисади үсеше һәм сугышлардан соң туган авырлыклар да чагылыш таба (2 нче рәсем).

Язмалардан күренгәнчә, әлеге эпиграфик һәйкәлләр күп очракта югары катлау вәкилләренә: дәүләт хезмәтендәге җитәкчеләргә, гаскәр башлыкларына, абруйлы дини руханиларга, эре җир биләүчеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына куелган.

Дәүләт хезмәтендәге югары катлау кешеләре Казанда яшәсәләр дә, аларның хан ярлыгы белән беркетелгән, хан тарафыннан бүләк ителгән җир биләмәләре, авыллары булган. Еш кына җәй көне алар шунда ял иткәннәр, монда аларның утарлары, җәйге йортлары булган, хезмәтчеләре яшәгән. Вафат булган очракта да, аларны күбесенчә үз утарларында җирләгәннәр. Акрынлап гаилә каберлекләре дә барлыкка килгән. Бер үк урында бер үк типтагы кабер ташларының куелуы шул хакта сөйли. Шундый ук ташлар җирле идарәчеләрнең югары катлау кешеләренә дә куелган. Кабер ташлы зиратлар күп очракта зур мәйдан биләми. Шул сәбәпле гади игенче, терлекчеләрнең аерым




2 нче рәсем. Еллар хисабына бәйле куелган кабер ташларының саны.
***А–В*** *– Иван III тарафыннан 1467, 1469, 1478, 1482, 1484, 1485 һәм 1487 елларда оештырылган сугышлар.* ***В–С*** *– 1508–1523 еллар арасындагы тыныч тормыш;* ***С–Д*** *– 1523–1530 еллардагы Казанга каршы оештырылган сугышлар;* ***Д–Е*** *– 1530–1547 еллар арасындагы тыныч тормыш;*
***Е–F*** *– 1540 еллардан соң Казанга каршы оештырылган сугышлар.*

зиратларга җирләнүләре турында да фикер йөртергә мөмкин. Бай, мәһабәт каберташлар янында гади, кечкенә ташлар очрамый. Әлеге фикер таш язмаларга анализ ясаганнан соң да ныгый.

Казан ханлыгының төп байлыгы – җир. Ханлыктагы җирләр, дәүләтнең иминлеген тәэмин итү чарасы буларак, хан тарафыннан үзенең якыннары, дәүләт идарәсендә урын биләгән төрле дәрәҗәдәге бәк-морзалар, хәрби оглан-казаклар, дини вакыф биләмәләре, җирле бәкләр һәм башка сыйнфый баскычта торучылар арасында бүленгән. Казан ханлыгының матди яктан яшәеше җир бүленеше һәм салым җыю системасы аша тәэмин ителгән. Ханлык җирләре салым җыю өлкәләре – даругаларга һәм вассал олысларга бүленгән. Даругалар үз чиратында хәрби берәмлекләр: йөзләр һәм уннардан торган. Олыслар – ханлыктагы феодал вассал биләмәләр. Олыс җирләренә ия булу хокукы нәселдән-нәселгә күчү принцибына нигезләнгән. Феодал вассаллык мөнәсәбәтләренә тархан (сөергал) ярлыклары аша кануни төс бирелгән. Югары катлау кешеләре тархан (сөергал) биләмәләрен нәселдән-нәселгә тапшыру өчен тырышкан. Феодал вассаллыкның нигезендә хәрби хезмәт, ясак җыю һәм башка төр салымнар аша түләү системасы яткан. Хан, дәүләт җирдә эшләүче һәм шул җирдән ясак түләүче халыкка иминлек тудырган, аларның хокукларын яклаган.

Дәүләттәге феодал вассаллык мөнәсәбәтләре җир бүленешенә, дәүләткә хезмәт, дини һәм милли тормыш иминлегенә бәйле урнашкан. Казан ханлыгында җир, төп байлык буларак, җир биләүченең социаль һәм сәяси дәрәҗәсен (урынын) билгеләгән. Югары катлау вәкилләре үз биләмәләрендә тулы хакимлеккә ия булу хокукын алганнар [Гариф, 2010].

Казан ханлыгындагы сыйнфый бүленеш һәм ханлыкның яшәеш системасы эпиграфик һәйкәлләр буенча да ачыклана. Кабер ташлары язмаларындагы дәүләт идарәсе, хәрби, дини һәм җирле феодалларның исем-шәрәфләре, иерархик катламда тоткан урыннары һәм аларның кул астында булган биләмәләре чагылыш таба. Эпиграфик һәйкәлләрне өйрәнеп, аларга анализ ясап, ханлык чорында үзәк белән төбәкләр арасында урнашкан хокукый мөнәсәбәтләрне ачыклау мөмкинчелеге дә туа.

Татар эпиграфик кабер ташларыннан түбәндәге мәгълүматларны алырга була:

1) таралу географиясенә бәйле халыкның урнашуы;

2) феодалларның титул-дәрәҗәләренә бәйле хакимият төзелеше;

3) сәяси-сыйнфый һәм дини катлауларның бүленеше;

4) ташларның урнашуына бәйле торак урыннары, олы юллар яисә сугыш кырлары турында мәгълүмат;

5) шул чорда традицион язу үрнәге, башлам текстлары, бизәк-орнаментлар, геометрик күләм һәм форма үзенчәлекләренә бәйле сәнгать үсеше;

6) ташлардагы еллар исәбе һәм исемнәрнең үзенчәлегенә бәйле мәгълүмат аша җирлектәге халыкның яшәеш чорын һәм төрле үзгәрешләрне ачыклау.

**Әдәбият**

*Воробьев, Н.И., Львова А.Н. Романова Н.П., Симонова А.Р.* Чуваши. Ч. 1, Чебоксары, 1956. С. 38–39.

*Галлямов Р.Ф.* Селения Лаишевской стороны в XVI – в начале XVII вв. // История Лаишевского края 1997. С. 63–82.

*Гариф Н.Г.* Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. Казань: ТФА Тарих институты басмаханәсе, 2010. 128 б.

*Гариф Н.Г.* Казан ханлыгы. (Оешу тарихы, идарә системасы, административ бүленеше һәм феодал вассаллык мөнәсәбәтләре.). Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 175 б.

*Иванов В.П., Николаев В.В., Димитриев В.Д.* Чуваши: этническая история и традиционная культура. М., 2000.

*Измайлов И.М.* Татарский народ после 1552 года: потери и приобретения. // Материалы научно-практической конференции. Казань, 2003.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр.) / тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

*Нәккаш-Исмәгыйль Нәҗип.* Христиан чиркәвендә мөселман ядкәрләре // Мәдәни җомга. 1997. № 18. Б. 14.

*Фукс Карл.* Краткая история города Казани. Казань. 1817.

*Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 165 с.: ил.

**Казан ханлыгы чоры ташларына уелган аятьләр һәм гыйбарәләр**

1. Аллаһыдан башка илаһи зат юк.
2. Аллаһының әмереннән качып булмый.
3. Ул [Аллаһы Тәгалә] үлемсез, ә башка һәрбер тереклек иясе үләчәк.
4. Дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр.
5. Бары тик җиңелү белмәс кодрәт иясе, Олуг Аллаһ кына мәңге калачак *(55 – Рахмән сүрәсе, 27 аять).*
6. Җир йөзендәге җанлыларның барысы да юкка чыгачак *(55 – Рахмән сүрәсе, 26 аять).*
7. Аллаһу Тәгалә әйтте: «Һәрбер җан иясе үлем ачысын татыр. Аннан барыгыз да Безгә (Аллаһка) әйләнеп кайтырсыз». *(29 – Ганкәбүт (Үрмәкүч) сүрәсе, 57 аять).*
8. Аллаһу Тәгалә әйтте: «Һәм белми җан иясе кайсы җирдә үләсен». *(29 – Ганкәбүт (Үрмәкүч) сүрәсе, 34 аять).*
9. Дөнья – үләксәдер, аның артыннан куучы эттер.
10. Бу дөнья үләксәдер, аны этләр эзләп йөрер.
11. Күрәмен дөньяны вәйран (җимерек) булган хәлдә, берни дә мәңгелек түгел – Аллаһының моңа карары юк.
12. «Бу дөньядагы барлык авырлыкларга сабыр кеше дә вакытыннан алдан үлмәс».
13. «Үлем сине үз вакыты киләчәген искәртеп торыр, ә каберең кылган гамәлләреңнең сандыгы булыр».
14. «Үлем өчен бәхет килде... Ә бездән шатлык кош кебек очып китте..., аны эзләүчеләр инде табалмас».

***Гариф Нурулла Гыймадетдин улы,***
*тарих фәннәре кандидаты*

# ИСХАКЫЙНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ФИКЕР ДӨНЬЯСЫ ХАКЫНДА ЯҢА ХЕЗМӘТ

Китап күзәтү: **Ahmet Kanlıdere. Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshaki (1878–1954). İstanbul, Ötüken yay., 2019. 318 s.**

Истанбулның танылган Мәрмәрә университетында укытучы профессор, тарих фәннәре докторы Әхмәт әфәнде Канлыдәрәне төрек һәм татар галимнәре җәдитчелек хәрәкәте, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса һәм Заһир Бигиевләргә багышланган җитди хезмәтләре аша беләләр һәм хөрмәт итәләр. Менә быел Әхмәт әфәнденең татар тарихы һәм мәдәнияте белән бәйләнешле тагын бер китабы дөнья күрде: «Социализмнан төркичелеккә: Казанлы Гаяз Исхакый (1878–1954)» исемле хезмәте Истанбулда «Өтүкән» нәшриятында басылып чыкты.

Г. Исхакыйның тормышы, эшчәнлеге, иҗаты турында соңгы елларда Татарстанда шулкадәр күп язылды ки, инде бер әйтер яңа сүз дә калмагандыр, дип китапны укый башласам да, тиз арада фикеремне үзгәртергә мәҗбүр булдым: киңкырлы шәхесебез хакында белгәннәребез тулы түгел, яки беръяклы гына икән! Иң аз өйрәнелгән темаларның берсе – Г. Исхакыйның еш кына үзгәреп торган иҗтимагый-сәяси карашлары һәм бу үзгәрешләрне тудырган сәбәпләр. Игътибарын әлеге аспектка юнәлткән Ә. Канлыдәрә Г. Исхакыйның иҗтимагый-сәяси фикер мирасының четерекле булуын ул яшәгән чорда дөньяда сәяси халәтнең дә даими катлауланып торуы белән бәйли.

Татарстанда язылган күпчелек китап-мәкалә һәм диссертацияләргә Г. Исхакыйны кирәгеннән артык мактау, яки аерым тезисларның кабатлануы кебек сыйфатлар хас булуын сиземләгән автор китап ахырында бирелгән библиографиягә аларның күпчелеген кертә, ләкин үз хезмәтендә артык кулланмый, аның өчен төп чыганак булып Г. Исхакыйның һәм замандашларының вакытлы матбугатта чыккан язмалары хезмәт итә. Бу хосус, ягъни соңгы дәверләрдә безнең илдә язылган татарча-русча хезмәтләргә мөрәҗәгать итмичә, алардагы идея-фикерләргә иярмичә, беренчел чыганак белән эш итү – төрекчә басылган яңа китапның иң тәүге үзенчәлеге булып тора. Икенче үзенчәлек итеп, төрек галименең, Г. Исхакыйдан даһи ясамыйча, аны мактау яки тәнкыйтьләүне үзмаксат итеп куймыйча, фикер сөрешендә, эш-хәрәкәтләрендә ялгышырга-ашыгырга хакы булган табигый бер кеше итеп кабул итүе һәм аңа карата тыныч, мөмкин кадәр тарафсыз, объектив караштa торырга омтылышын күрсәтер идем.

Китап кереш сүз, өч бүлек, кушымталар һәм библиографиядән тора. Беренче бүлек Г. Исхакыйның фикер дөньясының формалашу процессына, Рәсәйдәге тормышы һәм әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә багышлана, анда язучының Истанбул белән элемтәләре, миллиятчелек фикерләренә якынаюы, большевизм җилләренә каршы торышы һәм бу елларда язган әдәби әсәрләре турында сүз бара. Автор Г. Исхакыйга тәэсир иткән күренекле шәхесләр буларак Әхмәд Мидхәт, Нәмык

Кәмал, Габделхак Хәмид, Каюм Насыйри кебек затларны атый, татар халык авыз иҗаты, рус әдәбияты белән кызыксынуын, Йосыф Акчура, Садри һәм Әхмәдһади Максудиләр, Фатих Кәрими, Исмәгыйль Гаспралы кебек күренекле шәхесләр белән булган мөнәсәбәтләрен, кулга алыну тарихын, туктаусыз идеологик юнәлешен үзгәртеп торуы сәбәпләрен тикшерә. Гасыйм Мансуровның «Беренче революция елларында татарлар» исемле хезмәтендә 1905 елда «кып-кызыл таңчы» буларак мәйданга чыккан Г. Исхакыйның эсер булып китүен, аннан соң миллиятчелек, пантюркизм белән мавыгуын, шул рәвешле сигез тапкыр идеология алыштыруы турындагы фикерен китереп, Ә. Канлыдәрә аның белән күпмедер күләмдә килешә һәм Г. Исхакыйның үзе инанган фикергә, артын-алдын уйламыйча, соңы ни булып бетәсен фаразламыйча бирелгәнлеген холкына хас бер сыйфат дип аңлата.

Икенче бүлектә Г. Исхакыйның госманлы төрекләренең иҗтимагый тормышына ясаган тәэсире, чыгышлары һәм язган мәкаләләре анализлана. Бу бүлек шактый киң булып, уннан артык бүлекчәдә Казан татарларының өстенлекләре, татар әдәбияты һәм халыкчылык (народничество), уртак төрки тел мәсьәләсе, Рәсәйдә яшәгән төрки халыкларның үзара ярдәмләшүе һәм берлеге, төрки берлекне оештыру юлындагы комачаулаулар, төрки хатын-кызларның азатлыгы, латин әлифбасына күчү кебек шул заман өчен көн кадагында торган проблемаларга Г. Исхакыйның карашлары тирәннән тикшерелә.

Г. Исхакыйның һәрбер язган мәкаләсе берәр мөһим фикерне бәян итүгә яки актуаль мәсьәләне чишү юлын күрсәтүгә багышланган. Аның 1918 елга кадәр язган мәкаләләрендә татарлык фикере үзәктә тора, татарларның госманлы төрекләре һәм башка төрки халыклар белән чагыштырганда мәдәни яктан өстенрәк булуы, төрки галәмнең татарлар артыннан барырга тиешлеге ассызыклана. Төркия җөмһүрияте төзелгәннән соңгы дәвердә язган мәкаләләрендә исә төрки халыклар арасында булган бөтен аерымлыкларны юк санап, язучы аларның берлегенә ирешү фикерен яклый, бу төрки берлекнең башында Төркия дәүләте торачагына инана. Г. Исхакыйның башка төрек зыялыларыннан аермалы хосусияте итеп, китап авторы аның социалист фикерләре йогынтысында калган килеш, милли кыйммәтләргә нык рәвештә бәйләнуын, секуляр фикерләрне кабул иткән хәлдә, кайбер мәсьәләләрдә (мәсәлән, латин әлифбасына күчү, хатын-кыз азатлыгы хосусларында) консерватив позициядә торуын әйтә.

«Гаяз Исхакый әсәрләрен язган вакытта гел практик файда турында уйлый иде. Көрәштәшләреннән берсе Нәҗип Гасрыйның да әйтүе буенча, ул халык өчен язучылардан иде. Әсәрләрен өслүб (стиль) һәм дөрес фактик мәгълүмат ягыннан артык килештерергә вакыты юк иде. Шуңа күрә аннан галимнәргә хас төгәллек таләп итү хаксызлык булыр. Әсәрләрен авыр шартларда язган һәм тиз арада матбугатка биргән. Аларның шактый зур өлеше – ясаган чыгышларының текстлары. Нәҗип Гасрый әйткәнчә, ул җитез язучы һәм каралама-черновикларын бик аз укып-төзәтүче иде», – ди автор (90 б.).

Г. Исхакый Ататөрек заманында үзенә тиешле уңай мөнәсәбәттән мәхрүм була, аның төрек сәясәтчеләренә һәм зыялыларына юнәлеш бирергә тырышып язганнары, Төркиядән читтә яшәгән төрки халыкларга игътибар итәргә чакырулары я бөтенләй җавапсыз кала, я кайберәүләрнең (мәсәлән, совет-төрек сәяси мөнәсәбәтләрен ныгыту яклы кешеләрнең) ачуын китерә. Төркиядә изоляция хәлендә яшәгән язучы 1927 елда Варшавага барып урнаша.

Өченче бүлектә Г. Исхакыйның Европадагы мәдәни һәм сәяси эшчәнлеге, «Милли юл» журналындагы язмалары, Идел һәм Урал буйларында большевиклар оештырган сәясәткә карата тәнкыйть фикерләре, 1933–1936 елларда Иерусалим, Палестина, Мисыр, Финляндия һәм Ерак Көнчыгышка ясаган сәяхәтләре вакытында күргәннәре, Европадагы киеренке сәяси вакыйгаларга карата әйткән фикерләре анализлана. «Милли юл» журналында Исхакый имзасы белән 141 мәкалә басыла, моннан тыш тагын «Милли юл», «Чыңгыз» имзалары белән басылган язмалар да аның каләменнән чыккан булырга тиеш дип, Ә. Канлыдәрә 11 ел буе чыккан «Милли юл»ның һәр санында бер яки ике мәкалә бастырган Г. Исхакыйның бу мирасы аз өйрәнелүенә гаҗәпсенә, Ә. Таһир, Х. Миңнегулов, Г. Галләметдинов, төрек галимәсе Ш. Гюнгёр һ. б. ларның бу темага язган хезмәтләре әлегә җитәрлек түгел, ди. «Милли юл»да Г. Исхакыйның 1929 елда «Кызыл Татарстан» газетасында аңа каршы язылган пычрак язмаларга биргән җаваплырына, аның «табышмак-шәхес» Галимҗан Идриси белән булган хосусый һәм сәяси каршылыкларына киңрәк тукталып, Ә. Канлыдәрә яңа архив документларын, Аяз Таһир Төркестан Идел-Урал вакыфында (Ayaz Tahir Türkistan İdil Ural Vakfı) саклана торган кайбер мәгълүматларны да фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Ул шулай ук «Милли юл» журналының Европада, аеруча Польшада киң таралган антисовет «Прометей» хәрәкәтенең бер органы булуы фикерен алга сөрә. Инглизчә чыганакларга таянып, Әхмәд әфәнде «прометейчылыкның» нидән гыйбарәт булуын аңлата, Г. Исхакыйның сепаратист фикерләрен украин миллиятчелеге, рус шовинизмы, казаклар хакында язган мәкаләләрендә күрә. Китапта шулак ук Мөслимәләр съезды һәм анда алынган карарларга, Рәсәй мөселманнары съездларына, Дәүләт Думасына мөнәсәбәтле Г. Исхакыйның матбугаттагы чыгышлары тикшерелә.

1917–1918 елларда татар һәм башкорт сәяси лидерларының үзара көрәшендә Зәки Вәлидинең тоткан урыны, Башкортстан һәм Татарстан автономияле республикалар төзелүгә кагылышлы фикерләре, 1928–1930 елларда Советлар илендә ислам дине һәм мөселман лидерларны үзара бәрелештерү сферасында оештырылган сәяси уеннар, бу уеннарда Н. Төрекулов һәм Г. Ибраһим кебек шәхесләрнең роле – Г. Исхакыйның «Яңа милли юл»да язган тәнкыйди язмаларындагы темаларның кайберләре генә. Ә. Канлыдәрә әлеге темаларга махсус тукталып, Г. Исхакыйның позициясен һәм ул дәвердәге сәяси шартларны объектив анализларга омтыла. Бүгенге Рәсәй шартларында яшәгән тарихчы яки әдәбиятчының, әлбәттә, мөһаҗәрәттәге Г. Исхакыйның

үзенчәлекле кискен һәм кыю сәяси фикерләрен бу кадәр ачык итеп язып чыгуы, язса да бастырып чыгаруы мөмкин түгел. Аерым бер пункт буларак, Ә. Канлыдәрә Г. Исхакыйның үз дәвере Төркия хөкүмәтенең мөһаҗир төркиләргә (Казан һәм Кырым татарларына, азәрбайҗаннарга) карата суык мөгамәләсен, аларның иҗтимагый оешмаларын, матбугат органнарын яптыруын тәнкыйть иткән язмаларына туктала. Совет матбугаты белән беррәттән төрекчә чыккан китап һәм газета-журналларны укып барган Г. Исхакый төрекчелек һәм госманчылык хәрәкәтләренә карата да үз карашын белдерә.

Вафатына кадәр соңгы унбиш ел буе Төркиядә калган әдип бары тик әдәбият белән генә шөгыльләнә, публицистик язмалар язмыйча, дәшми генә яши. Төрек җәмәгатьчелегендә мода хәленә килгән Көнбатыш хәйранлыгы аңа бер дә ошамый. Төрекчелек фикерләре актуаль булмаган 1940 елларда Г. Исхакыйның шәхесе дә, махсус оешмалардан башка, беркемне дә кызыксындырмый, дип нәтиҗә ясый китап авторы.

Китапка бирелгән кушымтада Г.Исхакыйның төрек матбугатында басылган ике дистәдән артык мәкаләсенең текстлары китерелә. Аеруча «Сират-ы мөстәкыйм», «Вакит», «Йени Кавкасйа» кебек журналларда басылган, ләкин Казанда чыккан унбиш томлыкка керми калган, керсә дә, анализланмаган язмалары бик әһәмиятле. Китап ахырында шулай ук берничә фоторәсем дә урнаштырылган.

Ә. Канлыдәрә язганнарның барысын да һичшиксез дөрес дип бәяләү, әлбәттә, бәхәсле, фәкать Г. Исхакый шәхесенә карата «читтән торып», рус-совет идеологиясе тәэсиреннән азат рәвештә ясалган фәнни анализ укучы өчен гаять тә кызыклы һәм яңа тоелачагыннан шөбһәм юк. Автор Г. Исхакый яшәгән чорны, совет һәм кемалчы идеологияләрне, әдипнең дусларын һәм дошманнарын, аның турыда кемнең ни әйткәнен вак нечкәлекләре белән белә. Хезмәтнең күзгә ташланган бердәнбер кимчелеге итеп шуны күрсәтеп була: автор ахырда үзенең барлык язганнарына тулаем бер йомгак ясамый, үз фикерләрен ныгытучы тиешле нәтиҗә өлеше булмагангамы, китапка исем биргән «социализмнан – төркичелеккә» гыйбарәсе соңында конкретлашып бетмичә, ничектер китап эчендә югалып кала кебек. Моның бер сәбәбе итеп, китапның башта ике зур мөстәкыйль мәкалә рәвешендә хәзерләнүен әйтергә була, икенче бер сәбәп тә бар: хезмәтнең кереш өлешеннән алда ике битлек «Өнсүз» бирелгән, Ә. Канлыдәрә үз тикшеренүенә гомуми йомгакны күпмедер күләмдә шунда ясый дип әйтеп була. Хезмәт тиз арада татарчага тәрҗемә ителер һәм Г. Исхакый мирасын өйрәнү эшендә мөһим чыганакларның берсенә әверелер дип көтәргә генә кала.

Әхмәт әфәнде Канлыдәрә үзенең яңа китабын Америкада аспирантурада укыганда фәнни җитәкчесе булган хөрмәтле остазы Эдвард А. Аллвортның якты истәлегенә багышлаган.

***Әлфинә Таһир кызы Сибгатуллина,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы, М. Горький исемендәге Дөнья әдәбиятлары институтының өлкән фәнни хезмәткәре.*

**2019 елның 19 апрелендә** Казанда Габдулла Тукайның әдәби музеенда «Габдулла Тукай иҗатын кабул итү һәм өйрәнү офыклары» темасына түгәрәк өстәл узды. Ул 2019 елда Татарстан Республикасында Туган тел көненә багышланган чаралар планы кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Габдулла Тукайның әдәби музее тарафыннан оештырылды.

Түгәрәк өстәлнең максаты татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүнең үсеш мөмкинлекләрен ачыклау, бөек әдипнең хәзерге мәдәнияттәге һәм киләчәктәге урыны турында фикер алышу буларак билгеләнгән иде.

Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләре катнашты.

**2019 елның 17–20 апрелендә** Грузиянең Тбилиси шәһәрендә «Бүгенге дөньяда традицион мәдәниятне саклау һәм үстерү тәҗрибәсе» темасына халыкара иҗади лаборатория эшләде. Әлеге чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Р.Р. Солтанова, Л.М. Шкляева, Н.В. Герасимова катнашты.

Программага Грузиянең Симон Джанашиа исемендәге Милли музее, Сигнахи шәһәренең Тарих һәм этнография музее, Уплисцихе музей-комплексы экспозицияләре һәм фондлары, Балалар иҗаты йорты эшчәнлеге, рәссамнарның иҗат лабораторияләре белән танышу да кертелгән иде.

**2019 елның 25 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә әдәбият галиме, археограф, текстолог, филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш гыйльми хезмәткәре Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗановка 80 яшь тулу уңае белән «Төркитатар язма мирасы: саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре» дигән темага фәнни-гамәли семинар үтте. Семинар барышында төрки-татар кулъязма мирасы: туплау һәм өйрәнүнең торышы, бүгенге әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре, эпиграфик истәлекләрне ачыклау һәм саклау проблемалары хакында фикер алышу оештырылды.

Чарада Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе Мөхәммәд Фөзули исемендәге Кулъязмалар институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты Керимов Паша Алиоглы, Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе Низами Ганҗәви исемендәге Әдәбият институты фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Османлы Исмихан Магаммад оглы, Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясе каршындагы Үзбәкстанның өряңа тарихы буенча Координационметодик үзәк мөдире, тарих фәннәре кандидаты Әминов Бабур Бомурад улы, Россия Фәннәр академиясе Дагстан фәнни үзәге Тарих, археология һәм этнография

иститутының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Шихалиев Шамил Шихали улы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты һәм башка оешмалардан галимнәр, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, белем бирү оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләре катнашты.

Семинар кысаларында юбилей уңаеннан нәшер ителгән «М. Әхмәтҗанов. Сайланма хезмәтләр» җыентыгы тәкъдим ителде.

**2019 елның 26 апрелендә** Габдулла Тукайның туган көненә багышланган тантанада Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде.

Әлеге мәртәбәле бүләккә Әлмиев Надир Усман улы (график эшләр сериясе, «Хиросима чаңнары» циклы, Дәрдмәнд, Г. Тукай, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Р. Кутуй, Р. Бохараев һ. б. татар шагыйрьләре җыентыкларына иллюстрацияләр, «Татарстан, Алтай» пейзажлар сериясе өчен); Фәйзрахманов Айдар Фәтхрахман улы (татар фольклор мирасына керткән өлеше, «Олы юл» әдәби-музыкаль кичәләр циклы, «Онытырга мөмкин түгел» һәм «Яшәү барыбер кызык», «Олы юл», «Борчылма» җыентыклары өчен); Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары төркеме – Бикчәнтәева (Хәмитова) Люция Миңнеәхмәт кызы, Бариев Радик Зөфәр улы, Хәйруллин Искәндәр Илдар улы (татар сәнгате үсешенә керткән өлеше һәм татар театры үсешендә зур роль уйнаган «Гөлҗамал», «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Кара чикмән», «Өч сеңел», «Дон Жуан» спектакльләрендә сәхнә образларын тудырган өчен), Галиуллин Тәлгат Нәби улы («Мөхәммәт Мәһдиев Йолдызлыгы» роман-эссесы, «Китек көзге» китабы, «Мы – потомки страны Тартария» әдәби-тәнкыйди басмасы өчен) лаек булды.

Лауреатларга дәрәҗәле бүләкләрне Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов «Казан Экспо» күргәзмә комплексында урнашкан Илһам Шакиров исемендәге концерт залында тапшырды.

**2019 елның 16 маенда** Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Татар торак пунктлары: методология, структура, төп тикшерену аспектлары» темасына түгәрәк өстәл үтте. Чарада Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, мәгариф оешмалары вәкилләре катнашты.

**2019 елның 15–18 маенда** Беларусь Республикасының Минск шәһәрендә «Лексикографиянең бүгенге проблемалары» дигән темага XIV Халыкара фәнни конференция узды. Конференциягә Беларусь Республикасы, Россия, Чехия, Австрия, Польша, Украина һәм башка илләрдән танылган галимнәр чакырылган иде.

Әлеге конференциядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге

Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының директор урынбасары О.Р. Хисамов катнашты һәм «Татарстан Республикасы топонимнарының электрон картотекасы» темасына фәнни чыгыш ясады.

**2019 елның 18 маенда** Казан федераль университетындагы Н.И. Лобачевский исемендәге музейның күргәзмәләр залында күренекле археолог, профессор, тарих фәннәре докторы Альфред Хәсән улы Халиковның (1929–1994) тууына 90 ел тулу уңаеннан «Археолог» дип аталган күргәзмә ачылды. Күргәзмә ачылышында Казан федераль университеты ректоры И.Р. Гафуров, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры А.Г. Ситдыйков катнашты.

Күргәзмәдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтында, Казан федераль университетының Археология музеенда, Татарстан Республикасы Милли музеенда, Биләр дәүләт тарихи-археологик һәм табигый музей-тыюлыгында, Алабуга дәүләт тарихи-археографик һәм табигый музей-тыюлыгында саклаучы материаллар тәкъдим ителде.

**2019 елның 29–31 маенда** Казанда Россиянең һәм чит илләрнең әйдәп баручы галимнәре педагогик белем бирү буенча «Укытучының һөнәри компетенцияләрен үстерү: төп проблемалар һәм кыйммәтләр» дип исемләнгән V Халыкара форумда мәктәптә белем бирүгә һәм укытучыларның әзерлегенә бәйле актуаль проблемалар турында фикер алышты. Алар Россиядә һәм дөньяда педагогик белем бирүне яңартып кору тенденцияләре һәм үзенчәлекләре, укыту технологияләре һәм материаллары белән танышты, эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Форумда Россиянең – 140 тан, чит илләрдән 70 тән артык югары белем бирү оешмалары вәкилләре катнашты.

**2019 елның 31 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Балалар дөньясы: рухи кыйммәтләрне яклау һәм үстерү» темасына түгәрәк өстәл оештырылды.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Язучылар берлеге, Татарстан китап нәшрияты, фәнни оешмалар, татар театрлары һәм вакытлы матбугат вәкилләре, язучылар һәм шагыйрьләр һ. б. катнашында узган бу чарада әдәбият, сәнгать һәм матбугатның балаларны тәрбияләүдәге һәм рухи яклаудагы роле турында сүз барды. Аерым алганда, татар театрларында балалар һәм яшүсмерләр репертуары; татар вакытлы матбугатында балалар әдәбияты; балалар өчен татар телендә яңа телевизион канал – «Шаян ТВ» эшчәнлеге турындагы сораулар күтәрелде. Докладлар белән «Шаян-ТВ» каналының башкарма директоры Рәмилә Сәхәбетдинова, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире урынбасары Факил Сафин, Казан федераль университеты доценты Миләүшә Хәбетдинова һәм башкалар чыгыш ясады.

Түгәрәк өстәлне Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырды.

**2019 елның 27 маеннан 7 июненә кадәр** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Пенза өлкәсенең, **12–23 июнендә** Төмән өлкәсенең татар авылларына комплексы экспедицияләр оештырылды. Экспедицияләр вакытында тел, тарих, фольклор, гамәли-декоратив сәнгать, археография, музыка буенча материаллар тупланды.

Шулай ук **19–24 майда,** Кострома татарларының традицион мәдәниятен өйрәнү максатыннан, Кострома шәһәрендә һәм, татар эпиграфик һәйкәлләрен тарихи-археографик өйрәнү максатыннан, **27 майдан 5 июньгә кадәр** Татарстан Республикасының Биектау районында, **10–20 июнь көннәрендә** Самара өлкәсендә махсуслаштырылган экспедицияләр үтте.

**2019 елның 1–8 июнендә** Казан шәһәрендә Төрки халыкларның XIV «Нәүрүз» Халыкара театр фестивале узды. Фестиваль Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тарафыннан оештырылды.

Фестивальдә Казакъстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Румыния һәм Россиянең милли республикаларыннан барлыгы 29 театр катнашты. Спектакльләр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры, Казан яшь тамашачылар театрлары сәхнәләрендә, шулай ук Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданда һәм Кабан күле яры буенда уйналды.

Агымдагы елда фестиваль Башкортстан театр сәнгатенә багышлап үткәрелде, аннан барлыгы алты театр – М. Гафури исемендәге академия драма театры, Салават башкорт дәүләт театры, Башкорт дәүләт курчак театры, Уфа «Нур» татар театры, Стәрлетамак театр-концерт берләшмәсе, М. Кәрим исемендәге Милли яшьләр театры катнашты.

**2019 елның 10–16 июнендә** «Нәүрүз» Халыкара фестивале исеме астында һәм Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлегенең Россиядә театраль белемне үстерү проекты кысаларында студентлар спектакльләреннән торган «Науруз school» Халыкара фестивале оештырылды. Фестивальдә Т.К. Жургенев исемендәге Казакъ милли сәнгать академиясеннән (Алма-Ата), ГИТИСтан (Мәскәү), Арктика дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтыннан (Якутск), Уфа дәүләт сәнгать институтыннан, Казан театр училищесыннан һәм башка уку йортларыннан студентларның спектакльләре тәкъдим ителде.

**2019 елның 11 июнендә** Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында күренекле тарихчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе Гайнетдин Әхмәревнең тууына 155 ел тулу уңаеннан «Татар халык мәгарифе һәм педагогик фикере үсеше» темасына Бөтенроссия

фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде.

Конференциядә Г. Әхмәревнең педагогик карашлары, иҗтимагый-педагогик эшчәнлеге, хезмәтләрендә татар халкы тарихын укыту мәсьәләләре, бүгенге көндә галимнең педагогик мирасын өйрәнү, татар милли мәгариф системасында телләр өйрәтү мәсьәләләре темаларына фәнни докладлар тыңланды.

**2019 елның 13–15 июнендә** Казанда Алтын Урда дәүләте оешуга 750 ел тулу уңаеннан «Алтын Урда тарихы һәм мәдәнияте» темасына I Халыкара фәнни симпозиум узды. Ул, Алтын Урда мәдәни мирасын саклау һәм өйрәнү, фәнни хезмәттәшлекне ныгыту максатыннан, А.Х. Халиков исемендәге Археология институты, Казан федераль университеты һәм Төрек тарихи җәмгыяте тарафыннан оештырылды. Чарада Россия һәм Төркия фәнни оешмалары, югары уку йортлары галимнәре катнашты.

**2019 елның 24–25 июнендә** Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе, Кореяның Донг-Док Кызлар университетының Евразия тюркологиясе институты белән берлектә «Евразия мәдәни киңлегендә бүгенге тюркология» темасына Халыкара семинар үткәрде. Семинар эшендә Көньяк Корея, Төркия, Азәрбайҗан, Россия фәнни оешмалары галимнәре катнашты. Программа кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Гуманитар тикшеренүләрнең өстенлекле юнәлешләре: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» темасына түгәрәк өстәл оештырылды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2019. № 2

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 05.07.2019. Басылды: 18.07.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ, К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла